ЧЫН МИРАС

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№12 / декабрь 2012



ТАТАРСТАНДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

9 тәңкәле чулпы-көянтә.
Билгесез оста

Журнал «Татмедиа» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Баш мөхәррир урынбасары —
җаваплы сәркатип —
Рамил Ханнанов

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Иҗат төркеме:
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83 (17-90)
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият
комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ № М-1717
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 $^{1}/_{16}$
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 7.12.2012

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№12 / декабрь

Эчтәлек

ТАРИХ

4 Федератив мөнәсәбәтләр һәм илдәге вазгыять. *Минтимер Шәймиев*
8 Татарстан Республикасы Конституциясе: тарих һәм хәзерге заман. *Әхмәт Мазһаров*
18 Тарихи-мәдәни мирас елы: нәтиҗәләр һәм бурычлар. *Айрат Сибагатуллин белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*
23 Биналарда — тарих хәтере. *Рания Раимова*

ӘДӘБИЯТ

28 Арыслан галим. *Мөсәгыйт Хәбибуллин*
35 Гомерем юлы. *Хәсән Туфан*
36 Шәрекъ Ренессансы. *Резеда Ганиева*
44 Габдерәшит Ибраһимның Җәмалетдин Әфгани турында бер чыгышы. *Әлфинә Сибгатуллина*
52 Батырша. *Фәүзия Бәйрәмова*
57 Туфан строфасы серләре. *Фәридә Хәсәнова*
69 Йолдызлар төстән язганда... *Рифә Рахман*
75 Тукай энциклопедиясенә. *Резеда Ганиева*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

80 Иле барның теле бар. *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*

МИЛЛИ ИДЕЯ

84 Татар теле — гомумхалык теле. *Фәрит Яхин*

89 Шахмат гүзәллеге гроссмейстеры. *Атлас Гафиятов*
93 2012 елга «Чын мирас» журналының библиографиясе
96 Тарих сәхифәләреннән

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторлар, М.Козловский, А.Дубин, А.Даниловның шәхси архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — Балалар клиникасы. 60-70 нче еллар. Хәзерге Язучылар берлеге бинасы
А.Дубин коллекциясеннән

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

ТАРИХ

Тарихтагы канлы тауларның,
Түбәсендә — ядкәр каберләр.
Өсләрендә — гамьсез әремнәр...
Моңарчы да килгән, киткәннәр,
Моннан соң да килер дәверләр.

Хәсән Туфан

ФЕДЕРАТИВ МӨНӘСӘБӘТЛӘР ҺӘМ ИЛДӘГЕ ВАЗГЫЯТЬ

(ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ М.Ш.ШӘЙМИЕВНЕҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ 20 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН «ЯҢА ФЕДЕРАТИВ РОССИЯНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДАГЫ КОНСТИТУЦИОН ЗАКОН ЧЫГАРУ ТӘҖРИБӘСЕ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯДӘ ЯСАГАН ЧЫГЫШЫ)

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе

Моннан 20 ел элек — 6 ноябрь көнне 14 сәгать 28 минутта Республика Югары Советы Татарстанның яңа Конституциясен кабул итте. «Вакыт — иң яхшы хөкемдар». Төп законның — теләсә кайсы дәүләт Конституциясенең дә тормышчанлыгын чынбарлыкта чагылдырган гыйбарә бу. Катлаулы сәяси вазгыятькә карамастан, кайвакыт үтеп тә булмаслык тоелган каршылыклар аша, Татарстан Дәүләт суверенитеты турында Декларация һәм республика статусы турында 1992 елның 21 мартында узган бөтенхалык референдумында тавыш бирү йомгаклары нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Конституциясе кебек үк, кеше хокукларын һәм ирекләрен яклауны гарантияләп, шушы еллар эчендә республикабызның тотрыклы социаль-икътисади үсешен тәэмин итеп килә. Без яңа Россия Федерациясе төзүнең беренче адымнарыннан ук илебезнең иҗтимагый-сәяси һәм законнар чыгару — хокукый кырында аның федератив төзелешен яклап чыктык һәм чыгабыз, чөнки Россия дәүләтен демократияле төстә үстерүнең бердәнбер юлы бу. Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм федерациянең башка субъектлары конституцияләре бер-берсеннән килеп чыга.

Россия Федерациясе Конституциясенең 11 нче статьясында болай диелгән:

«...1. Россия Федерациясендә дәүләт хакимиятен Россия Федерациясе Президенты, Федераль Җыен (Федерация Советы һәм Дәүләт Думасы), Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе судлары тормышка ашыра.

2. Россия Федерациясе субъектларында дәүләт хакимиятен аларның үзләре тарафыннан оештырылган дәүләт хакимияте органнары тормышка ашыра.

3. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары арасында үзара

эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр чикләрен билгеләү бу Конституция, Федератив килешү һәм вәкаләтләр чикләрен билгеләү турында башка килешүләр нигезендә хәл ителә».

Үзәк белән элеккеге автоном республикалар һәм калган субъектлар арасында Конституция нигезендә вәкаләтләр чикләрен билгеләү мөмкинлеге — Россия дәүләте тарихында моңарчы күрелмәгән вакыйга иде. Ул үзгәртеп кору елларыннан соңгы яңа җәмгыятьнең сәяси тормышында зур алга китеш булды.

Тик, ни кызганыч, оппозицион партияләрнең фракцияләре генә түгел, Россия республикаларында яшәүчеләр әлегә дәррәү яклап-хуплап, үзләренә тавыш биреп килгән «Бердәм Россия» партиясе депутатларының бер өлеше дә империячел фикерләү сагышыннан бүгенгәчә аерыла алмый. Конституциядә, Россия Федерациясендә суверенитет һәм хакимиятнең бердәнбер чыганагы булып аның күпмилләтле халкы тора, дип ачык итеп билгеләнүгә карамастан, хакимият институтларының «Россия — руслар өчен» кебек өндәмәләрне рәсми төстә гаепләүләрен ишеткәнебез яки Конституциянең 14 нче статьясын тиешле дәрәҗәдә төгәл үтәгәнебез юк (анда, дини берләшмәләр дәүләттән аерылган һәм закон алдында тигез, дип бик ачык язылган). Яисә законнар чыгару шартларын булдыру проблемасын алыйк. Россия Федерациясе Конституциясенең 68 нче статьясында, Россия Федерациясе барлык халыкларына туган телен саклау, аны өйрәнү һәм үстерүгә шартлар булдыру хокукын гарантияли, диелгән. Глобальләштерү шартларында милли республикаларда туган телне саклауга үтә зур тырышлыклар куелса да, Конституциядә игълан ителгән нормаларга каршы килеп, аерым федераль структуралар халыкларның туган телләрен өйрәнүгә хокукларын өлешчә кысуга юл куйган мәгариф стандартларын кабул итә. Дәүләтебездә милли мәсьәләләр проблемалары күзгә күренеп тора һәм алар тиешле хакимият институтын булдыру аша төптән уйланылган чишелеш-карарлар таләп итә. Әле ярый ил Президенты Владимир Владимирович Путин бу хакта тагын бер кат искә төшерде. Әмма күренеп торган проблемаларга күз йомарга ярамый. Аларны хәл итү дәүләтнең алга таба ныгуына китерәчәк ләбаса.

Ни өчен бүген, Татарстан Республикасы Конституциясе көнендә, барлык хакимият структуралары, барлык дәрәҗәләрдәге иҗтимагый оешмалар тарафыннан иң элек Россия Конституциясен төгәл үтәү зарурилыгы турында сөйләргә туры килә? Минемчә, җавап бер генә — чынбарлыктагы демократик федерация булдыру өчен кирәк бу. Безнең моңа инануыбыз шактый катлаулы булган соңгы егерме елдагы социаль-сәяси тормыш тәҗрибәсе белән раслана. Бу еллар РФ һәм ТР Конституцияләренең кайбер җитешсезлекләренә, кайбер нигезләмәләренең бер-берсенә туры килмәүләренә карамастан, бүген безнең өчен тотрыклылык гаранты булып торуын күрсәтә.

Конституция нигезендә вәкаләтләр чикләрен ике як өчен дә кулай итеп билгеләү мөмкинлеге гамәлдәге Конституцияләрне үтәү-тануның төп нигезе булып тора. Башка юл юк. Безгә алга таба да, зирәклегебезне җуймыйча, бауны үзебезгә артыгын тартмыйча, вәкаләтләр чикләрен билгеләү механизмын камилләштерү юлларын эзлисе иде. Шуны ассызыклап үтәсем килә: федерация субъектларыныкы гына булган вәкаләтләргә теге яки бу тыкшынулар депутатларга һәм Федераль Җыен вәкилләренә — ахыр килеп, югары законнар чыгару хакимиятенә ышанычыбызны какшата. Федерация субъектларының гына карамагында яки уртак карамактагы вәкаләтләрне үзәк

файдасына «аударып» кабул ителгән федераль законнар байтак.

Бу җәһәттән иң элек, Россия Федерациясе субъекты башлыгы вазифасы атамасы буенча 2010 елның декабрендә кабул ителгән «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законга үзгәреш кертүне мисал итеп китерергә була.

Төрле чакырылышларның күп кенә депутатлары инде 2001 һәм 2005 елларда ук Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары Ищенко һәм Харченко тәкъдиме белән мондый үзгәреш кертүне кабул итү омтылышы булганын белә.

Шул ук вакытта шуны да беләбез: алар тарафыннан кертелгән закон проекты Россия Федерациясе Хөкүмәте ягыннан рәсми төстә инкарь ителде. Рәсми инкарьда, бу тәкъдим Россия Федерациясе субъектларының үз дәүләт хакимияте органнары атамаларын мөстәкыйль билгеләүгә хокукын чикли һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 11 нче статьясына каршы килә, дип күрсәтелгән иде.

Нәтиҗәдә Россия Федерациясе Дәүләт Думасының 9 декабрь, 2005 елгы карары нигезендә әлеге закон проекты кире кагылды.

Бу җәһәттән законнарны төгәл үтәргә тырышучы гражданнарыбыз (ә хәзер алар — кемгә караганда да актив): «Шуннан бирле нәрсә үзгәрде, дәүләтнең Төп законын үтәүгә салкынрак карый башладыкмы әллә?» — дип аптырый.

Мәгълүм булганча, Россия Федерациясе Конституциясеннән бер елга алданрак кабул ителгән Татарстан Конституциясе, һичшиксез, аның кануннарына тулысынча туры килеп бетә алмый иде. Үзгәртеп кору елларыннан соңгы чордан күренгәнчә, гражданнарыбызның тормыш сыйфатын яхшыртуга, хокукларын һәм ирекләрен саклауга юнәлдерелгән тырышлыклар фәкать Россиянең, республикаларның конституцияләрен һәм федерациясе субъектлары уставларын үтәү нигезендә генә нәтиҗәле булырга мөмкин. Өстәвенә, инде алдан әйтеп үткәнемчә, үзара килешү өчен вәкаләтләр чикләрен билгеләүнең үтемле, әйбәт механизмнары бар. Яңа гына оешкан яисә бүген гамәлдә булган, тик перспективалары әллә ни күренмәгән партияләр һәм хәрәкәтләрнең «Нигезенә кадәр җимерик тә, аннан соң...» кебек теге яки бу өндәмәләрен без инде күптән ишеткән. Алар безгә кыйммәткә төште... Мондый өндәмә-белдерүләр Конституциягә каршы килә, һәм аек акыллы кешеләр өчен һич кулай була алмый.

Конституциябезне кабул итү көне алдыннан, Конституция Комиссиясе Рәисе буларак, сәяси карашларына бәйсез рәвештә, яңа Татарстанның киләчәген кайгыртып, шәхси амбицияләрен читкә куеп, Төп законыбызны бертавыштан кабул иткәннәре өчен, шәхсән үз исемемнән һәм Татарстанда яшәүче барча халык исеменнән республика Югары Советы комиссияләренә, депутатлары һәм җитәкчелегенә, Министрлар Кабинеты, Президент Аппаратының җаваплы хезмәткәрләре, галимнәр, иҗтимагый эшлеклеләргә рәхмәт белдерәсем килә. Бик зур рәхмәт сезгә!

Шул еллардагы катлаулы эш татар милләтенә мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртте, лаеклы киләчәккә юнәлешле милли үзаңның үсүенә китерде. Социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни өлкәләрдә күпмилләтле республикабызның күзгә бәрелеп торган уңышлары «Без булдырабыз!» дигән сүзләрне тагы да ышанычлырак әйтү мөмкинлеге бирә.

Казан, 2 ноябрь, 2012 ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ: ТАРИХ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

ӘХМӘТ МАЗҺАРОВ,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты

РЕСПУБЛИКАНЫҢ ТӨП ЗАКОНЫ — КОНСТИТУЦИЯ ТАТАРСТАНДА ЯШӘҮЧЕ КҮПМИЛЛӘТЛЕ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ, ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КҮПТӘННӘН КИЛӘ ТОРГАН БАРЛЫК ӨМЕТЛӘРЕН ҺӘМ ГАМЬНӘРЕН, КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧЫН ҮЗЕНӘ ТУПЛАГАН ХӘЛИТКЕЧ ДОКУМЕНТ БУЛДЫ.

Бер үк вакытта ул Россиядә яңа федератив дәүләтчелек урнашу этабына хас проблемаларны һәм катлаулылыкларны чагылдыра. Нәкъ менә Конституциядә без беренче тапкыр хокукый социаль дәүләтне, демократия иреген һәм халыкларның иминлеген югары кыйммәт буларак игълан иттек. Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов Республика Дәүләт Советына юлламасында билгеләгәнчә, «Татарстан Конституциясенең егерме еллыгы Төп законның тарихи әһәмиятен һәм республиканың заманча дәүләтчелеге формалашудагы ролен ассызыклап күрсәтте».

Егерме еллык ул — бәйрәм дә, узганнарга йомгак ясау да һәм киләчәккә үсеш перспективалары турында уйланулар вакыты да. [...]

Татарстанның беренче Конституциясе 1926 елда кабул ителгән иде. Ул 1920 елда төзелгән милли дәүләтчелек формасын ныгытты. Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы ул вакытта ук инде дәүләтчелекнең кайбер атрибутларына ия була. Алар — конституция, закончылык, территория, рәсми административ оешмалар, дәүләт телләре һәм символлары. Рус теле белән беррәттән, татар теле дә актив өйрәнелә, милли мәдәниятләр хөкүмәттән финанс ярдәме ала.

1936 елгы СССР Конституциясен әзерләү барышында республиканың статусын союз дәрәҗәсенә күтәрү турында тәкъдимнәр әйтелә, ләкин

Сталинның бу мәсьәләгә карата катгый позициясе бары тик автоном статусны кабат беркетүгә генә китерә. 1937 елгы ТАССР Конституциясендә аерыча мөһим нормалар «Дәүләт төзелеше» дип аталган аерым бер бүлеккә туплана, ТАССР гражданлыгы, шәхси суд органнары һ.б. шундыйларны булдыру хокукы турында нигезләмә эшләнә. Әлбәттә, тоталитар режимның ныгуы сәбәпле, республиканың фактик хокуклары партия оешмаларының карарларын үтәүне оештыруга кайтып кала. Шуңа карамастан аерым республика төзелү, мәдәниятне үстерү максатыннан кайбер оешмаларга нигез салыну уңай йогынты ясый һәм зуррак мөстәкыйльлеккә ирешү юлында мөһим этап була.

Ил тарихындагы сугыштан соңгы чор, шәхес культын фаш итүгә карамастан, республика хокукларын киңәйтүгә алып бармады. Киресенчә, коммунистик идеология милләтләрнең берләшүен котылгысыз дип игълан итте, хакимият татарлар өчен тел, мәгариф, китап бастыру, массакүләм мәгълүмат чаралары кебек өлкәләрдә чикләүләр кую ягыннан конкрет адымнар ясады.

Шул чорда республика, «Милләтләрнең һәм телләрнең югалуы — бөтен кешелекнең генофонды җимерелү», дигән аксиомага таянып, татар мәдәниятен саклау мәсьәләсендә үзенчәлекле калкан ролен үтәде. Совет федерациясенең формаль характеры һәм номиналь дәүләтчелек республикага үз икътисади һәм мәдәни сәясәтен корырга мөмкинлек бирмәде. Шул ук вакытта Татарстан зур үсеш алган сәнәгате, авыл хуҗалыгы, фәне һәм югары мәгарифе булган көчле төбәккә әйләнә барды.

1978 елгы Конституцияне кабул иткәннән соң, Татарстанның дәүләтчелеген билгеләүдә берникадәр үзгәрешләр барлыкка килде, хокук институтлары «Татарстан АССРның милли-дәүләти һәм административ-территориаль төзелеше» исемен алды. Үзгәрешләр шулай ук ТАССР белән РСФСР арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә, республиканың РСФСР карамагында булган аерым мәсьәләләрне чишүдә катнашуына кагылды. Шуның белән бергә, 1978 елгы Төп Закон автономия статусының дәүләти-хокукый билгеләре исемләгән теркәп бара торган нормаларны үзгәрешсез калдырды.

1978 елгы ТАССР Конституциясенә кертелгән төзәтмәләр халыкның социаль-икътисади һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмадылар. Зыялылар арасында әледән-әле СССРда республикаларның тигез хокуклы булмавы, Татарстанга союздаш республика хокукы бирү турындагы мәсьәләләр күтәрелә иде. [...]

Үзгәртеп кору (асылда җәмгыять төзелешендә революцион үзгәрешләр) барышында, сүз иреге, демократия, базар мөнәсәбәтләрен игълан иткәндә, без Россия Совет Федератив Социалистик Республикасында гамәлдәге хокук кысаларында яшәүне дәвам иттек. Сәясәтчеләр капиталистик мөнәсәбәтләрнең яңадан торгызылуы турында сүз алып барды, ә ил фактик һәм юридик яклардан социалистик ил булып кала бирде. Иске структураларны үзгәртү һәм тоталитар ялган федерациядән (асылда империядән) чын, реаль федерализмга күчүнең ышанычлы юлларын эзләү барды. Бу иҗади процесс иде. Туа килгән күпсанлы сорауларга беркемдә дә анык кына җавап юк. Демократия нормаларын үтәү Татарстан законнары җыелмасында авыр тарихлы, үпкәләре һәм күпсанлы стереотиплары җыелган күпмилләтле халыкның мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны таләп итте. Төрле позицияләрне һәм сәяси карашларны, яңа социаль-иҗтимагый мөнәсәбәтләргә күчүнең кулай вариантын табу өчен, үзара килештерергә кирәк иде. [...]

Ул чакта беркем дә СССР таркалыр дип уйламады һәм барлык таләпләр союз статусын тануга кайтып калды. Искә төшереп үтәсем килә: ул вакытта республикалар гына түгел, Россия үзе дә хокуксыз иде, суверенитет игълан итеп, ул үзенең лаеклы статусы өчен көрәште. Ә Татарстан тагын да хокуксызрак хәлдә. Мисал өчен, республиканың ул елларда барлыгы 2% милке бар иде, ә сәнәгатьнең 80%ы союз милкендә. Нинди автономия турында сүз була ала? Республика бөтен Прибалтика кадәр эшләсә дә, акчасын, татар зыялылары сораганча, үз мәдәнияте үсешен тәэмин итүгә тота алмады.

Республика өчен башлангыч хокукый акт булып 1990 елның 12 июнендә кабул ителгән РСФСР дәүләт суверенитеты турындагы Декларация торды. Анда бөтен халыкларга үзләре сайлаган милли дәүләтчелек формасында үзбилгеләнү хокукы бирелгән иде. Шуннан соң ТАССР Югары Советы да үзенең дәүләт бәйсезлеге турындагы Декларациясен кабул итте. Россия белдергән хокукларга туры килү өстенә, моны халык үзе катгый таләп итте. Ул көннәрдә Россиянең шул чактагы Президенты Б.Н.Ельцин Казанга килде һәм хәзерге вакытта бар кешегә дә таныш булган канатлы сүзләрне әйтте: «Суверенитетны күтәрә алган кадәр алыгыз!» [...] Бүген күпләр Б.Н.Ельцинны Татарстан суверенитетына теләктәшлек күрсәткәне өчен ачулана, ләкин ул шуның белән киеренкелекне йомшартты. Урамнарда берөзлексез митинглар бара, милләтара каршылыклар бәрелешләргә көчү белән яный, уннарча партия матбугат битләрендә бәхәсләшә, парламентта депутатларның кайнар дебатлары бара. Сәяси көчләр позицияләренең капма-каршы якка аерылуы һәм килешмәүчәнлекләре территорияләрнең идарә ителмәс хәлгә килүенә китерергә мөмкин иде.

Эш 1991 елның 24 октябрендә «Татарстан Республикасы дәүләт бәйсезлегенең актын» кабул итүгә кадәр барып җитте. Анда шундый юллар бар: «Татарстанның Дәүләт бәйсезлеге турында Актның үтә дә әһәмиятен искә алып, шуңа бәйле рәвештә республиканың югары органнарына, аның күпсанлы халкына йөкләтелгән җаваплылыкны истә тотып, Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә, республиканың бәйсезлеге турындагы Актны кабул итү нәтиҗәсе буларак, Татарстан Республикасының сәяси-хокукый, социаль-сәяси хәлхәләтендәге үзгәрешләр хакындагы анализ-прогнозны Татарстан ССР Югары Советы тикшерүенә куюны йөкләргә». Әлеге документта сүз, әлбәттә, тулы бәйсезлек турында бармый, ул заманында яңартылган ССР Союзының тиңдәше кебек кабул ителгән Бәйсез Дәүләтләр Оешмасына керү теләген чагылдыра. Бер үк вакытта Акт хисләрнең кайнарлык дәрәҗәсен күрсәтте, ул үзеннән-үзе Россия Федерациясен Республика белән сөйләшүләр алып барырга этәрде. Икенче яктан, Мәскәүдә Россиянең бөтенлегенә куркыныч янау, республикалардагы сепаратизм һәм алар тарафыннан РСФСР Конституциясе бозылу турында тавышлар ишетелде, сәясәтчеләр һәм депутатлар иң катгый чаралар күрүне таләп иттеләр. Алар Россия хокук актларының үзләре үк әле һаман да совет, социалистик булып калган Конституциясен бозуларын онытталар иде.

Шундый катлаулы шартларда Б.Н.Ельцин ачыктан-ачык демократиягә көчү кирәклеге турында белдерде, һәм аның алдына тоталитар системаны чын федерациягә әйләндерү механизмы мәсьәләсе килеп басты. Ил Президенты Татарстан Республикасы халкының ихтыярына каршы бара алмый иде. Җитмәсә, башка республика, шулай ук өлкәләрдә дә күбрәк хокук һәм ирек

Татарстан Республикасы гербы

Татарстан Республикасы флагы

таләп иттеләр. Бердәнбер юл булып төбәкләргә максималь мөстәкыйльлек бирү калды.

Безнең Конституциянең тууы Татарстанның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларциягә нигезләнде. Декларация республиканың барлык күпмилләтле халкы исеменнән кабул ителгән суверенитетның табигатен, ике дәүләт теленең дә тигез хокуклы булуын билгеләде, кеше хокукларын һәм ирекләрен, шулай ук РСФСР белән килешү төзүнең зарурилыгын игълан итте. Шуның белән бергә Конституциягә таба хәрәкәт юлында 1992 елның мартына билгеләнгән республика статусы турындагы Референдум мөһим адым булды. Ул яшәп килгән хакимиятнең легитимлыгын раслау, аның стратегиясенең дөреслеген бәяләү, халыкның төрле катлам вәкилләрен республикабызның абруен күтәрү максаты тирәсенә берләштерү ихтыяҗыннан үсеп чыкты.

Референдумда «Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе һәм

башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә кора торган суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты, дигән сүз белән сез килешәсезме?» соравына җавап бирергә кирәк иде. Тавыш бирү көне якынайган саен, сәяси ситуация ахыр чиккә җитеп киеренкеләнде. Мәскәүдә кайбер аеруча «кайнар башлар» Ельцинга Татарстанга гаскәр кертергә тәкъдим иттеләр. Россия Федерациясенең Конституция суды референдум үткәрүнең дөрес түгеллеге турында карар чыгарды, ягъни халыкны үз ихтыяҗларын белдерүнең иң демократик формасыннан мәхрүм итте. Россия Федерациясе һәм аның карамагындагы республикалар арасындагы мөнәсәбәт Конституция нигезендә төзелергә тиеш, алар килешергә мөмкин, әмма ул килешүләрнең дә шулай ук федераль Конституциягә нигезләнүе шарт, дигән хокукый позициянең дөреслеген суд билгеләде. Әмма яңа Конституция әле кабул ителмәгән, ә искесе Россиянең дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килә. Хокукый коллизия хасил булды. Билгеле, мондый шартларда Конституция суды хокукый түгел, ә сәяси карар кабул итте.

Шушы вакыйгаларга бәйле рәвештә Республиканың Югары Советы түбәндәге «Белдерү» белән чыкты: «Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты һәм референдум турындагы актлары берничек тә Россия Федерациясенең дәүләти һәм территориаль бөтенлегенә янамый... Алар республика гражданнарын милли һәм дини билгеләре буенча дискриминацияләмиләр һәм бүлмиләр, ә гражданнарның, нинди милләттән булуына карамастан һәм дини ышануларына бәйсез рәвештә, тигез хокукларыннан чыгып, татар һәм рус телләрен дәүләт телләре сыйфатында ныгыталар... Татарстан Республикасының күрсәтелгән актлары РСФСРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациясенең 4 нче маддәсе һәм Россия Федерациясенең халыкара-хокук бурычлары тарафыннан билгеләнгән халыкларның иркле милли-дәүләти үзбилгеләнү принципларына туры килә». [...] Сепаратизмда уйдырма гаепләүләр Татарстанның 1991 елның августыннан Федераль үзәк белән икеяклы килешүләр төзү турында сөйләшүләр алып бару факты белән дә кире кагыла [...]. Әйтик, 1991 елның 15 август Протоколында «мөнәсәбәтләрне җайлауның килешү формаларын куллануга йөз тоту» кирәклеге белдерелгән иде. 1992 елның 2 апрель Протоколында яклар, «Россия Федерациясенең бөтенлеген саклап калу теләгеннән чыгып», «Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе арасында аерым мөнәсәбәтләр урнаштыру кирәклеге турында» килештеләр. Катлаулы сөйләшүләр алып бару өчен Татарстан делегациясе хокукый теләктәшлеккә мохтаҗ иде. Бу яктан Татарстан Конституциясен кабул итү аеруча әһәмияткә ия.

Минтимер Шәрипович Шәймиев җитәкчелегендә Конституция комиссиясе төзү турындагы карар 1991 елның 31 августында кабул ителде, республиканың статусын саклап калу кирәклеген белдергән референдум узды. Шуннан соң сәяси вазгыять тотрыклылана башлады. Төп закон проекты өстендә эш ике елдан артыкка сузылды, аның барышында илебезнең федератив төзелеш тәҗрибәсе, чит дәүләтләрнең конституция төзелешендәге фәнни һәм гамәли үрнәге исәпкә алынды. Проектны бөтенхалык тикшерүе вакытында республика гражданнарыннан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керде. Хатлар һәм телеграммалар республикадагы районнардан гына түгел, чит төбәкләрдән дә күпләп килде. Документ, шулай ук, җирле советларда, иҗтимагый оешмаларда тикшерү узды. Татарстан Кон-

ституциясен әзерләүчеләр фикеренчә, ул чит илләрдә конституцион закон чыгаруның иң яхшы якларын исәпкә алырга һәм халыкара хокук нормаларына туры килергә тиеш иде. Документ проектын тикшерүгә танылган чит ил белгечләре, шул исәптән Швейцария, Алмания галимнәре җәлеп ителде. Алар барысы да Төп законның ахыргы вариантына уңай бәя бирделәр.

Конституция бик җентекләп, кайнар бәхәсләр аша әзерләнде, кайвакыт парламентта фикерләрнең каршылыгын үзара килештереп булмас кебек тоелды. […] Акрынлап алтын урталык табылды. Милләтара, сәяси һәм социаль мәсьәләләрдә мәнфәгатьләрнең тигезлеген булдыру принцибы мәҗбүри нормага әйләнде.

Татарстан Конститутциясе Россия Конституциясеннән бер ел алда кабул ителде һәм соңгысының эчтәлегенә дә йогынты ясады. Республикада кабул ителгән карарларның Россиядә алдан баруы 1993 елгы Конституция Киңәшмәсенең эшендә этәргеч фактор булды. Россия Федерациясе Төп законының республикалар мәнфәгатьләре чагылган аеруча әһәмиятле маддәләре дә шул хакта сөйли. 5 нче маддәнең 2 нче пунктындагы «республиканың үз конституциясе һәм законнар системасы бар» дигән формулировка республикаларда яшәп килгән тәҗрибәне исәпкә ала. 68 нче маддәдәге түбәндәге сүзләр зур казаныш булды: «Республикалар үзләренең дәүләт телләрен урнаштыру хокукына ия. Республиканың дәүләт җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә алар Россия Федерациясе теле белән беррәттән кулланыла». Боларда халыкның бик күптәннән яшәп килгән тигез хокукка омтылышы чагыла. Үзәк белән субъектлар арасында килешүләр төзеп (11 нче маддә, 3 п.), идарә объектларын һәм вәкаләтләрне бүлешү турындагы үтә мөһим нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясенең башлангыч проектында юк иде. Ул нигезләмә Дәүләт бәйсезлеге турында Декларациянең һәм Конституциянең үзәк белән килешүле мөнәсәбәт урнаштыру таләбенә тугры республика җитәкчелегенең максатчанлыгы нәтиҗәсендә пәйда булды. Әлеге маддәне кабул итүнең нәтиҗәсе булып киң масштабларда килешүләр төзелү санала ала.

1994 елгы Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр чикләрен билгеләү турында Шартнамәнең безнең республика үсешендә роле искиткеч зур булуны ассызыклап узарга кирәк. Россия тарихында беренче тапкыр үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәт административ команда бирү диктаты ярдәмендә түгел, ә үзара килешүләр рәвешендә төзелә башлады. Килешү Татарстан белән Федераль үзәк арасында сәяси аныклык кына кертеп калмады, ә республика гражданнарының сәяси һәм икътисади эшчәнлегенә иҗади рух өстәп, халыклар күңелендә тынычлык урнаштырды. Акрынлап халык 90 нчы еллардагы митингларны һәм каты бәхәсләрне оныта башлады.

Икеяклы мөнәсәбәтләрне җайга салуның бер нәтиҗәсе республиканың федераль органнарга сайлауларда катнашуында күренде. 90 нчы еллар башында Татарстанда гомумфедераль парламентка һәм Россия Президентын сайлаулар узмады. Шартнамәгә кул куелганнан соң хәл тамырдан үзгәрде, һәм 1995-1996 елларда республика җирлегендә илнең закон чыгару органнарына узган сайлаулар гомуммиллә̄т юрисдикциясен тануны белдерде, Россия белән Татарстанның «бәйсезлек нисбәте» турындагы бәхәсләренә нокта куйды.

1994 елгы Шартнамәгә кул куюны Татарстандагы күпмилләтле халыкның үзләре сайлаган формада

үзбилгеләнүен Федераль үзәкнең тануы дип караргa мөмкин. Алга таба хөкүмәтара Шартнамәләр пакетын имзалау Мәскәү белән Казан арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә цивилизацион төсмер өстәде, Россия һәм Татарстан җитәкчелеге бөтендөнья җәмәгатьчелеге каршында халыкара хокук нормаларын саклауларын күрсәтте. Болар барысы бергә «Татарстан моделе» дигән исем алды. Еллар үткән саен без бу модельнең республикада тынычлыкны саклауда гына түгел, ә башка төбәкләр өчен дә милләтара мәсьәләләрне конфликтсыз чишүнең, социаль-икътисади проблемаларны уңышлы хәл итүнең, федератив мөнәсәбәтләрнең отышлы формуласы буларак әһәмиятен ныграк аңлый барырбыз.

20 ел эчендә республика федератив мөнәсәбәтләрне төзү үрнәге генә түгел, ил икътисадын яңарту мәйданының флагманы булып җитеште. Татарстан Конституциясе хөкүмәткә, сәнәгатьчеләргә, белгечләргә мөстәкыйль икътисади сәясәт булдырырга мөмкинлекләр тудырды. Иң әүвәл җитәкчелек алдында республика территориясендәге СССР һәм Россия милкен бүлү бурычы тора иде. Безнең хокукый позиция оборона сәнәгатеннән башка барлык милекне дә диярлек Татарстан кулына күчерергә мөмкинлек бирде. Бу икътисадны базар мөнәсәбәтләренә күчергән вакытта хәлиткеч рольне уйнады. «Базар мөнәсәбәтләренә йомшак керү» хосусыйлаштыруга әзерлекле якын килергә җай тудырды, халыкны массакүләм хәерчелектән коткарды, адреслы социаль ярдәм күрсәтер өчен шартлар булдырды, авылны саклап калды, мәдәниятне яклауга юл ачты. Нәтиҗәдә, Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиев җитәкчелегендә республика «Иске торакларны ликвидацияләү» программасын, йөз процентлы газлаштыруны, юллар төзүне, телефонлаштыруны һәм интернетлаштыруны үтәп чыкты. Заманча инфраструктура булдыруда 90 нчы елларда яулап алынган мөстәкыйльлек ярдәм итте.

Икътисади стратегияне төзүдә мөстәкыйльлек, республикабыз Президенты Р.Н.Миңнеханов һәрчак ассызыклаганча, чималга бәйлелектән — нефть химиясендә һәм химиядә, автомобильләр төзү сәнәгатендә, авиациядә IT сферада, авыл хуҗалыгында югары технологияләргә күчәргә мөмкинлек бирде. Сәяси тотрыклылык һәм югары сыйфатлы законнар системасы Татарстанның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген күтәрде.

Республиканың казанышларына халыкара элемтәләр сферасын да кертеп була. Федераль үзәк республиканы халыкара система субъекты буларак карамаса да, фактта Татарстан халыкара бәйләнешләрен актив үстерә. Ел саен республика йөзләрчә иң югары дәрәҗәле делегацияләр кабул итә. Үз чиратында, безнең вәкилләр рәсми визитлар белән төрле илләрдә булалар һәм күпсанлы килешүләр имзалана. Күп илләрдә Татарстанның вәкиллекләре ачылды. Республика шулай ук халыкара оешмалар тарафыннан танылды. Аерым алганда, Европа төбәкләре конгрессында актуаль мәсьәләләр буенча комитетны Ф.Х.Мөхәммәтшин җитәкли. Халыкара бәйләнешләр республиканың абруен күтәреп кенә калмады, икътисади эшчәнлекнең мөһим элементына әверелде.

Безнең хокук белгечләренең казанышы булып Россия субъектларының халыкара эшчәнлек принципларының федераль кануннарда һәм аларга нигезләнгән актларда закон белән теркәлүе тора. 1994 елдагы Шартнамәдә теркәлгән төп нигезләмәләр Россия кануннар системасына урнаштылар һәм бөтен Россиядә гамәлгә керделәр.

Совет чорында игътибар үзәгеннән

читтә калып килгән мәдәният һәм милли мәгариф системасы безнең өчен четерекле өлкә иде. Аларның әһәмиятен мәгърифәт кысаларында гына аңлау дөрес түгел. Татар мәдәниятен, милли мәгарифне үстерү, үз чиратында, халыкның милли үзаңын күтәрү, бигрәк тә яшь буынны милли тормыш, көнкүреш, йола-гадәтләр даирәсендә туган телле итеп тәрбияләү белән бәйләнгән. Республиканың мөһим хокукый инициативасы булып Татарстан Конституциясендә (14 нче маддә), ә аннары Шартнамәдә татар мәдәниятен үстерү өчен илкүләм җаваплылыкны беркетү тора. Федераль хакимият мондый караш белән килешеп кенә калмады, аны хуплап чыкты. Бүген уртак мәдәни сәясәтнең гәүдәләнеше булып ил төбәкләрендә Россия күләмендәге сабантуйлар уздыру күрсәтелә ала. «Юлдаш» телевидениесе һәм Интернет мөмкинлекләре Россия һәм БДБ гражданнарына Татарстанда, дөньяның төрле почмакларында яшәгән татар җәмгыятьләренең эшчәнлеге турында мәгълүмат биреп торуны яңа баскычка күтәрде. Планетаның күпчелек өлешенә ике дәүләт телендә тәүлек буе тапшырулар алып бару безнең уңышларыбызның һәм мәдәният өлкәсендәге мөмкинлекләребезнең символына әверелде.

СССРда барлык автономияләрнең дә Конституцияләре бер үрнәкне күчереп язган иде. Үзгәртеп корудан соң республикалар үзләренең законлы актларын эшли башладылар. Бу «суверенитетлар парадында» һәм кайвакыт стихияле закон чыгаруда, әлеге процессны күпме генә сүксәләр дә, позитив момент бар: кешеләрдән аларның нәрсә көткәннәрен сорадылар. Законнарны унификацияләү билгеле бер дәрәҗәдә генә файдалы, ләкин ил төбәкләренең төрлелеген исәпкә алмау үзен тулысынча фаш иткән бер партия җитәкчелеге астындагы социалистик, иске идарә системасына кире кайтуны белдерер иде. Татарстанда хокук актларының әйдәп баруы шул вакытта котылгысыз булса, ул бүген дә тиешле кысаларда бик кирәк. 1990 еллар ахырында безнең законнарны федераль законнар белән тәңгәлләштерү чоры җитте. Галим буларак, мин бик яхшы аңлыйм: республика Конституциясе объектив рәвештә даими камилләштерүне сорый. Россия җәмгыятенең һәм Татарстан Республикасының үсеше чишелешләрен табу котылгысыз булган конституцион характердагы яңа мәсьәләләрне көн тәртибенә куя килә. [...]

Төп законда билгеле дәрәҗәдә тотрыклылык, хәтта консервативлык булырга тиеш, конъюктурага ияреп, Конституцияне үзгәртергә ярамый, шул ук вакытта закон чыгару тормыштагы үзгәрешләрдән артта кала алмый. 20 ел элек Татарстанда икътисад тотрыксыз, федератив мөнәсәбәтләрнең принциплары да ачык түгел иде әле. Сәясәт коммунистик һәм демократик карашлар арасында бәргәләнде. Бүген базар мөнәсәбәтләренең табигатен һәм төп социаль-икътисади өстенлекләрен аңлау вакыты килде. Республика да, тулаем ил дә тотрыклылык һәм ачыклык чорына аяк басты, шуңа күрә Төп законга үзгәрешләр кертү ихтыяҗы туды. Татарстан Конституциясендәге кайбер маддәләрнең декларатив булуы ачыкланды һәм аларны саклауның инде әһәмияте юк, кайберләренең федераль законнар белән каршылыкка керүе мәгълүм булды һәм алар үзгәртелде. Ләкин шуны ачык аңларга кирәк: тикшерү кысаларына кабаттан кертелми торган нигез законнар бар!

Әйтик, Татарстан Конституциясенең беренче маддәсенә дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациянең иң мөһим нигезләмәләре кертелгән, республиканың статусы референдумда расланган. Алар вакыт сынавын узган һәм бүген дә күпмилләтле халыкның бу нигезләмәләрне яклавына шик юк.

Билгеле булганча, Россия Федерациясе Конституция суды суверенитет төшенчәсен республиканың хокукый сыйфатламасыннан төшереп калдыруны таләп иткән иде. Мондый вердикт юридик күзлектән караганда гадел түгел, чөнки 2007 елгы Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамә икеяклы мөнәсәбәтләрне һәр ике (федераль һәм республика) конституцияне тану нигезендә ныгыта. Россия Конституциясе дә, 5 нче маддәдә телгә алынмаса да, дәүләтләрнең суверенлыгын бөтенләй үк кире какмый. Шул ук вакытта 73 маддәдә турыдан-туры: «Россия Федерациясе карамагыннан тыш, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрдә Россия Федерациясе субъектлары тулы хакимияткә ия», — диелә. Әлеге контекстта «тулы хакимият» дигән тәгъбир безнең аңыбызда дәүләтнең суверенлыгын белдерә. Фәнни күзлектән караганда, республика дәүләт кебек суверенлыкка ия яки, гадирәк итеп әйткәндә, аның үзенең чикләнмәгән хокуклары булырга тиеш. Мәсәлән, Швейцария Конституциясенең 3 нче маддәсендә: «Кантоннарның суверенлыгы Федераль Конституция белән чикләнмәгән дәрәҗәдә суверен», — дип язылган. Ә Швейцария федератив мөнәсәбәтләрнең бик бай һәм гомум танылган тәҗрибәсе белән мәгълүм.

Хәзерге дөньяны глобальләштерү шартларында берәү дә абсолют суверенлык хокукына ия түгел. Теләсә кайсы дәүләт, халыкара килешүләргә кул куйганда, халыкара яки төбәкара оешмаларга кергәндә, үз өстенә төрле йөкләмәләр алып, үзенең милли суверенлыгы белән бүлешә. Теләсә кайсы федерация ил эчендә вәкаләтләрне чикләү нигезендә төзелә. Бу юлга федератив дәүләтләр генә түгел, унитар дәүләтләр дә басты. Дөньякүләм тәҗрибәдә үзәкләштерүдән баш тарту гадәти күренешкә әйләнде, шулардан чыгып компетенцияләрне чикләү вакытында аерымланган суверенитет турында түгел, ә субсидиарлык, ягъни вәкаләтләрне максималь түбән дәрәҗәдә куллану турында сөйләүне артыграк күрәләр. Нәкъ шундый принцип Европа Союзында беркетелгән. Бу — Россия исәпкә алырга тиеш булган дөньякүләм тенденция.

2000 елдан башлап Федераль закон чыгаручы күп кенә уртак вәкаләтләрне, субъектларның закон чыгаруын чикләп, аларны җентекле регламентлап, Федерациягә бирде. Бүген Федерациядәге вәкаләтләрнең артык булуы ачыктан-ачык сизелә, аларны бердәм үзәктән чыгып башкару кыенлаша бара. Идарә структурасында административ аппаратның акланмаган киңәюенә, бюрократлыкка, коррупциягә китерә торган ачыктан-ачык янәшәлекләр хасил була. Хакимиятнең катгый вертикале нәтиҗәсе буларак, аерым территорияләрдә җирле органнар эшчәнлеген координацияләү авырлаша. Болар барысы да идарә эшенең нәтиҗәлелеге кимүгә алып бара. Субъектларны тулаем дотацияләү шартларында тырышып эшләргә, җирле ресурслардан файдаланырга омтылыш кими, шуңа төбәкләрнең үз потенциалы тулысынча файдаланылмый кала. Аңлашыла ки, үзәкләштерүдән баш тартуның котылгысызлыгы һәм Татарстанның бу өлкәдәге уңай тәҗрибәсе илне алга таба федеральләштерү юлларын күрсәтә.

Федераль үзәкнең Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында таләпләренә бәйле рәвештә, Татарстан Парламентының Төп законның асылына һәм рухына сакчыл карашын билгеләп үтәсем килә. 2000 еллар башында Федераль закон тарафын-

нан Федерация субъектының югары вазифадагы затын ачыклау тәртибе үзгәртелде. Төбәк җитәкчесе, урында бөтенхалык тарафыннан сайлану урынына, Россия Президенты тәкъдиме буенча парламент тарафыннан билгеләнә башлады. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, алдан күрә белүчәнлек күрсәтеп, Президентның үз халкы тарафыннан сайлануын күздә тоткан республика Конституциясендәге норманы гамәлдән төшереп калдырмады, ә вакытлыча туктатып торды. Һәм хаклы булып чыкты да: бүген Россия субъект башлыкларын халык сайлап куюга әйләнеп кайта. Яңа Федераль законга һәм Республика Конституциясенә туры китереп, Татарстан Президенты гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайланачак.

Җитәкчеләрне сайлау — аеруча Федерация өчен тарихи расланган адым. Ышанып әйтәм: республика башлыгының атамасы белән дә шулай ук булачак. Бу субъектларның үз вәкаләтендә һәм республиканың югары вазифадагы затына карата «Президент» атамасыннан баш тартуга бернинди ихтыяҗ да юк.

Сайлау алды шау-шуы белән мавыккан кайбер «кайнар башлар» әледән-әле, тарих дәресләрен онытып, республикаларны юк итү тәкъдимен күтәрәләр. Дәүләт төзелешен лабораторияләрдә уйлап табарга, тарихны чиста биттән башлап язарга мөмкин түгел: теләсә кайсы дәүләтнең узганы бар. Россия баштан ук күпмилләтле дәүләт буларак төзелгән. Федераль Конституция очраклы гына «Без, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы» кебек тирән мәгънәле сүзләр белән башланмый. Әлеге сүзләр илнең фундаменталь идеологиясен — аның күпмилләтле булуын чагылдыра, ә бу, үз чиратында, дәүләт төзелешендә чагылыш табарга тиеш.

Россиягә федерализм түгел, ә унитаризм хас дип әйткәндә, тарих сәхифәләрен күздән ычкындыралар. Россия йөзләгән халыкларның мәдәнияте нигезендә, җирле традицияләрне исәпкә алып барлыкка килгән һәм төзелгән. Сәясәтчеләр һәм галимнәр еш кына телгә алган Россия монархлары үз илләренең үзенчәлеген яхшы аңлаганнар. Дипломатик визит белән 1839 елны Россиядә булган француз де-Кюстин бал вакытында император Николай I белән мондый сөйләшүне искә төшерә: «Сез үзегезне руслар арасында дип уйлыйсыз инде, — ди аңа император, тирә-юньдәгеләргә күрсәтеп. — Сез ялгышасыз: менә бу — алман, монысы — поляк, бу — грузин, тегендә — фин, монсы — татар. Һәм болар барысы бергә Россия була». [...]

Яңа Россия демократияне дә, федерализмны да үзе көрәшеп алды. Халыкларның алга таба хокукларын һәм демократик ирекләрен киңәйтүдән башка юл юк. Россия федерализмының үз формасын эзләү вакытында Татарстан һәрвакыт башлап йөрүчеләрнең беренче рәтендә булды һәм булачак, ул моңа көченнән килгән кадәр үз өлешен кертергә әзер. 2007 елны Россия Президенты В.В.Путин тарафыннан имзаланган Федераль үзәк һәм безнең республика арасындагы килешүнең яңа нөсхәсе Федераль закон көченә ия һәм федерализм нигезендә яткан килешүләр формасының дәвамы булып тора. Ул республиканың яшәп килүче статусын кабат беркетә, Татарстан Конституциясен республика дәүләтчелегенең асылы буларак таныта. «Көчле төбәкләр — көчле Россия!» шигаре белән барган юлыбызның дөрес булуын раслый.

Казан, 2 ноябрь, 2012 ел

ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ:
НӘТИҖӘЛӘР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

РЕСПУБЛИКАБЫЗДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ ТӨГӘЛЛӘНЕП КИЛӘ. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ БЕРНИЧӘ СОРАУ БЕЛӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ **АЙРАТ МИННЕМУЛЛА УЛЫ СИБАГАТУЛЛИНГА** МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕК.

– Айрат Миннемуллович, Мәдәният министрлыгы сайтында республикабызда Тарихи-мәдәни мирас елы уңаеннан кабул ителгән чаралар планы үтәлеше турында тулы мәгълүмат бар. Шушы чараларны тормышка ашыру алдагы елларда мәдәният өлкәсендә нинди юнәлешләрнең мөһим икәнен күрсәтте, нинди яңа проектларга башлангыч бирде? Якын киләчәктә Сез җитәкләгән министрлык тарафыннан тарихи-мәдәни мирасны саклау өлкәсендә нинди эшләр планлаштырыла?

— 2012 елның Тарихи-мәдәни мирас елы булуы юкка түгел — тарихи мирасыбызга һәм милли кыйммәтләребезгә сакчыл караш Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясенең нигезенә салынган. ТР Министрлар Кабинеты раслаган Тарихи-мәдәни мирас елын үткәрү буенча чаралар планы җәмәгатьчелек игътибарын әлеге актуаль темага юнәлтте. Ә инде быелгы мөһим проектларга килгәндә, «XXI гасырда мәдәни мирас: саклау, файдалану, популярлаштыру» дип аталган фәнни-гамәли конференция уңышлы үтте. Без аны ел саен оештырырга ниятлибез. Беренче мәртәбә «Бөтендөнья мирасы комитетының

яшьләр моделе» Халыкара яшьләр форумы үткәрелде, икенче зур чара — «ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм табигый чараларын саклау конвенциясенең киләчәге» консультатив утырышы. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге» комплекслы проекты буенча эш дәвам итә. Киләсе елга Болгар цивилизациясе музеен ачу планлаштырыла. 2012 елда мәдәни мирас объектларыннан Татарстан Язучылар берлеге бинасы реставрацияләнде, Боратынский утары, Л.Н.Толстой, А.М.Горький, В.И.Ульянов-Ленин һәм Г.Тукай музейларына реставрация-төзекләндерү эшләре башланды.

Быел 2013-2016 елларга «Мирас-Наследие» максатчан программасы кабул ителде. Әлеге программа кысаларында археологик, фольклор һәм сәнгатькә кагылышлы экспедицияләр оештырылачак, аеруча әһәмиятле тарихи биналарны төзекләндерү-яңарту эшләре уздырылачак, музей фондындагы әйберләр, архив документлары реставрацияләнәчәк.

Программаның үзенчәлеге Татарстан Республикасының туристлык маршрутларында урнашкан мәдәни мирас объектларын саклауга юнәлтелгән булуда.

– Казан шәһәре – татар халкының рухи һәм мәдәни мәркәзе. Шәһәребездәге тарихи һәм архитектура һәйкәлләрен төзекләндерү эше беркадәр җайга салынды. Бу эшләр Универсиада үткәннән соң туктап калмасмы? Гомумән, киләчәктә Казан каласында татар рухын саклау өченниләр планлаштырыла?

— Мәдәни мирас объектларын саклау мәсьәләләре Татарстан Республикасы Президентының аерым контролендә. Тарихи һәм архитектура һәйкәлләрен төзекләндерү эшләре, әлбәттә, Универсиададан соң да туктап калмаячак, әйткәнемчә, «Мирас-Наследие» максатчан программасы кысаларында дәвам итәчәк. Агач архитектура һәйкәлләрен торгызу — күчемсез мәдәни мирасыбызның аеруча четеркле өлеше. Ул Президентыбызның игътибар үзәгендә. Мәдәни мирас булган агач йортларны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы учреждениеләре төзекләндерә. Мәсәлән, алар тарафыннан Галиәсгар Камал, Шиһабетдин Мәрҗани йортлары төзекләндерелде, янган Бәхтиев йорты торгызылды.

Татар рухын саклау дигәндә, беренче чиратта, башкалабыз үзәгендә урнашкан Иске Татар бистәсе турында сүз бара. Ул уникаль мәдәният, мәгариф, һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге булган. Иске Татар бистәсенең тарихи-архитектур йөзен комплекслы саклау өчен, аңа аерым статус бирү турында сүз бара. Хәзерге вакытта бистәне дәүләт саклавына кую максатыннан, документлар әзерләнеп, нәтиҗә чыгару өчен Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтына юлланды.

– Болгарда һәм Зөядә башкарылган тарихи-мәдәни ядкәрләрне саклау өлкәсендәге уңышларыбыз күз алдында, алар һәрьяктан игътибарга лаек. Бүгенге көндә Урта Идел төбәгендә иң эре өяз шәһәрләренең берсе булган, сәүдәгәрләре белән мәшһүр Чистай шәһәрен музейлаштыру буенча нинди эшләр башкарыла? Бу яктан Чистайның потенциалы Алабуга шәһәренә караганда берничә тапкыр зуррак бит.

— Чистай шәһәренең һәм районының мәдәни мирасы уникаль — биредә 144 мәдәни мирас объекты, 250 археология һәйкәле бар, А.М.Бутлеров, В.М.Молчанов, Б.Л.Пастернак, А.А.Фадеев, К.А.Федин, Л.М.Леонов, В.Ф.Боков, М.В.Исаковский, Е.А.Долматовский, К.А.Тренев исемнәре шәһәр тарихына язылган. Чистайны «Мәдәни Афина» дип атаулары юкка түгел. Бөек Ватан сугышы елларында бирегә 200дән артык язучы һәм мәдәният эшлеклесе эвакуацияләнеп, совет язучылары бер-

Е.А.Боратынский музееның эчке күренеше

леге ачылган. Чистайдагы Әдәби фонд интернатында 500ләп язучы баласы, шул исәптән Т.Гайдар, А.Баталовлар яшәгән.

Бүгенге көндә шәһәрнең тарихи үзәге тарихи йөзен һәм ландшафт тирәлеген саклап кала алган. Быел сентябрь аенда Чистай муниципаль районы җитәкчелеге шәһәрдәге Музей берләшмәләре базасында дәүләт музейтыюлыгы ясау инициативасы белән чыкты. Хәзер бу мәсьәлә Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә карала.

– Татар теле, татар мәдәнияте, гореф-гадәтләр, нигездә, авылларда сакланды һәм саклана. Хәзерге вакытта авылларда мәдәният йортларын, аерым мәктәпләрне төзекләндерү буенча план тормышка ашырыла. Татарстанда авылларны үстерү буенча кимендә ун елга исәпләнгән комплекслы программа кабул итәргә кирәк түгелме икән? Мондый программа кабул ителсә, Сез, министр буларак, авыл җирлегендәге мәдәният өлкәсендә нинди юнәлешләргә, проектларга өстенлек бирер идегез?

— Чыннан да, халык мәдәнияте авылларда саклана һәм кыйммәтле мирасыбыз буыннан-буынга тапшырыла килә. Авылларны саклап калу өчен мәктәп, клуб, фельдшерлык-акушерлык пунктлары кебек социаль әһәмияткә ия объектларның эшләп торуы зарур. Без республиканың «Авыл клублары төзү программасы»на зур өметләр баглыйбыз. Аның нигезендә салынган клублар күпфункцияле булачак. Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән бүгенге көндә республиканың һәр районында бер авылда мәдәният йорты салынды. Бу эшкә 500 млн сум акча тотылды. Торак пунктын сайлаганда, беренче нәүбәттә, авылның киләчәктә үсеш мөмкинлекләренә игътибар бирелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән 2013 елда муниципаль районнарда төзеләчәк мәдәният йортлары исемлеге расланды. Алар, һичшиксез, заман таләпләренә җавап бирәчәк, мәдәниятне, халыкның иҗади сәләтен үстерүгә ярдәм итәчәк.

Программа 2014 елга да каралган. Алга таба да дәвам иттерү республика бюджетының мөмкинлекләренә бәйле.

– Классик язучыларыбызның күптомлыкларын чыгару һәрвакыт Мәдәният министрлыгының махсус заказы белән башкарылды. Бу максатта киләсе елларга нинди эшләр планлаштырыла?

— 2009-2010 елларда Фатих Кәрим, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәт Мәһдиев, Һади Такташ, Галиәсгар Камал, Һади Такташның «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде.

2012 елда Рөстәм Кутуйның өчтомлыгы, Рөстәм Мингалимнең дүрттомлыгының I томы, Мөсәгыйт Хәбибуллинның алтытомлыгының I томы, Габдрахман Әпсәләмовның рус телендәге I томы басыла. «Сайланма әсәрләр»нең дәвамын киләсе елларда нәшер итү планлаштырылган.

– Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү юнәлешендә Мәдәният министрлыгы тарафыннан ниләр эшләнә, бу юнәлештәге мөһим эшчәнлек буенча республика программасы бармы, чараларны финанслау ничек тормышка ашырыла?

— Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән эшләү — Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының төп юнәлешләреннән берсе. Бөтендөнья татар конгрессы, Россия төбәкләрендәге Татар федераль милли-мәдәни автономияләре белән берлектә милли мәдәниятебезне саклауга һәм үстерүгә бәйле чаралар үткәрелә. 2012 елда Төрекмәнстанда, Төркиядә Татарстан көннәре узды. Читтәге милләттәшләребезне берләштерүдә зур роль уйнаган милли бәйрәмебез Сабантуй быел Россия Федерациясе төбәкләрендә 147 урында үтте, чит илләрдә 64 урында, мәсәлән, Ташкентта, Алма-Атыда, Нью-Йоркта, Кытайда, Чехиядә, Эстониядә үткәрелде. Төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең бәйрәмнең әһәмиятен абруйлы сүз белән ышандырырлык итеп аңлатып бирә белүләре Сабантуйны уздырырга нык ярдәм итә. Шуның белән бергә Татарстанның һәм Президентыбызның абруе, бәйрәмне уздыруга ярдәм күрсәтүе дә уңай нәтиҗә бирә. Хәзер киләсе елда узачак Сабантуй бәйрәменә әзерлек бара. Федераль Сабантуйны Төмәндә үткәрәчәкбез, ә Бөтенроссия авыл Сабантуен уздыруны Пермь өлкәсенең Барда авылы кабул итәргә әзер.

Читтәге милләттәшләребезне татар китабы белән тәэмин итү юнәлешендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе максатчан эшли. Китапханәнең халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлеге татарлар яшәгән төбәкләргә китапларны килешү нигезендә дә, бүләк итеп тә тарата. 2011 елда 28 төбәкнең 46 китапханәсенә 4 мең экземпляр басма һәм электрон китап җибәрелде. Татар әдипләре әсәрләрен АКШ, Канада, Финляндия, Болгария, Казахстан, Литва һәм башка илләргә дә илтеп җиткерә алдык. ТР Милли китапханәсе Татарстанда басылган татар газета-журналларын 20 адрес буенча чит ил китапханәләренә, татар ассоциацияләренә һәм иҗтимагый үзәкләренә тарата. ТР Мәдәният министрлыгының Традицион мәдәниятне үстерү республика үзәге «Түгәрәк уен» журналы аша чит илләрдәге милләттәшләребез белән аралашып тора, быел журналда Америкада һәм Кытайда яшәүче милләттәшләребездән килгән язмалар дөнья күрде. Киләчәктә «Чын мирас» журналына да бу юнәлештә нәтиҗәле эшләр теләп калам.

Әңгәмәдәш — Илдус Заһидуллин

А.Данилов фотосы

ТР Язучылар берлеге бинасы

БИНАЛАРДА – ТАРИХ ХӘТЕРЕ

РАНИЯ РАИМОВА,
архитектор-реставратор,
Татарстан Республикасының атказанган архитекторы

Мөштәри урамындагы 14 нче йорт — хәзерге Татарстан Республикасы Язучылар берлеге бинасы — Оконишников йорты буларак билгеле. Ул ТАССР Министрлар Советының 02.08.1990 елда чыккан 290 нчы Карары белән дәүләт саклавына алынган республика күләмендәге һәйкәл булып санала.

XIX-XX гасырлар чигендә Казан округының аралашу юллары начальнигы В.А.Макаров утар хуҗасы булган. Аның өчен кирпечтән 14 нче йорт салынган, проект авторы К.С.Олешкевич булган дигән фикер яшәп килә. 1909 елны В.А.Макаров йортны икмәк сатучы һәм тегермәнче улы Михаил Оконишниковка саткан. Моны йорт коймасы эчендәге кечкенә капкага чукылган «МО» вензеле дәлилли.

Совет чорында бу бина Лепскийның балалар клиникасы буларак билгеле иде. Лепский Ефим Моисеевич (1879-1955 еллар) — мәшһүр табиб, 1920 елны Губздрав әмере буенча институт клиникасы янында балалар хастаханәсе оештыра, озак еллар шунда эшли.

Соңгы елларда бинада Татарстан Республикасы Язучылар берлеге ур-

нашкан. Озак еллар дәвамында матди яктан тәэмин итү булмау сәбәпле, бинага су үтү, коммуникация өзелү кебек проблемалар һәйкәлнең торышына һәм конструкциясенә зыян китерә.

Подваллар чүптән чистартылды, соңгы араталар сүтелде, канализация системасы тәртипкә китерелде, дивардан һәм гөмбәзләрдән штукатурка алынды. Нәтиҗәдә, гөмбәзләрнең авария хәлендәге өлешләре табылды. Бик күп кенә бәхәсләрдән соң, авария хәлендәге гөмбәзләрне яңа монолит түшәмәгә алмаштырырга карар кылынды.

Проект буенча подвалдагы җайланмалар техник һәм хезмәт биналарына урнаштырылды.

Бу бинада камин, агач эшләнмәләрдән һәм чүкеп ясалган үзәк баскычтан торган интерьер уникаль санала. Аларны максималь рәвештә саклау һәм реставрацияләү төп бурычларның берсе булды. Тулысы белән түшәмәләрне алмаштыру беренче мәсьәләләрдән иде.

Бик күп кенә бәхәсләрдән соң, иске түшәмәләрне матчалар белән ныгытып саклап калырга дигән карар чыгарылды.

Әвәләп ясалган бизәкләрнең (лепнина) торышы канәгатьләндерерлек түгел иде: күпсанлы майлы буяу катламнары, нигездәге ярыклар, аерым өлешләрнең кителгән һәм җимерек булуы. Барлык бизәкләр майлы буяудан белгечләр тарафыннан кул белән җентекләп чистартылды, югалган фрагментлар һәм элементлар торгызылды, нигезләрдәге ярыклар капланды.

Имән паркет түшәлгән идәннәрнең торышы бик начар иде, аларны шундый ук сурәттәгеләренә алмаштырырга дигән карар кылынды, моның өчен һәр бинаның идәненә төгәл сурәт ясалды. Метлах плитәдән булган идәннәр урамнан керү ишеге төбендә һәм ишегалды ягы холлында сакланган иде. Башка биналарда плитә идәннәрнең торышы начар хәлдә иде, нигезе җимерелгән, плитә салдырып алып булмаслык хәлдә чатнаган. Нәтиҗәдә, өстәмә ишек алдында, баскыч мәйданчыкларында плитәнең зурлыгын, төсен, конфигурациясен саклап, яңага алмаштырылды (керамограниттан лазер белән плитә кисеп алынды).

Парад баскычның коймалары да урындагыча реставрацияләнде. Алар көйдерү юлы белән күпсанлы буяулардан чистартылды, югалган элементлар кайтарылды, грунт белән эшкәртелеп, соры-көмешсыманга буялды. Баскыч култыксасы ясалды. Баскычның түбән тумбасында кайчандыр факеллы кариатида образын гәүдәләндергән шәмдәл торган, кызганычка каршы, ул юкка чыккан.

Агач тәрәзәләр начар хәлдә иде, әмма коелган тоткалы матур бикләр яхшы сакланган. Алар салдырып алынды һәм цех шартларында реставрацияләнде, чистартылды, турайтылды һәм көмешсыман төскә буялды. Җитмәгән бикләр һәм механик юл белән ачыла торган тоткалар коелды. Башка тәрәзәләргә тарихи яктан стиле һәм төсе буенча якын булган яңа фурнитура сайланды, барлык тәрәзәләр профильләр, бүленешләр, төсләрне тулы саклаган хәлдә эшләнде.

Ишекләрнең сакланышы шулай ук начар хәлдә иде, кайберләре юкка чыккан яки совет чорында алмаштырылган. Булган ишекләр салдырылды һәм цех шартларында реставрацияләнде, ишек тартмалары үз урынында калды һәм ремонтланды. Интерьерлардагы 3 камин реставрацияләнде, аларның һәрберсе сәнгать әсәре булып санала.

2 нче кат балконында зур эшләр башкарылды. Балконның чүкеп ясалган һәм чуеннан коелган коймалары, башка эшләнмәләре реставрацияләнде (баганалар, койма, стропила, консольләр). Эшләр урында һәм цехта башкарылды.

Балкон өстендәге тарихи эшләнмә бик кызыклы, почмактан металл рама-

Фото А.Дубин коллекциясеннән

Балалар клиникасы. 60-70 нче еллар. Хәзерге Язучылар берлеге бинасы

ларга армирлы пыяладан (эченә металл челтәр урнаштырылган пыяла) пластиналар куелган. Бу этапта эшләнмәне торгызып булмады, консольләр буенча рәшәткә ясалган һәм металл табак куелган.

Фасадлар буенча лепнинаны чистарту һәм реставрацияләү эше башкарылды, өстәге баскыч култыксасы белән бәйле вазоннар, чүкелгән коймалар, су агызу бүрәнкәләре торгызылды, бинаның периметры буенча приямкалар өстеннән эшләнмәләр корылды. Төп керү ишеге өстендә чүкелгән япма реставрацияләнде. Ачык террасада да зур эшләр башкарылды: чүкелгән койма монтажланды һәм реставрацияләнде, яңадан диварлар күтәрелде, металл балкалар буенча түшәмәләр, баскычлар ясалды, терраса эшләнмәсе тротуар плитәләреннән ясалды. Террасаның чүкелгән тумбаларына ут үткәрелде. Бакчада фонтан чистартылды һәм торгызылды. Фонтан касәсе мозаик бетоннан эшләнгән кыйпылчыклардан гыйбарәт, алар чистартылды һәм тулыландырылды.

Территориядәге сукмак, яшел чирәм, күперчек, ут яктырткычлар төзекләндерелде. Йорт коймасы белән кечкенә өстәмә капкалы уникаль капка, бакча коймасы (декорлар юкка чыккан, металл деструкциясе) ныгытылды һәм реставрацияләнде.

Бинаның барлык чүкелгән әйберләре Чабакса тимерчеләре тарафыннан эшләнгән булган (Татарстан Республикасы Биектау районы Чабакса авылы). Тарихи язмаларда әйтелгәнчә, бакча уртасында юка итеп чүкеп ясалган ял итү урыны булган, бу көнгә хәтле ул сакланмаган.

Әлеге бина бөтенлеге ягыннан уникаль һәм кызыклы, ул хәзерге вакытка авторы ясаган беренче хәлендә килеп җиткән. Шуңа күрә реставрацияләгәндә төп бурыч булып бабаларыбыздан калган бинаны киләчәк буынга мөмкин кадәр оригинал халәттә саклау һәм җиткерү торды.

Русчадан
***Ренат Миңнегалиев** тәрҗемәсе*

ӘДӘБИЯТ

Милләтләргә бүлгәләсәләр дә
Шагыйрьләрне һәрбер гасырда,
Безнең ишеләрнең «милләте»
Шигърият бит, дуслар, асылда.

Хәсән Туфан

АРЫСЛАН ГАЛИМ

(Тарихи сәхифә)

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИН,
Татарстанның халык язучысы,
Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

АТЫ-ИСЕМЕ ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫНА ТАНЫЛГАН ЛЕВ НИКОЛАЕВИЧ ГУМИЛЁВ ҮЗЕНЕҢ БИОГРАФИЯСЕН ТӘҮГЕ СҮЗЛӘР БЕЛӘН БАШЛЫЙ: «МИН, НИКОЛАЙ УЛЫ АРЫСЛАН, 1912 ЕЛДА 1 ОКТЯБРЬ КӨННЕ ДӨНЬЯГА КИЛГӘНМЕН. БУ КӨНДӘ, ГАДӘТТӘ СИРӘК БУЛА ТОРГАН ХӘЛ — ЯБАЛАК-ЯБАЛАК КАР ЯУГАН.

Лев Гумилёв әнисе Анна Ахматова белән. Ленинград, 1960 нчы еллар

Мин үзебезнең Васильево утравында туганмын — бабам йортында, гәрчә атам-анам, туганнарым патша авылы Бежинцкида гомер итсәләр дә. Ошбу авылдагы зур булмаган әлеге өйне бабам күтәргән. Бабам үлгәннән соң, авыл халкы әбием кулына күчкән. Әбием табигате белән шул чиккә җитеп гади-садә иде ки, авылда яшәгән хатын-кызлар белән бер санда эшләгән, бер санда күңел ачкан, бер санда көн күргән, шул исәптән мин бахырыгызны да карап, күз-колак булып үстергән.

1917 ел вакыйгаларыннан соң әбием, мине алып, калага таба кузгала. Авыл халкы, бигрәк тә хатын-кыз крестьяннар, безне туганнарын озаткандай озатып калдылар. Әнә шулай без әбием белән күрше Беженцк каласына күчеп килдек. Бу шәһәрчектә без 10 ел яшәдек.

...Бүгенгәчә хәтеремдә калганы шул: бермәлне көтмәгәндә бу шәһәргә әтием килеп төште. Ул шулай искәртми генә ике-өч тапкыр килде. Миңа тарих һәм шигырь хакында — византиялеләрнең Италияне җиңүе турында тәфсилләп сөйләде. Шуннан соң әбиемнең: «Баланың башын катлаулы тарих белән катырма», — дип сукранганын хәтерлим. Әтием аны ишетмәгәнгә сабышты. Әбием янә: «Коля, нигә син балага шундый катлаулы китаплар бирәсең?» — дигәч, әтием аңа: «Вакыты җиткәч, ул барысын да аңлар, борчылма», — диде. Мин ары таба, чынлап та, әтием әйткәннәрне аңладым гына түгел, тәмам тарихка кереп чумдым. «Гераклның Арыслан» белән сугышуын кат-кат йотылып укып чыктым.

Ахыр, янә шуны әйтәсем килә, әтием миңа игътибарлы булды. Ул миңа укырга дөньяви шигъри китаплар калдырды. Киткәндә, әбиемнең күзләренә карап: «Яраткан китапларын укысын, кочаклап йокласын, тарих каһарманнары белән саташсын», — диде. Һәм мин көннәр буена күзләрем талганчы әтием калдырган китапларны укыдым. Әйе,

Лёва Ленинградта. 1926 ел

әтием тәмам күрәзәче булган икән — мин тарихчы булып киттем һәм бөтен гомеремне хак тарихка багышладым.

***

Әнием — Русиядә һәм хәтта чит илләрдә дә танылган шагыйрә — Анна Ахматованың нәсел җебе Алтын Урда ханы Әхмәткә барып тоташа. Әнием минем янга соңрак килде. Миңа 17 яшь тулган иде инде. Ул мине җитәкләп диярлек үзе белән Ленинградка алып китте. Биредә ашау мәсьәләсендә үтә кытлык иде. Мин үземә эш эзләдем һәм эзли торгач таптым — мине психик авырулар больницасына китапханәче итеп алдылар».

Укучымны искәртеп үтим, Ленинградта, Жданов Өлкә Комитетында утырган вакытта, шагыйрә Анна Ахматова тантаналы бер кичәдә заманча язылган шигырьләрен укый. Халык хуплап кул чаба. Шагыйрәне алкышларга күмәләр, аяк очларына көлтә-көлтә чәчәкләр ташлыйлар. Бу тамашаны залдан күзәткән Өлкә Комитеты секретаре Жданов кына түгел, экраннан күргән илбашы Сталин да гади халыкның шул чиккә җитеп шагыйрәне яратуына көнләшеп куя. Бу дәвердә ил халкы бары тик аны гына тантаналы төстә

алкышлап каршы алырга тиеш булган икән... Һәм күп тә үтми илбашы Өлкә Комитеты секретаре Ждановка искәртә: «Узындырма шагыйрәне». Кыскасы, шагыйрә Анна Ахматованы һәм Ждановның үзен дә кисәтеп, бары тик бер сүз әйтә: «Чарасын күр...» Күп тә үтми шагыйрәне Язучылар берлегеннән чыгаралар, шигырьләрен бер генә газета-журнал да басмый, француз теленә улы тәрҗемә иткән шигырьләрен дә чит илләргә җибәртмиләр. Талантлы шагыйрәнең хәтта яшәгән фатирына түләргә акчасы да калмый. Ачлы-туклы яши...

***

«Нәкъ менә шул елларда мин беренче тапкыр хезмәт яздым, — дип каләмен тибрәтә үз истәлегендә Арыслан галим. — Һәм бу хезмәтем белән кулъязмада ук танышкан тәүге укытучым Михаил Иванович Артамонов игътибарына лаек булдым. Ул мине Эрмитаж китапханәсенә эшкә чакырды. Карусыз ризалаштым. Ул минем тәгаен укытучым булып китте, миңа биредә укырга-язарга бөтен шартларны тудырды. Эрмитажда төпләнеп эшкә кереп киткәч, үзе белән көнчыгыш тарафларында төрки-татарлар яшәгән төбәкләргә экспедициягә алды. Бу елларда гүя миңа канат үсте. Мин аның белән бер санда йөрдем, тәмам иңдәше, киңәшчесе булып киттем. Укытучым көнчыгыш халыклары турында «Хазары» дигән зур хезмәт язган булып чыкты. Иң сәере шул: укытучым бу хезмәтен, нигәдер, әүвәл миңа укырга, ары таба хәтта редакцияләргә бирде. Төннәремне йокламыйча, укытучым хезмәтен янәдән укып кына калмадым, бераз редакцияләп тә чыктым. Ахыр, ошамаган җирләре хакында аңа үз сүземне әйттем. Ул башын чайкап торды да: «Син укыдың, син редакцияләдең, мин сиңа ышанам, хезмәтемне басмага да хәзерләп бирәсең», — дип иңемнән кочып алды. Үзем күзаллаганча хезмәткә кереш сүз яздым. Ул минем тәүге «Хунны» хезмәтемне укыды һәм «Хунны» һәм «Хунны в Китае» исемле хезмәтләремнең галимнәрнең гыйльми советында каралачагын әйтте. Әнә шулай мин — гади китапханәче — Көнчыгыш халыклары тарихына караган зур булмаган, ләкин игътибарга лаек хезмәт язганмын булып чыкты.

***

Олуг галим Арысланның төрки-татар тарихына караган хезмәтләрен тәмам киртәләр аша чыгарып, иләктән иләп, зур кыенлык белән бассалар да, ул соңгы көненә кадәр бу могҗизаи фәнгә тугры кала. Үҗәтлек белән төрки-татар халыкларының хак тарихын язуын дәвам итә. Арыслан галим бер халыкка да, бер милләткә вә этноска да тәлинкә тотмый, дөньяга карашы белән генә түгел, яшәү рәвеше белән дә хак тарихка йөз тота. Ул хәтта Русиянең Б.Рыбаков кебек академикларын да тәнкыйтьләмәде, бары тик шул дәвердәге галимнәрнең сәясәткә ярашып язылган үз сүзләре белән бәян итеп, укучыга аларның төп «максатын» аңлатып бирә алды.

Менә алар — революциягә кадәр булган классиклар — В.Н.Татищевтан алып Г.М.Плехановка кадәр дияргә була, тарихны бертөрле итеп язалар. Иң гаҗәбе: төп дошманнары — татарлар һәм аларның бабалары.

Әйтик, Татищев бу хакта болай дип яза: «...половцы и печенеги... русским пределам набегами, пленяя и грабя, великие вреды наносили»; Н.Карамзин исә: «Половцы — неутомимые злодеи», мир с такими варварами мог быть опасным перемирием»; Н.Г.Устрядов: «Половцы — лютые злодеи»; С.М.Соловьев: «Русь... должна была вести борьбу с жителями степей»; Н.И.Костомаров: «Полчища степных кочующих народ... жадных к грабежу и истреблению»; Н.А.Рожков: «Наибольшая опасность для древнерусского государства степняки — половцы» h.б.

Әнә шулай Русия галимнәренең кинәнә-кинәнә бабаларыбызны гаепләү-

ләренә ияреп, без бахырыгызның замандашы — В.Чивилихин татарлар турында кирпеч калынлыгы роман-эссе язды. Арыслан бабай Чивилихин кебек язучыларга рәнҗеде, чөнки бу елларда В.Чивилихинның әсәре китап итеп басылган һәм зур тираж белән укучыларга җиткән иде инде. Галим А.Кузьмин аның бу әсәренә рецензия яза һәм роман-эссене күккә күтәреп мактый. Бу хәл-гамәл дә Арыслан галимнең тәмам кәефен кыра. «Кая монда хак тарих, кая монда гаделлек?» — дип зарлана. Роман-эсседа үзәгендә, нигездә, һаман шул бер балык башы — «татарское иго» кабатлана. Бу хәлгә инде Арыслан галимнең тәмам ачуы кабара. Роман-эсседә тарихны бозып күрсәтү, үткән дәверләребезгә гадел бәһа бирмәү өстенлек итә дип, 1982 елда «Коммунист» журналы редакторы Р.И.Косолаповка үтенеч рәвешендә хат язарга кыя. Хатта түбәндәге сүзләр: «Хөрмәткә ия Ричард Иванович! Партиялеләр сафында булмасам да, Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Мөрәҗәгать итүемнең төп сәбәбе — нигездә, тарих фәннәре докторы Аполлон Кузьминның «штат тәнкыйтенә карата» үз фикеремне Сезгә җиткерү. Мәгълүм булганча, күптән түгел, язучы В.Чивилихинның «Память» романэссесы халыкка таралды. Ул анда мин бахырыгызны «кыйнаган», ә роман-эссега А.Кузьмин күпертеп рецензия язган, ягъни Л.Гумилёв бакчасына яман сүзләр әйтә-әйтә, таш аткан. Имеш, Чыңгыз белән Батый Русиягә «иго» китерәләр. Әйтик, Чыңгыз һәм Батый А.Кузьминга һәм В.Чивилихинга ошамый ди, ләкин бит ил халкы әйбәт кешеләрдән генә тормый. В.Чивилихин һәм А.Кузьмин да, мөгаен, бар кешегә дә ошамыйдыр. Шуңа карап, бөтен рус халкын һәм хәтта мәскәүлеләрне яман халык дип язарга ярар иде микән?.. Ул гынамы, әгәр дә теге йә бу халык кына түгел, теге йә бу кеше безгә ошамый икән, русларны һәм хәтта мәскәүлеләрне начар халык дип язу дөрес булыр микән? Бу ике кеше барлык Русь халкының һәм тарихчыларның ихтыяҗын канәгатьләндерә алмыйлар икән, Чыңгыз хан һәм Бату хан исә бөтен монгол халкының ихтыярын үтәүчеләр булып чыгалар бит... Аларны бертавыштан хан итеп корылтайда сайлыйлар. Инде татар-монгол яуларына килсәк, татар-монгол сугышчылары, нигездә, ярты миллион кешедән җыелган яугирләр, ягъни бары тик ил халкының бер өлешен генә тәшкил иткән сугышчылардан торган. Әнә шул яугирләр миллионнан күп тапкыр артык халкы булган Русьны, Кытайны һәм Иран белән бергә бөтен бер Урта Азияне кул астына җыялар, ягъни яулыйлар... Сезгә янә искәртеп үтим, монголлар бу дәвердә өч төбәктә сугышалар — Кытайда, Иранда һәм Идел буе кыпчаклары белән. Олуг хан тарафыннан бу илләргә таба өстәмә гаскәр җибәрү мөмкин булмаган да булмаган. Иң гаҗәбе, А.Кузьмин үзен Ил патриоты итеп күрә, «...ә борынгы русларны йомшак-куркак халык, нәкъ менә куркаклыклары белән алар безне шул көнгә калдыралар», дип яза хөрмәткә ия Ричард Иванович...» Арыслан тарихчы бу хакта кинаяләп: «...позволили погубить себя столь слабому противнику...» дип тә өсти.

Кыскасы, бу дәвердә Арыслан галимгә яла ягучылар шактый була. Һәм Арыслан галим үзе дә журнал редакторына: «...гөнаһсыз кеше юк», — дип искәртә. Шуңа карамастан Л.Н.Гумилёвның «Этногенез» хезмәтенә кереш сүз язган профессор Р.Итс Арыслан галим хакында болай дип яза: «Исләр китмәле! Укыйсыңукыйсың да хезмәттәге фактларны янәдән тикшерәсе килә һәм авторга инанасың — Гумилёв хак тарих язган!» Һәм дәвам итә: «Ил түрәләренә, Ил тарихчыларына һәм этнографларына, аеруча Арыслан галимгә һәр өлкәдә һәйкәл куярга кирәк иде. Ә киртә өстенә киртә тезмәскә...»

Хак бәһа. Нәкъ менә Арыслан тарихчы Русиянең хак тарихын язарга кереште, аңа кадәр Русиядә коры һәм күңелгә ябышмый торган хезмәтләр

язып яткан «сорыкортларга» бик салып, саллы хезмәтләренең бары тик уннан бер өлешен генә дөнья халыкларына җиткерә алды…

Тарихка кереп калган мондый юлларны да укырга була: «Әйе, бик күпләргә Чыңгызхан һәм Батый хан да ошамый, шул исәптән А.Кузьмин һәм В.Чивилихинга да — тик бит алай булмый һәм була да алмый. Чыңгыз һәм Батый ханнарны да гаепләп булмый. Алар икесе дә, нигездә, монгол халыкларының уй-теләген тормышка ашырганнар, ягъни корылтай чыгарган карарга буйсынганнар. Бу хәлгамәл дә барыбызга таныштыр кебек миңа… Нигездә, татар-монголлар бу дәвердә өч фронтта сугышалар: Русьта, Кытайда һәи Урта Азияне яулыйлар. Ягъни татар-монголлар өч төбәктә канлы сугыш алып баралар — Кытайда, Иранда һәм Идел буе Болгарында… Шуның өчен Каракорым түрәләре аларның барысына да, әлбәттә, ярдәмгә яугирләр җибәрә алмаганнар да алмаганнар, чөнки мөмкинлекләре чамалы булган. Минем өчен иң гаҗәбе шулдыр: А.Кузьмин патриот буларак, бу хәлгамәлдә һәм начар мәгънәдә борынгы бабаларыбызны гаепли. «Имеш, алар, нәкъ менә алар харап итәләр Русияне. Имеш, бабалары көч-куәтләре түбән булган татар-монголларга биреләләр», — дип тә өсти. «Коммунист» журналы редакторына язган хатында.

***

Үзенең күпсанлы һәм саллы хезмәтләрендә төрки-татар халыкларының асыл тарихын яктырткан олуг галим Лев Николаевич Гумилёв раслаганча, Идел буе татарларының тарихы, Алтай төркиләренә барып тоташса да, 632 еллардан — Җиһангир Атилла ханның дәвамчысы булган Кубрат хан бабабыздан башлана. Ахыр, мөхтәрәм галим миңа болай диде: «VII гасырда Кубрат хан көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып Таман ярымутравында дәүләт төзи. Әгәр дә мәгәр бабагыз Кубрат хан турында әсәр язарга ниятләсәгез, җәяүләп дисәм дә ярыйдыр, гаиләң беләнме Таман ярымутравына сәяхәт кыл. Кодрәтле бабагыз Кубрат хан тәүге тапкыр ил-җир биләгән төбәкне үз күзең белән күреп кайт. Әйе, әсәрең хаклыкка йөз тотсын дисәң», — дип васыятьнамә әйткән иде. Һәм галим хаклы булып чыкты. Мин үз машинам һәм гаиләм белән Кубрат хан биләгән төбәкләрдә булып, ул салган вә күтәргән Тимерүк каласын күреп кайттым. Борынгы Идел буе Болгар дәүләте дә Батый хан татарларына кадәр шул исем-атама белән тарихка кереп китә.

Әйе, галим хаклы иде. Ул хәлгамәлләр нәкъ Арыслан галим әйткәнчә була. Үзенең иш вә канкардәшләре белән 640 нчы елларда Кубрат хан илҗирләрен киңәйтергә ниятли. I-II гасырларда ук Идел-Урал елгалары буена килеп утырган хун-төрки кардәшләре белән элемтәгә керә һәм берләшү максаты белән шул төбәккә урдасы белән икенче улы Кодракны җибәрә. Яшь хан Кодрак бередә канкардәшләре белән бергә Идел буе Болгар дәүләтенә нигез ташын сала. Өченче улы Аспарух Дунай буйларына юнәлә һәм бүгенге Дунай буе болгар дәүләтен нигезли. Өлкән улы Батбай атасы төбәгендә кала. Дүртенче улы Балкыр Карачәй-Балкыр төбәкләренә юнәлә һәм анда төпләнеп кала… Бертуган энесе Шамбатны яугирләре белән Киев тарафына таба җибәрә. Бу хәл-гамәлләрне хәтта Византия императоры Константин да үз хезмәтендә искәртә. Болар барысы да безнең тарих. Һәм боларның барысын да Арыслан галим Лев Николаевич үз хезмәтләрендә төпле дәлилләр белән раслый. Тагын да тәгаенләбрәк язсак, Идел буе Болгарын Батый хан яулый. Болгар ханы Илһам монголларны бер тапкыр җиңгән була инде, шуңа күрәме, тәкәббер кылана, канкардәшләре белән

аралашмый — баш бирми. Батый хан илчеләрен кабул итми, ил-дәүләтен саклап, каһарманнарча сугыш кырында ятып кала. Бу да без — татарларның тарихы ич!..

***

Туксанынчы елларда «Кубрат хан» романымны тәмамладым. Нәкъ шул елларда Лев Николаевич Гумилёв Эрмитажда өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли иде. Олуг һәм мәртәбәле галим евразияле Пётр Савицкий белән хат артыннан хат алыша. Чит илдә көн күргән олуг галим аңа: «...изучать эпоху Чингиза надо с хуннов, через тюрок и киданий», — дигән киңәш бирә. Шуны искә алып, ниһаять, Арыслан галим евразияле Николай Трубицкий сүзләре белән аңа болай дип яза: «...ни один нормальный народ в мире, особенно народ, организованный в государстве, не может добровольно допустить уничтожение своей национальной физиономии во имя ассимиляции, хотя бы с более совершенным народом». Һәм шул сүзләрне укыгач, укытучым җилкәмә кулын куеп, болай дип өстәде: «Вот вам будущим историкам весь сказ, дорогой мой Мусаит. Понять, что ни «я», никто другой не есть пуп земли, что все народы и культуры равноценны, что высших и низших нет, — вот всё, что требуют мои книги от читателя». Тарихи әсәрләр язучы буларак, мин бахырыгыз да мөхтәрәм галим сүзләренә тугры калдым дип уйлыйм. Бабаларыбыз тарихына шактый иҗатымны багышладым. Һәм булдыра алган кадәр хак тарихка йөз тоттым.

Олуг галим белән тарих турында әңгәмә барганда, ул шкафтан үрелеп Хара Даван китабын алды. «Менә гапгади этностан чыккан галимнең хезмәте. Мин сиңа аны бүләк итәм. Укы, өйрән, хәтереңне бает», — диде. Һәм үзалдына сөйләшкәндәй болай дип өстәде: «Интересно, кто такой Э.Хара Даван?..» «Ни өчен СССРда аның хезмәтен басалар, укыйлар, ә евразияле классикларны ялгышып та искә алмыйлар, хезмәтләрен дә басмыйлар?..» — дип үртәлеп тә куйды...

Үз хезмәтендә Арыслан бабай калмык галиме хакында болай яза: «Бик күп халыкларның кавемнәр бишеге, ил-халыкларны яулау туфрагы, миф вә әкияти могҗизалар иле, дөньядагы барлык диннәрнең анасы, миллиардка якын халыкларның нигез ташы — әнә нинди могҗизаи җир ул тарихчы галим Хара Даван өчен — Азия. Ул гынамы, Монгол империясенең биеклек ноктасы... Чыңгыз ханның бөеклеге. «Кем белән чагыштырып була Чыңгыз ханны?» дип үз-үзенә сорау куя Хара Даван. Наполеон беләнме?.. Юк. Наполеон бер гаскәрен Мисырда ташлап калдыра, икенче гаскәрен карлы-буранлы Русиядә. Аның империясе үзе исән вакытта ук юкка чыга. Бөек Александр Македонский беләнме?.. Юк. Ә бит хәтта Чыңгыз ханның оныгы империяне бернинди каршылыксыз, үз кул астына ала — Әрмәнстаннан Кореягә кадәр һәм Мисырдан Идел буйларына җитеп чик күтәрә. Шуның өчен, Хара Даван язганча, кыска гына вакыт эчендә бик күп илләрне вә халыкларны кул астына җыя. Тарихчы Хара Даван кыю рәвештә болай ди: «Чыңгыз хан — җир шары халыкларының императоры...»

Хара Даван хезмәтен укыгач, Арыслан бабай шундый нәтиҗәгә килә: «Миңа калса, безгә, кытайлар язган гипнозлы елъязмалардан баш тартып, төркиләр күзлегеннән карап, хак тарихка йөз тотарга вакыт». Мин бахырыгызны кинәндереп, үз фикерен әйтте...

Ары таба миңа булган «дәрес»ен: «Хара Даван нindидер дәрәҗәдә хаклы, Көнчыгыш һәм Көнбатыш дөньясын төркиләр бәйләде. Мин — рус кешесе — гомерем буена татарларны бер гаепсезгә рәнҗетүдән якладым», — дип дәвам итте һәм чәй өстәле янына әйдәде.

***

Тарихчы олуг галим Арыслан бабай тарихның кискен борылышының 1260 елдан башланып китүен беркемгә дә иярмичә, нәкъ үзе уйлаганча аңлый һәм уй-фикерләрен фәнни рәвештә үзенчә раслый — төркиләрнең булган вә кылган хәл-гамәлләреннән күреп, нәкъ шул елда тарихта «сила вещей» дигән кискен борылыш башлана — Византиянең культурасы җир белән тигезләнә — мөселманнар христианнарны үтерәләр һәм диннәрен шактый илләргә таратуга ирешәләр. Көнчыгыш илләре христианнары ислам кабул итәләр. Көнбатыш уйга кала һәм чара күрергә керешә. Китә бер-берсенә яла ягу, бер-берсен гаепләү һәм халыклар арасында бер-берсен яманлау башлана, ягъни, Арыслан бабай язганча, «чёрная легенда» аякланып китә. Шундый нәтиҗә өскә калкып чыга: монголлар — монголлар түгел икән, алар татарлар икән ләбаса!.. Әнә шулай бу дәвердә татарларга һич булмаган яман гаеп-яла тагыла — иң әүвәл Идел буе болгарлары төркиләренә, ары таба мордва, тунгус, якут һәм хәтта Алтын Урда кул астында булган русларга да чаткысы җитә. Чөнки «чёрная легенда» идеясе нәкъ менә руслар аша чын мәгънәсендә «чёрная легендага» әверелеп китә…

«Чёрная легенда» яу-ялганы 500 ел эчендә тамырын бик тирәнгә җибәрә, хәтта ары таба «евроцентризм»га әверелә, тәмам чәчәк ата. Дөнья халыклары арасында Русиянең артта калуы, бер урында таптанган Кытай һәм Һиндстан аерым билгеләп үтелә. Күңелгә кара тап булып яткан этносларны кыргыйларга яисә примитивныйларга һәм цивилизованныйларга бүлү башлана. Бу хакта Европадан чыккан колонияләрдә яшәгән чиновниклар аеруча нык тырышалар… Әмма Арыслан галим бу хәл-гамәлгә үз сүзен кистереп әйтә: «Әйе, бер милләт, бер халык та безне Ходай сайлады, дип әйтә дә, яза да алмый. Нинди милләт кенә үзен безне Аллаһ сайлады дип шапырынмасын — немец, япон, яһүд — бу хәл-гамәлнең, ягъни милләтчелекнең асыл ташы — эгоизм, күркә кебек кабарыну — барысы да итагатьсезлек вә милли гариплек».

Этнослар турында сүз кузгалдымы, исемле галимнәр һәрдаим Арыслан галимне телгә алалар. Европада узган «Этногенез» секциясендә бәхәс куба. «Кем оста һәм аңлаешлы итеп яза бу фәндәге четерекле мәсьәләләрне? Утырышта катнашкан этногенез галимнәренең шактые беренче урынны тарихчы В.В.Бартольдка бирәләр. Шул мәлдә этногенез җыелышын алып барган рәис-профессор Р.Итс торып баса да, барысын да аптыраошта калдырып: «Мин беренче урынны этнолог Лев Николаевич Гумилёвка бирәм», — ди.. Һәм чыгыш ясый: «Шаккатмалы хәл: укыйсың-укыйсың да Гумилёвның этногенезга багышланган хезмәтләрен — торып-торып гаҗәпләнәсең — фактларны яңадан тикшерәсе килеп китә, тикшерәсең һәм янәдән инанасың — Гумилёв хаклы, Гумилёв өстен». Хәтта тарихта булган гыйбрәтле мисаллар китерә… «Әйтик, крестоносецлар заманында 1370 елда указ нигезендә Лиможа каласы халкын суеп чыгарга боерган Кара Принцны кем дип атарга?! Ә бит бу «явыз җан» Англиянең милли каһарманы булып тарихка кереп калган. Исләр китмәле!.. Кайсы этностан була ул галиҗәнапларым?.. Юк, татар булмаган да булмаган Кара Принц…»

Сикәлтәле елларны үтә-үтә сөрген мәхшәрләрен татыган олуг галим Арыслан Николай улының тарихи хезмәтләре — мәңгелек елъязма — татарларның хак тарихы, шул исәптән унҗиденче гасырларда гына куәтләнеп киткән Русиянең дә. Әйе, күлләр кибә, челтерәп аккан чишмәләрдән куәтләнеп киткән елгалар эзләрен югалта — әмма әнә шул мәхшәрдә татар исем-аты белән тарихка кереп калган халык яши һәм яшәячәк!.. Шул исәптән укучылары күңелендә мәңгелек хатирә-истәлек булып калган Арыслан галимнең гаять бай хезмәтләре һәм гыйбрәти хак тарихы да… ■

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

ХӘСӘН ТУФАН

(09.12.1900 — 10.06.1981)



ГОМЕРЕМ ЮЛЫ

Зирәк, кыю, чая, чыдам илем,
Сиңа бит бер сүзем бар минем, —
Йә үлемемдә шуны, йә теремдә
Искә ал идең:

Әйтә алсаң әгәр берәр көндә:
«Чат үзем, – дип, – минем бу улым!» —
Бу дөньяның бөтен бәясеннән
Кыйммәт миңа шундый булуым.

Шул бәяңә лаек булса гомерем,
Бүтән берни, берни кирәкми, –
Саф рәхмәттән койган бүләк булып
Бу яшәүне тик шул бизәкли.

Һәр эшне мин
Башкарам тик бары
Синең өчен кирәккә күрә;
Кирәк төштә утка-суга кердем
Бата-чума һәм яна-көя.

Йөрәгемне, илем,
Кул кылмаган
Саф рәхмәтең синең иркәли.
Дулкынланып шулай, канатланып
Үтеп барам гомер үтәли.

Һәлакәтләр юлда очрый калса,
Кирәк булса корбан булуым,
Дөнья сиңа әйтә алыр, илем:
«Үзең кебек иде бу улың!»

Сиңа, илем, антым бу минем,
Мин тик шуны әйтмәкче идем.

1956

---

*Шагыйрь Хәсән Туфанның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

ШӘРЕКЪ РЕНЕССАНСЫ

РЕЗЕДА ГАНИЕВА,
филология фәннәре докторы

Галимнәр һәр замандагы, һәр халыктагы Яңарыш канун төсен алган ике алшартның үтәлешен мәҗбүри дип таныйлар: алдагы үсеш баскычындагы аеруча әһәмиятле дип саналган милли-рухи кыйммәтләрне тергезү һәм торгызу; башка мәдәниятләр казанышлары хисабына «кан яңарту». Моңа омтылыш гарәпләрдә Коръәне Кәрим мәйданга чыккан һәм гамәлгә кергән елларда ук башлана. Алар үзләренең милли Ренессансы нигезенә бәдәвият дәверендәге традицияләрне, ачышларны кабул итү белән бергә, үзләренә көчле дулкын булып бәреп кергән грек-йунан фәне, фәлсәфәсе, сәнгате тәэсиреннән дә баш тартмыйлар. Пакъстанның атаклы мөселман шагыйре, философы Мөхәммәд Икъбаль «элгәреге мөселманнар Коръәнне греклар фәлсәфәсе яктылыгында укыдылар»; атаклы галим К.Беккерның «гарәп фәлсәфәсе — гарәп хәрефләре белән язылган грек философиясе», «Искәндәрдән (Александр Македонский) башка Мөхәммәд юк», диюе ислам мәдәнияте буенча күренекле белгеч, америкалы Г.Э.Грюнебаумның «мөселман цивилизациясе — һәм мәдәни, һәм социаль аспекттан чыгып караганда, антик һәм эллинизм үсешендәге бер ботак (тармак)», дип дәлилләве дә югарыда әйтелгән фикерләрне расласа кирәк [1]. Шул ук Г.Э.Грюнебаумның Әфләтүн (Платон), Арасту (Аристотель) карашлары, аеруча «неоплатонизм фәлсәфәсе Коръәннең бик үк теләп кабул ителмәгән юлдашына әйләнде» дигән фикере белән дә килешәсе килә. Галимнең әйтергә теләгән төп фикере түбәндәгедән гыйбарәт: ислам цивилизациясе Урта диңгез буендагы грек һәм җирле культураларның гаҗәеп тә җитез һәм оста трансформацияләнгән, йунан антикасы белән шәрекъ мәдәниятләренең үзара керешкән һәм тыгыз береккән эллинизм дәверенең турыдан-туры дәвамчысы булып тора.

Шәрекъ Ренессансының куәтле һәм тизләтелгән үсеш кичерүенә VII гасырдан башлап гарәпләр арасында тәрҗемәчелек эшенең киң колач алуы да зур этәргеч була. Грек мәдәниятен ихтирам иткән Мәмүн хәлифә 832 елда Багдадта «Гыйлем йорты» ача, Византия императоры белән килешү төзеп, аннан грекча төрле фәннәргә караган бик күп китаплар алдыра, аларны гарәп теленә тәрҗемә итү эшен оештыра. X гасырда грекчадан гарәпчәгә тәрҗемәчеләр арасында чыгышлары белән Идел буе Болгарстаныннан Хәсән Сувар (942-1017) кебек укымышлылар булганлыгы да мәгълүм.

Тәрҗемәләр мөселманнарның йунан фәннәре һәм фәлсәфәсе белән танышулары, үз мәдәниятләрен үстерүдә нәтиҗәле файдаланулары турында «Борынгы ислам мәдәнияте» (1909) дигән хезмәтендә Галимҗан Ибраһимов та язып калдыра. Антропо-

центристик карашлар белән сугарылган грек фәлсәфәсенең мөселманнарга зур йогынты ясавын совет чоры татар галимнәре дә таныйлар. Мәсәлән, бу хакта профессор Х.Госман болай ди: «Гарәп-фарсы антик мәдәниятләр, бигрәк тә грек мәдәнияте, рухи мирасын актив рәвештә иҗади кабул итә һәм үзенә яраклаштыра: грек фәне һәм сәнгате казанышларын өйрәнә. Алдынгы карашлы фикер ияләренең һәм сәнгать әһелләренең табигать һәм иҗтимагый тормышка, беренче чиратта, кеше шәхесенә карата мөнәсәбәте грек фәлсәфәсе карашлары белән сугарыла» [2].

Әйткәнебезчә, Шәрекъ Ренессансының нигез ташларын салуга гарәпләрнең күршеләре — Борынгы Грециянең ике даһи философы Әфләтүн (Платон) белән Арасту (Аристотель) бәһаләп бетермәслек өлеш кертә. Аларның фәнни-гыйльми, фәлсәфи хезмәтләрен гарәпчәгә тәрҗемә итү мөселманнарның һәм дини, һәм дөньяви Яңарышын хәзерләшүдә бетмәс-төкәнмәс хәзинәгә әверелә. Бүгенге көндә дә Платонның Көнбатыш сәясәтчеләре, философларының өстәл китабы булып саналган «Дәүләт» исемле хезмәтендәге универсаль эчтәлекле Гаделлек теориясе, Аристотельнең Акыл турындагы тәгълиматы урта гасырлардагы мөселман Яңарыш философлары һәм шагыйрьләре тарафыннан бик тә үзителә, бөек рухи кыйммәтләр буларак иҗади үзләштерелә, бу хакта күпсанлы фәнни трактатлар языла (әл-Кинди, Фараби, Ибн Сина, Ибн Рөшд, Й.Баласагунлы һ.б.). Платон «Дәүләт»ендәге үзәк фикерләр Ренессанс дәвере кичергән фарсы һәм төрки әдәбиятларның да байтак әсәрләрендә сәнгати чагылыш таба (Й.Баласагунлының «Кутадгу билиг», Низами, Нәвои, Җами, Дәһләвиләрнең Искәндәр турындагы поэмаларында).

Ислам дөньясында Аристотель хезмәтләренә ихтыяҗ аеруча зур була. Идел буе болгарларына алар бик иртә — VIII гасырда ук килеп ирешә. Кеше акылы тудырган могҗиза дип югары бәяләнгән Аристотель логикасы, бу хактагы хезмәтләр — философ-неоплатоник Порфирий аңлатмалары белән бирелгән текст кыпчак бабабыз Фараби тарафыннан төзәтүләр, өстәмәләр белән гарәпчәгә күчерелеп, «Китаб әл-мантыйк» исеме белән мөселманнар арасында киң таралыш таба. Дөньяны танып белергә, уйларга, төпле, төгәл, ачык фикер йөртергә өйрәткән Аристотель логикасы, бигрәк тә аның «Исагоге» — «Исагуҗи»е XX гасыр башында да татар мәдрәсәләрендә дәреслек вазифасын үтәвен дәвам итә. Андагы силлогизмнар мәдрәсәдән мәдрәсәгә йөреп, фәнни бәхәсләр, ярышлар, сүз көрәштерүче моназарәче шәкертләр пәйда була. Аристотельнең теологик логикасыннан хәбәрдар булган, дискуссия-бәхәс барышында каршы якны төп башына утыртырга омтылган моназарәче шәкертләр образы XX гасыр башындагы татар әдәбиятының байтак әсәрләрендә (бигрәк тә Г.Исхакый, Г.Ибраһимов иҗатында) чагылыш таба. Арасту логикасы ислам теологиясендәге кәлям гыйлемендә [3] мөтәкәллимнәр [4] һәм могтәзиләләр [5] дигән юнәлешләрне тудыруда, аларның асыл сыйфатларын билгеләүдә зур роль уйный. Бу хакта «Шура» журналында гарәп әдәбияты мәсьәләләре буенча мәкаләләр циклы бастырган «Г.Д.Р.Н.» (автор криптонимы) болай ди: «Гарәп фәйләсуфларының Ислам тәэсиреннән бөтенләй мөстәкыйль уларак Арасту фәлсәфәсен ихтирам итүләре вә аңа бетмәс-төкәнмәс шәрехләр язулары илә бәрабәр, дин тәэсире илә «Ислам схоластикасы» [6] да пәйда булды. Хакыйкый (чын) фәйләсуфлар кеби, схоластиклар да ике зур фиркага бүленә иделәр. Куәтлерәк вә тарафгяре (тарафдарлары), күбрәк булган кыйсеме (өлеше) хакыйкатькә бәхәс

вә моназарә (сүз көрәштерү) васитасы (ысулы) илә җитешергә өмид итеп, шушы юлда бардылар. Болар «мөтәкәллимун» исәпләнәләр. Бер юл әһле — әһле сөннәттән әшгарыйлар илә могтәзиләләр»дер. Могтәзиләләр игътикад (инану) һәм нәзарларын (уйфикерләрен) күбрәк гакыл вә хикмәткә (фәлсәфә) әсас (нигез) коралар, ягъни рациональный юл тота иделәр» [8].

Платон, Аристотель һ.б. грек философларының хезмәтләрен гарәпчәгә тәрҗемә итү, иҗади үзләштерү нәтиҗәсендә, әл-Кинди, әл-Фараби, Ибн Сина, Бахманъяр, әл-Бирүни, Имам Газзали, Ибн Баҗҗа, Фәхреддин әр-Рази, Шиһабеддин әс-Сөһрәвәрди, Ибн Тәймийә, Ибн Төфәйл, Ибн Гарәби, Ибн Хәлдун кебек мөселман Яңарыш галимнәре һәм философларының эшчәнлеге башлана, мөселман аристотелизмы һәм мөселман неоплатонизмы кебек куәтле фәлсәфи юнәлешләр мәйданга чыга.

Сүз дә юк, бу ике фәлсәфи юнәлеш арасына кытай дивары корып кую мөмкин түгел. Берьяктан, аларның илаһиятне, галәмне танып белүдә үзләренә генә хас асыл сыйфатлары булса, икенче яктан, бер-берсен чит күрмичә, үзара керешү, берегеп үсү, охшашлыклар булу да күзгә ташлана иде. Илаһиятне, Галәмне танып белүдә, яшәешне аңлатуда мөселман арастучылары (икенче төрле исемнәре — перипатетиклар, рационалистлар, могтәзиләләр) акыл культына басым ясасалар, яңа әфләтүнчеләр исә неоплатоникларча «акыл белән береккән җанны — рухны» (Ибн Сина) гәүдәләндерүне өстен күрделәр. Бу фәлсәфи юнәлешләрнең һәр икесе Шәрекъ Ренессанс әдәбиятларына зур йогынты ясый. Күп кенә Шәрекъ Яңарышы философлары грек-эллиннарның, һинд, фарсыларның фәлсәфә, сәнгать өлкәсенә караган хезмәтләрен һәм дә әдәби әсәрләрен гарәпчәгә тәрҗемә итү, аларга шәрехкомментарийлар бирү өстенә, үзләре дә әдәби иҗат белән шөгыльләнгәннәр, шигырь һәм музыка теориясе буенча трактатлар язганнар.

Чыгышы белән гарәп, бу милләтнең беренче мәшһүр философы — Ягъкуп бине әл-Исхак әл-Кинди (800-879). Ул арифметика, геометрия, астрономия, космография, табигать белеме, медицина, сәясәт, юриспруденция, логика, музыка, нәфес (рух), мәгърифәт һ.б. фәннәр буенча 200дән артык хезмәт язган. Аныңча, хакыйкатьнең чыганагы кайда гына булмасын, аны эзләп табарга, кабул итәргә, чынбарлыкны танып белүдә файдаланырга кирәк. Әл-Кинди Птоломей, Евклид хезмәтләрен яхшы белгән, Аристотель әсәрләрен яратып тәрҗемә иткән, бик күп фәнни хезмәтләрнең мөхәррире, мөселман аристотелизмына нигез салучы булган. Әл-Кинди философияне табигать фәннәреннән аерып карамаган, барлык фәннәрдән мәгълүматлы булуны, аеруча математиканы яхшы белүне кешеләр өчен мәҗбүри бер шарт итеп санаган. Гарәп хәлифәлегендәге мөселманнар арасында антик дәвер казанышларын әт-Тәүхид фәлсәфәсе күзлегеннән яңартып, киң гамәли кулланышка кертү юнәлешендә галим аеруча зур тырышлык күрсәтә. Аллаһы Тәгаләнең Берлеге, барлыгы турындагы карашларны да Әл-Кинди Арастуның Берлек (Единое) фәлсәфәсендәгечә рационалистик карашларга таянып аңлата. Аныңча, абсолют илаһи гыйлем Аллаһы Тәгаләдә генә, фәлсәфәчеләр аның асылына төшенеп бетә алмыйлар. Коръән — илаһи ачышларның иң югары ноктасы. Әл-Кindинең акыл турындагы хезмәтләре, аңа биргән классификациясе Европаның яңа заман философиясе үсешенә, аеруча Рене Декарт (1596-1650; латинлаштырылган исеме — Картезий)) рационализмына һәм ул тудырган картезианчылык юнәлеше барлыкка килүгә көчле тәэсир ясый. Аның акыл, гый-

лем турындагы карашлары Ауропадагы мәгърифәтчелек фәлсәфәсенең төп чыганагына әверелә. Үз чиратында, ул рус һәм татар иҗтимагый фикеренә көчле йогынты ясый. Мәсәлән, Көнбатыш Европа философиясе, аерым алганда, Декарт тәгълиматы белән ничек кызыксыну, кабул итү турында мәгълүматларны Нәҗип Думави әсәрләре һәм мәкаләләреннән дә табарга мөмкин. 1914 елда ул «Шура» журналында (13-14 нче саннар) картезианчылык фәлсәфәсе белән сугарылган, җир кешеләренең акыл сәләтенә мәдхия укыган Вольтерның «Микромегас» фәлсәфи «повестен» «Хакыйкать эзләү» исеме белән татарчага тәрҗемә итә, дөресрәге, адаптацияли. 1915 елда (21 нче сан) «Шура» журналының мөхәррире Р.Фәхретдин үзе дә «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хәдисәләр» (Мәшһүр адәмнәр һәм зур вакыйгалар) бүлегендә Декартның фәнни-фәлсәфи эшчәнлеге хакында күләмле генә мәкалә бастыра.

Шул рәвешчә, безнең эрага кадәр яшәгән мәшһүр йунан философы Аристотель (Арасту) тәгълиматының үзәген тәшкил иткән Акыл культы башта ислам мәдәниятенә үтеп керә, аның аерылгысыз юлдашы булып китә; әл-Кинди кебек күпсанлы гарәп философларының эшчәнлеге нәтиҗәсендә, гасырлар аша кичә-кичә, испан гарәпләре арадашчылыгында Көнбатыш Европага килеп ирешә; Декарт кебек акыл ияләре тарафыннан кабат яңа мәгънәви ачышлар белән баетыла, ахыр чиктә Россия җирлегендә дә мәгълүм булып, тәрҗемәләр аша татар халкының рухи хәзинәсенә әйләнә.

Гарәп телендәге фәннәрне һәм философияне үстерүгә хәлифәлектәге башка халыкларның галимнәре дә зур өлеш кертә. Шундый галимнәрнең берсе — нәсел-нәсәбе белән төрки-кыпчаклардан булган Әбү ән-Насыйр Мөхәммәд бине Тархан әл-Фараби (870-950). Төркестанның (хәзерге Казахстанның) Отрар шәһәрендәге Фараб бистәсендә туган бу бөек галим һәм философ Шәрекъ дөньясының мәдәни үзәкләрендә — озак еллар Багдадта, беркадәр вакыт Мисыр белән Хәләбтә (Алеппо, Халеб), гомеренең соңгы елларын Сүриядәге Шамда (Дәмәшекъ) үткәрә. Грек-латин, гарәп-фарсы телләрен яхшы белгән Әл-Фараби Борынгы Шәрекъ халыклары тарихыннан, мәдәниятләреннән дә хәбәрдар була; фәлсәфә, мантыйк, математика, тыйб гыйлеме, музыка һ.б. фәннәр буенча 70ләп хезмәт яза, аларның байтагы Европа телләренә дә тәрҗемә ителә. Ул фәннәрне өч төркемгә — физика, математика һәм метафизикага бүлә һәм бу классификация Европа университетларында да канун буларак кабул ителә. Галимнең «Китабел-мусикил-әкәбир» исемле музыка турындагы хезмәтенә багышлап, Шәехзадә Бабич «Канун уйнаганда» шигырь-мәдхиясен яза. Фәлсәфәче буларак, Фараби Шәрекъ һәм Гареб дөньясында грекларның бөек акыл иясе Аристотель белән янәшә куела, «Икенче Арасту» дип аталып йөртелә. Аның эшчәнлегенә К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдинов та югары бәя бирә.

Мөселман Яңарышы философиясе һәм медицина фәненең бөекләреннән берсе — Ибн Сина (Авиценна, Әбүгалисина, 980-1037). Чыгышы белән фарсылардан булган Ибн Сина — дөньякүләм атаклы энциклопедист: галим, табигать фәннәре белгече, математик, табиб, философ, музыкант, шагыйрь. Бохара янындагы Әфшанә карьясендә туа; балачактан ук үзен зур сәләт иясе итеп таныта; уналты яшендә Бохара әмирен авырудан терелтә. Рәхмәт йөзеннән әмир аңа үз китапханәсендәге китаплар, кулъязмалар хәзинәсе белән танышырга мөмкинлек бирә. Караханнардан булган төрки солтан Мәхмүд Газнәвигә хезмәт итәргә теләмичә, аның эзәрлекләвеннән качып, яшеренеп,

төрле төбәкләрдә (Хөрәсән, Үргәнч, Рәй, Казвин, Исфаһан, Хамадан) яши, төрле идарәчеләрдә вәзир һәм табиб вазифасын үти, алар белән яуларга йөри, төрмәләрдә утыра, үлем җәзасы белән куркытыла, кыенлыкларга баш имичә, фән белән шөгыльләнә. Ибн Сина — 450 фәнни хезмәт авторы, шуларның 240ы безнең көннәргә килеп җиткән. 182 хезмәте фәлсәфи темаларга багышланган. Философиядә Әфләтүн белән Арасту карашларын уртаклаша, аларның синтезы күзәтелә. Мәкалә авторы фикеренчә, Ибн Сина — мөселман неоплатонизмының күренекле вәкиле. Галимне перипатетик, ягъни арастучы, акыл культына өстенлек бирүче диючеләр дә бар (А.В.Сагадеев). Фәлсәфи хезмәтләрендә һәм әдәби әсәрләрендә неоплатониклар өчен хас эманация (әл-файд, ишрак) теориясе аеруча тулы чагылыш таба. Бу теория буенча (ул мөселманнарның яктылык метафизикасы дип атала) Галәмне халикъ итүче Аллаһы Тәгалә нур сибү рәвешендә башта Акылны, аннан җанны, азактан матдәне (кеше өчен ул — тән) яраткан. Аның бу фәлсәфи карашлары теолог, суфи Сөхрәвәрди белән философ, дәүләт эшлеклесе, табиб, ишрак яктылык, нур фәлсәфәсе тарафдары Ибн Төфәйли кебек ишрак фәлсәфәсе тарафдарлары булган галимнәргә дә зур йогынты ясый.

Әфләтүннең «Дәүләт» турындагы атаклы хезмәтендәгечә, Ибн Сина да акыллы, мәгърифәтле, гадел патша һәм дәүләт турындагы карашларны яклый, һәртөрле явызлыкка каршы чыга, гаделлек турында күләмле хезмәт тә яза. Кызганычка каршы, мөселман мәдәнияте өчен бәһасыз булган 20 томлык гаделлек турындагы бу трактат — «Китаб әл-Инсаф» югала. Безнең көннәргә бары 18 томлык «Китаб әш-шифа» исемле фәлсәфи хезмәте генә килеп җиткән.

Ибн Синага дөньякүләм шөһрәт китергән хезмәте — биштомлык «Әл-Канун фи-т-тыйбб» китабы. Медицина, фармацевтика гыйлеменең энциклопедиясе булган бу хезмәттә грек, рим, һинд, Урта Азия табибләренең теоретик һәм гамәли эзләнүләре гомумиләштерелгән. «Исламның Гиппократы» дип аталып йөртелгән Ибн Синаның бу хезмәте латин телендә генә утыз мәртәбәдән артык басылып чыккан. XVIII гасыр башына кадәр ул Европа университетларында медицина буенча төп дәреслек вазифасын үтәгән. Озак гасырлар дәвамында «Әл-Канун фи-т-тыйбб» татарлар арасында да киң кулланылышта булган. Аннан байтак өзекләр безнең заманда «Мирас» журналында да дөнья күрде.

Шәрекъ философларына хас булганча, Ибн Сина да бихисап фәнни-фәлсәфи хезмәтләр язу белән бергә, әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән, шигырь һәм музыка теориясе буенча трактатлар да язган.

Ибн Сина — шагыйрь дә. Касыйдә жанрында ул аеруча актив эшли. Фарсы һәм гарәп телләрендә язылган бу касыйдәләр сәнгатьчә эшләнеш ягыннан Цицерон чыгышларын, Бокаччо әсәрләре стилен хәтерләтә. Иң атаклы касыйдәсе — «Касыйдәт ән-нәфс». Шәраб турындагы робагыйлары кебек галимнең бу «Җан» турындагы касыйдәсе дә эманация, ягъни ишрак мөселманнарның яктылык, нур фәлсәфәсенә корылган.

Әдәби иҗатындагы төп темалар — материянең мәңгелеге, Аллаһы белән табигатьнең пантеистик берлеге; фәнне, мәгърифәтле булуны алга сөрү; обскурантларны — гыйлем дошманнарын наданнар-ишәкләр дип тәнкыйтьләү. Бездә искелек тарафдарлары булган кадимчеләрне ишәк образы белән чагыштыру шагыйрь Габдулла Тукай иҗатына кадәр дәвам итә.

Ибн Сина — тугыз поэма авторы, шуларның сигезе медицина темасына ба-

гышланган; аларның барысы да диярлек ул замандагы традиция буенча шигырь белән язылган. Урта гасырларда татарларда математика буенча хезмәтләрне дә шигырь белән язу күренеше очрый. Аның тарафыннан «Хәй улы Якзан», «Рисаләт әт-тайр» («Кошлар турында китап»), грек әдәбияты сюжетын файдаланып, «Сәләмән вә Әбсәл» исемле фәлсәфи повестьлар да иҗат ителгән. Бу соңгысының сюжеты грек әдәбиятыннан алынган Аристотель «Поэтика»сына нигезләнеп, шигырь теориясе буенча «Шигырь фәне» дигән хезмәтен яза. Ибн Синаның матурлык һәм мәхәббәт фәлсәфәсен мөселман неоплатонизмы рухында эманация баскычларына (Алла — Акыл — Җан — матдә, ягъни тән) бүлеп аңлаткан «Гыйшык рисаләсе» исемле хезмәте дә бар. Рус теленә ул С.Б.Серебряков тарафыннан тәрҗемә ителгән (1976. — 176 б.).

Бөтендөнья фольклорында һәм әдәбиятында Ибн Сина образына зур урын бирелә; ул А.Дантеның ишрак (нур) фәлсәфәсе белән үрелгән «Илаһи комедия»сен язуга да этәргеч ясый; бу бөек энциклопедист образы К.Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы», Н.Исәнбәтнең биш пәрдәлек «Әбугалисина» драматик поэмасында да гәүдәләнгән.

«Ислам философларының бөекләреннән» (Г.Ибраһимов) тагын берсе — Ибн Рөшд Әбел-Вәлид Мөхәммәд (1126-1196). Андалузиядә туа, Маракишта (Марокко) яши; төрле идарәчеләрдә сарай табибе һәм хакиме вазифасын башкара. Хезмәтләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. «Аверроэс» (латинча) исеме белән Көнбатыш Европа фәненә көчле йогынты ясаган һәм европалылар тарафыннан бик тә хөрмәт ителә торган философ. Аристотель хезмәтләренең мәгънәви асылын тирән аңлатканы өчен аңа «комментатор» дигән исем бирелә. Тәрҗемә итү һәм шәрехнамәләр язу барышында Ибн Рөшд Арасту фәлсәфи карашларының христиан һәм ислам дине схоластикасы белән килешеп бетмәвен, үзара каршылыкка керүен күреп ала. Шул күзәтүләренә таянып, ул нәсарәләр һәм мөселманнар арасында киң таралыш тапкан «хакыйкатьнең икелеге» («двойственность истины») дигән тәгълиматка нигез сала. Ибн Рөшдчә, философиядә хакыйкать дип кабул ителгән хөкем теологиядә ялган буларак кабул ителергә мөмкин. Шул сәбәпле Коръәндә чагылыш тапкан хөкемнәрне дә ике төрле укылышлы —могтәзиләләрчә рациональ эчтәлектә аңлау һәм гаммәгә (гади халыкка) хас образ-символлар, аллегорияләр ярдәмендә күзаллау мөмкинлеге бар. «Хакыйкать ике яклы була» дип, фәлсәфи фикер йөртүдә хөрлеккә омтылганы өчен Имам Газзали тарафыннан тәнкыйтьләнә һәм «кяфер» дип игълан ителә.

Иҗтимагый идеаллар мәсьәләсенә килгәндә, Ибн Рөшд Платонның «Дәүләт» дигән хезмәтендәге фикерләрне уртаклаша.

Ислам Яңарышы нигез ташларын салуда әл-Кинди, әл-Фараби, Ибн Сина, Ибн Рөшд кебек мәшһүр затлар белән бергә, гарәп хәлифәлекләрендәге бихисап талантлар, галим-голәмәләр үз өлешләрен кертә. Алар Юнан-Рим-Византия, Мисыр, Һиндстан һәм яулап алынган башка халыкларның фәнни-әдәби мирасын тәрҗемә итү, шәрехләү белән генә чикләнмичә, аларның дөресме, дөрес түгелме икәнлеген тәҗрибәләр белән дәлилләп, тәнкыйть иләге аша үткәрделәр, фикер алыштылар. Галимҗан Ибраһимов язганча, «бик күп киңәйттеләр, алга үстерделәр. Әүвәлгеләрдә булмаган икътисади-сәяси (политическая экономия), тарих, җәгърафия фәлсәфәсе — боларның темалары. Тригонометрия, алгебра, хакыйкый булган химия кебек фәннәрне үз тарафларыннан,

үзләренең тырышлыгы вә фикерләве нәтиҗәсендә барлыкка китерделәр... Алар мәдәният гыйлемендә һәммә милләттән өстен чыкты» [9].

Белгәнебезчә, мәдәниятләр берберсен алыштырып киләләр. Борынгы Шәрекъ (Борынгы Мисыр, Бабил, Шумер, Ассирия, Иран, Һиндстан һ.б.) грек мәдәниятен тудыруга җирлек хәзерләгән. Беркадәр соңрак грек философиясеннән һәм мәдәниятеннән мөселман-гарәп фәлсәфәсе, ислам мәдәнияте үсеп чыккан. Үз чиратында, мөселман мәдәнияте Европа цивилизациясен һәм культурасын әзерләүгә зур өлеш керткән.

Шәрекъ белән чагыштырганда, Урта гасырлардагы Европа «мәгариф, гыйлемнең нәрсә икәнен дә белми, боларга «дин кысаларына сыймый торган яңалык» дип карап, папаның инквизициясе мәхкәмәләрен гыйлем вә фәлсәфә ияләрен аса, кисә, утка яга». Әмма алты-сигез гасыр узгач та вазгыять үзгәрә: «мәдәният гыйлеме кояшы мөселман дөньясында батып, нурын Европага чәчә башлый. Әле кайчан гына мөселман цивилизациясе казанышларына шәкерт булган европалылар, мәсәлән, танылган француз философы, диннәр белгече Эрнест Ренан да (1823-1892) ислам фәннәре ул греклардан турыдан-туры күчермә генә, ислам, гомумән, фәнгә, акыл культына, рациональ фикерләүгә каршы дип яза, сөйли башлыйлар. Ислам мәдәниятенең асылын, аның грек мәдәнияте белән үзара мөнәсәбәтләрен бозып күрсәтүчеләргә, аңламаучыларга каршы чыгучылар да була. Э.Ренанның «Ислам һәм дин» дигән хезмәтен тәнкыйтьләп, Петербург мәчетенең имам-хатыйбы, җәмәгать эшлеклесе, хәрби ахун, тәрҗемәче Гатаулла Баязитов күләмле мәкалә белән җавап бирә. Ул Коръәннән, хәдисләрдән китерелгән күпсанлы мисаллар белән ислам диненең фәнгә һич тә дошман булмаганлыгын дәлилләде, ислам фәннәренең греклардан алынган күчермә генә дигән фикерне хакыйкатьтән ерак дип кискен кире кага. Аныңча, борынгы Йунан мәдәнияте гарәп телендәге фәлсәфәне һәм фәннәрне тудыручы Ата вазифасын башкарган. Гарәпләр исә — греклар чәчкән мәдәният орлыкларын кайгыртучан Ана кебек кадерләп, тәрбияләп үстереп, бүген мәдәният үрнәге һәм үзәге дип саналган Европага җиткерүчеләр. Шулай булгач, борынгы грек мәдәниятен Ислам мәдәниятенә каршы кую, түбәнсетү һич тә мөмкин түгел. Ислам фәннәре — ни дәрәҗәдә йунаннардан кабул ителгән булса, шул ук дәрәҗәдә гарәпләрнең тырышлыгы белән табылган рухи хәзинә. Димәк, даһи Европаның Анасы — ислам мәдәнияте. «Европа обязана, — дип яза Гатаулла Баязитов, — великой благодарностью исламу как Матери, передавшей Европе так хорошо воспитанного юношу, отец которых Греция. Европа в то время совсем не знала этого отца, зачем же не назвать родившегося юношу по имени матери, т.е. Аравии, его воспитавшей. И так мы полагаем, что наука, о которой говорил Ренан, есть настолько греческая, настолько и арабская» [10]. XX гасырның унынчы елларында «Шура» журналында шул ук фикер Мәйән Габдел Әүвәл әл-Гаффари тарафыннан да ассызыклана: «Димәк, даһи Европаның Анасы — ислам мәдәнияте» [11].

Галимҗан Ибраһимов та, урта гасырларда Ренессанс күтәрелеше кичергән мөселманнарның «мәдәният гыйлемендә һәммә милләттән өстен чыгулары, «галәмгә остаз булулары турында яза» [12].

Ислам дөньясының югары үсеш баскычында торуы аның Ренессанс эчтәлекле әдәбиятын да, теориясен дә үзенчәлекле итте. Бу чордагы кайсы гына шагыйрь иҗатына мөрәҗәгать итмә, аның әдәби-эстетик һәм этик карашлары фәннилек һәм фәлсәфилек белән сугарылган булыр. Шуңа күрә дә,

гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә бердәй талантлы шигырьләр язучы Мөхәммәд Фөзүлинең (1494-1556): «Әгәр дә минем шигырьләремнең кәүсәсе купшы фәнни фикерләр белән бизәлмәсә, бу минем җанымны рәнҗетү булыр иде» [13], — дигән сүзләре очраклы әйтелмәгән булса кирәк. Кыскасы, фәннилек һәм фәлсәфилек — шәркый Ренессанс әдәбиятлары өчен уртак типологик сыйфат. Г.Ибраһимов искәрткәнчә, «Әдәбият гыйлеменең гарәпләрдә гүзәл булып алга китүен аңлатып тору да кирәкми» [14]. Дөрестән дә, Яңа заманда Европа галимнәренә нисбәт ителгән тарихи, иҗтимагый, икътисади, фәлсәфи-эстетик һәм этик карашларның елга башы ислам мәдәниятенә барып тоташа. Бүгенге көндә Европа һәм Россия галимнәре ачышлары дип саналган байтак фикерләрнең тамырларын, «мәңге әйләнеп кайту» («вечное возвращение») канунына таянып, мөселман галимнәре хезмәтләреннән эзләргә кирәк. Карл Маркcның иҗтимагый-сәяси, икътисади теорияләре белән аваздашлыкны урта гасырлардагы тарих һәм социология фәннәренең бөек фәлсәфәчесе Ибн Хәлдун (1332-1406) хезмәтләреннән табып була. Юкка гына бу бөек галимне В.И.Ленин гарәпләрнең Марксы дип атамаган. Ипполит Тэнның культура-тарих мәктәбенә Лев Гумилёвның пассионарлык, Риза Бариевның этноноосферага караган хезмәтләрендә дә Ибн Хәлдун карашлары белән аваздашлыкны тоеп була. Жан Жак Руссоның гадел җәмгыять, табигый кеше турындагы өйрәтмәләре, Фрейдның психоанализы, гүзәллек, фаҗигалелек эстетикасы, иҗат ысуллары модернистик һәм постмодернистик әдәбиятлар, аеруча аларның экзистенциаль канаты өчен хас архетипик сыйфатлар суфичылык фәлсәфәсендә һәм әдәбиятында борынгыдан ук яшәп килә иде. Моның шулай икәнлеге татар галимнәренең күпсанлы хезмәтләре белән дә расланды.

Әдәбият

1. Грюнебаум Г.Э. Основные черты арабо-мусульманской культуры. — М.: Наука, 1981. — С.75.
2. Усманов Х.У. Место Тукая в истории татарской поэзии // Габдулла Тукай. Сб.ст. — Казань: Татгосиздат, 1968. — С.17.
3. Гыйльме кәлям — акыл кануннарына таянып, дини-фәлсәфи темалар турында фикер йөртү.
4. Мөтәкәллимнәр — ислам догматларын коры ышану, инану белән генә түгел, Арасту кебек диалектик ысуллар һәм акылга таянып та аңлатучылар.
5. Могтәзиләләр — дини мәсьәләләрне шәрехләгәндә, греклар кебек фәлсәфи категорияләргә — төшенчәләргә мөрәҗәгать итүчеләр. Соңгы күренекле татар могтәзиләләренең берсе — Шиһабетдин Мәрҗани. Аның могтәзиләләргә хас карашы шагыйрь Тукайның «Шиһап хәзрәт» (1913) мәрсиясендә дә чагылыш тапкан.
6. Схоластика — илаһият фәлсәфәсе догматикасын, акыл культына таянып, формаль логика ысуллары ярдәмендә аңлату.
7. Әшгарыйлар — дини мәсьәләләрне могтәзиләләр кебек һәм греклардагыча фәнни төшенчәләр ярдәмендә шәрехләүчеләр. Ислам диненең башка мәзһәпләре өчен хас карашларны да үзендә эреткән юнәлеш.
8. Гарәп әдәбияты // Шура. — 1910. — №3. — Б.68-69. Өзек Ләззәт Хәйдәровның кандидатлык диссертациясендә 39 нчы битеннән алынды.
9. Ибраһимов Галимҗан. Борынгы ислам мәдәнияте. — Казан: Рухи мәдәният академиясе, 2006. — Б.188-189.
10. Возражение на речь Эрнеста Ренана «Ислам и наука» С.-Петербургского мухамеданского ахуна, имам-джамия хатыб мударриса Атауллы Баязитова. — С.-Петербург: Типография А.С.Суворина, 1883. — С.10.
11. Аурупа вә ислам мәдәнияте вә аларның тарихчысы // Шура. — 1915. — №11. — Б.324-326.
12. Ибраһимов Галимҗан. Борынгы ислам мәдәнияте. — Казан: Рухи мәгърифәт академиясе, 2006. — 189 б.
13. Гулизаде М.Ю. Лирика Физули. Автореферат докт. дисс. — Баку, 1965. — С.58 («Будет оскорблением для меня, если стан моих стихов не будет облачён в роскошный наряд наук»).
14. Ибраһимов Галимҗан. Борынгы ислам мәдәнияте. — Казан: Рухи мәгърифәт академиясе, 2009. — 135 б.

Дәвамы алдагы саннарда.

ГАБДЕРӘШИТ ИБРАҺИМНЫҢ ҖӘМАЛЕТДИН ӘФГАНИ ТУРЫНДА БЕР ЧЫГЫШЫ

ӘЛФИНӘ СИБГАТУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы, профессор,
Россия Фәннәр академиясе Шәрыкне өйрәнү институтының
әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

МӘГЪЛҮМ БУЛГАНЧА, ЯПОНИЯДӘ ИСЛАМ ДИНЕН ТАРАТУДА ТАТАР ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ГАБДЕРӘШИТ ИБРАҺИМНЫҢ (1857-1944) ЗУР ӨЛЕШЕ БАР. 1909 ЕЛДА ЯПОНИЯГӘ КИЛЕП, Г.ИБРАҺИМ ШАКТЫЙ ОЗАК ЯШИ, ШУЛ ВАКЫТ ЭЧЕНДӘ БЕРНИКАДӘР ЯПОН ЗЫЯЛЫСЫ МӨСЕЛМАНЛЫКНЫ КАБУЛ ИТӘ.

ИБРАҺИМОВ ГАБДЕРӘШИТ ГОМӘР улы (1857-1944) — җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, публицист. 1885-1892 елларда Тубыл губернасы Тора шәһәрендә имам, мөдәррис. 1892-1895 елларда Оренбург мөселман Диния нәзарәте казые. 1906-1907 елларда Бөтенроссия мөселманнары съездларын оештыручылардан берсе, «Иттифак әлмөслимин» партиясе ҮК әгъзасы. «Миръат» журналының, «әт-Тилмиз», «Өлфәт» газеталарының нашире һәм мөхәррире. 1921 елдан эмиграциядә, 1933 елдан Япония, Токио җамигъ мәчете имамы. Европа һә Шәрык илләренә күп мәртәбәләр сәяхәт итә. Көньяк-көнчыгыш Азиядә ислам динен тарату тарихына һәм татар халкының сәяси тарихына караган китаплар авторы.

Татар энциклопедиясе сүзлеге. — Казан, 2002. — Б.243.

ҖӘМАЛЕТДИН ӘЛ-ӘФГАНИ (1839-1897) — дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, мөселман ислахчылыгы идеологы. 1858-1869 елларда Әфганстан әмирләрендә хезмәттә. 1871-1879 елларда Мисырның иҗтимагый-сәяси тормышында катнаша. 1884 елда Мөхәммәд Габдүһ белән Парижда яшерен «әл-Урва әл-вуска» («Тыгыз элемтә») җәмгыятенә нигез сала, шул исемдә газета нәшер итә. Җәмалетдин Әфганинең ислахчылык фикерләре Г.Баруди, Г.Баязитов, М.Бигиев, Р.Ибраһимов, Р.Фәхретдинов һ.б. дөньяга карашлары формалашуга йогынты ясый.

Татар энциклопедиясе сүзлеге. — Казан, 2002. — Б.66.

1934 елда Г.Ибраһим Япониягә килеп төпләнә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яшәп, 1944 елда Токиода вафат була. Профессор Салих Самарраи (Япония ислам мәркәзенең мактаулы мөдире) [1] 2011 елда Төркиядә Габдерәшит Ибраһимның моңа кадәр билгеле булмаган бер нотыгын бастырды [2] һәм ул төрек җәмәгатьчелегендә шактый зур кызыксыну уятты. Без шул язманы татарча бирергә уйладык, чөнки Г.Ибраһимның биографиясен өйрәнүчеләр тарафыннан аның атаклы ислам реформаторы Сәйед Җәмалетдин Әфгани (1838-1897) белән бәйләнеше әле һаман «гөман» гына ителеп килә [3], бу чыгышта исә без Г.Ибраһим белән Әфганинең үзара якын элемтәсе булуына төпле дәлилләр бар дип саныйбыз.

1930 еллар башында Г.Ибраһим Мисырда була һәм Каһирәдә Мөселман яшьләре җәмгыятендә (Җәмигъйетүш-Шуббанигъүл-Мөслимин) чыгыш ясый. Бу чыгышында ул үзенең ничек Әфгани белән танышуы турында сөйли. Соңыннан нотыкны тыңлаган шәхесләрдән берничәсе аның кыскача эчтәлеген бастырып чыгара [4], ләкин ул озак вакыт киң катлам укучыларга билгесез булып кала. Япон галиме бу чыгыш басылган китапны эзләп табып тәрҗемә итә һәм төрек вакытлы матбугатында язып чыга. Салих Самарраи Г.Ибраһим нотыгының әһәмиятен өч ноктада басым ясап күрсәтә:

1) Сәйед Җәмалетдин Әфганинең эшчәнлегенә ачыклаулар кертә;

2) японнарның ислам диненә карата булган кызыксынуын күрсәтә;

3) Г.Ибраһимның биографиясендәге кайбер безгә билгесез урыннарга әдипнең үзе тарафыннан ачыклык кертелә.

1. Себердән китеп, Урта Азия, Төркия, Япония, Корея, Кытай, Сингапур, Һиндстан, Хиҗаз, Шам һ.б. шәһәр һәм илләрне гизеп йөргән Габдерәшит Ибраһим 1911 елда ике томлы «Галәм-и ислам» китабын нәшер итә. Профессор Салих Самарраи, бу сәяхәтнамәгә югары бәя биреп, «Шәйх Габдерәшитнең бу китабы Ибне Батутаның сәяхәтнамәсеннән дә әһәмиятлерәк», дип исәпли һәм госманлыдан гарәп теленә тәрҗемә итә.

2. SAMARRAİ Salih. Büyük dava adamı seyyah Abdurreşid İbrahim'in h.1349

Безнең җәһәттән исә бу чыгыш Әфгани белән Г.Ибраһим арасындагы якын мөнәсәбәтне, Рәшид казыйның Әфганине үзенең остазы итеп кабул итүен һәм аның янында шактый күп вакыт булып, панисламизм идеяләрен «сеңдерүен» аңлау өчен аеруча мөһим булып тора. Чыгыштан аңлашылганча, Г.Ибраһимның фикер-хәясе формалашуда Әфгани шактый зур роль уйнаган булып чыга.

Билгеле булганча, Җәмалетдин Әфгани шәхесенә карата ислам дөньясындагы бәхәсләргә бүгенгә кадәр соңгы нокта куелмаган. Аның килеп чыгышы (Әфганстан, Иран?), милләте (әфган, фарсы, гарәп, азәрбайҗан-төрек?), сөнни исламга мөнәсәбәте, масонлыгы турында капма-каршы фикерләр, берәүләрнең аны «ислам диненең бөек заты» дип күкләргә чөеп мактарга, икенчеләрнең исә «исламны эчтән таркатучы дошман» дигән күзлектән карап нәләтләргә, бәддога укырга урын калдыра. Үзе исән вакытта ук каршылыклы мөнәсәбәтләр белән даими очрашып торган Әфганинең мондый шигырь юллары бар икән:

Инглизләр минем рус булуыма ышана,
Мөселманнар мине мәҗүси дип уйлый,
Сөнниләр мине шыйга (рәфиди) саный,
Ә шыйгалар хәзрәти Галинең дошманы, ди.
Берәүләр минем ваһһаби булуыма ышана,
Икенчеләре мине бабидләргә кертә...
Бераллачылар материалист дип сурәтли,
Тәкъвалар, гөнаһлы санап, ачык йөз күрсәтми,
Галимнәр мине бер билгесез надан хисаплый... һ.б. [5].

Татар дөньясында Әфгани белән күрешеп, аның көчле йогынтысын татыган иң билгеле кеше — ул Ризаэтдин Фәхретдинов (1859-1936). 1888 елда Әфгани Мәскәү һәм Петербургта була, Рәсәй мөселманнары белән очрашып, аларның хәл-әхвәлләре белән таныша. Петербург ахунының чакыруы белән башкалага килгән яшь Р.Фәхретдин Әфгани белән берничә сәгать сөйләшеп утыру бәхетенә ирешә һәм соңыннан аның турында «Шура» журналында язып та чыга [6]. Рәшит казый турында Әфгани Р.Фәхретдиннән дә ишеткән булырга мөмкин.

Г.Ибраһим исә Әфгани белән биш ел соңрак Истанбулда таныша. Җәмалетдин Әфгани биографиясенең зур гына бер өлеше Госманлы империясе белән бәйле. Башта ул 1870 елда солтан Габделгазиз чакыруы буенча Истанбулга килә, ләкин дарелфөнүндә [университетта] ясаган бер «уңайсыз» чыгышыннан соң төрек дин әһелләре арасында зур гауга чыга һәм ул госманлы иленнән китәргә мәҗбүр була. 1892 елның язында солтан Габделхәмид II аны яңадан хөрмәтләп Төркиягә чакыра, бу килүеннән соң Әфгани, берничә тапкыр китәргә талпынып караса да, төрле сәбәпләр аркасында илдән китә алмый һәм 1897 елның 9 мартында Истанбулда вафат була [7]. Габдерәшит Ибраһим, нәкъ менә Әфгани гомеренең соңгы елларында, соңгы көннәрендә аның янында булган кешеләрнең берсе буларак, үзенең хатирәләрен

tarihinde Kahire'de Müslüman Gençler Derneği'nde Cemaleddin Afgani hakkında sunduğu konferans. Kur'ani Hayat dergisi. — 2010. — №16. Соңрак бу язма башка төрек журналларында да басылды. Интернет-ресурс http://www.haksozhaber.net/cemaleddin-afgani-hakkinda-taniklik-15644h.htm

3. Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз.: М.Госманов, Ф.Галимуллин. — Казан: Җыен, 2011. — 19-20 б.

4. Şeyh Muhibbuddin el-Hatib. El-Munteka min Muhadarâti Cem'iyeti'ş - Şubbani'l – Muslimin. Kahire, el-Matbaa es-Selefiyye. — 1349. — 20-30 б.

5. Бу шигырьне русча чыганактан алып сүзгә-сүз тәрҗемә кылдык: Р.Р.Сикоев. Панисламизм. Истоки и современность. Джамалутдин Афгани и его религиозно-политические последователи XX — начала XXI века. — М., 2010. — С.37-38.

6. Ризаэтдин бине Фәхретдин. Шәех Җәмалетдин // Шура. — 1917, №16.

сөйли, моның белән Мисыр яшьләре арасында кызыксыну уята.

Биредә шул гарәпчә сөйләнгән нотыкның төрекчәдән тәрҗемәсе бирелә.

7. 47 елдан соң, 1944 елның декабрендә, Әфганинең җәсәде Әфганстанга алып кайтып, Кабул университеты янына күмелә.

Кардәшләрем!

1310 елның шогъбан ае башларында (1893 елның феврале) мин Истанбулның Бешикташ районындагы солтан Габделхәмид мәчете янында идем. Сөйләшеп торган ике кеше игътибарымны җәлеп итте. Берсен таныдым: остаз Габдуллаһ ән-Нәҗди (король Габделгазиз әс-Согыдинең абзыйсы) иде. Нindидер тарту көче мине алар янына китерде. Якынлашкач, сәлам бирдем. Миңа таныш булмаган кеше туган җиремне сорады. Мин Сибирия дип җавап бирдем. Ул арада икенчесе дә шул ук сорауны бирде, тагын Сибирия, дидем. Аннан соң каян килүемне сорадылар, Сәбрем (Тара), дидем. Нәкъ шул чакта мөәзин азан әйтте. Без намаздан соң тагын шушы урында очрашырбыз, дип мәчеткә кердек. Мин намаз укыгач, остазны көттермәс өчен тышка чыгарга ашыктым, ул да чыкты. Машина көтеп тора икән, бергәләп аның өенә киттек. Юлда яшемне сорады, кырыктан узуымны әйттем. Йөзе бик нурлы иде аның. Ике тапкыр мине кысып кочаклады. Өенә кайткач, хезмәтчесенә килгән кешеләрне яныбызга кертмәскә боерды. Бик ашыгыч эше булган берәрсе бар икән, бер-ике сәгать көтсен, диде. Миңа чәй китертте һәм Рәсәйнең сәяси хәлен сораштыра башлады. Мин, аны бик яхшы танымаганга күрә, җавапларымны кыеклатып кына бирдем.

Ул: «Бер заманлар син Мәхкәмә-и Шәргыя әгъзасы һәм мөфти булган идең түгелме?» — дип сорады. Эчемнән: «Кем булыр бу? — дидем, — мине таный һәм минем турыда бар нәрсәне белә». Мин шулай уйланып утырганда: «Җәмалетдин Әфганине ишеткәнең бармы?» — дип сорады. «Әйе», — дидем. «Мин шул кеше инде», — диде. Кулын үптем, ул да тагын бер тапкыр мине кочаклады. Әйтерсең лә бөтен эчем нур белән тулды һәм телем ачылды. Тотындым сөйләргә: Рәсәйнең сәяси хәлен, дини тормышын, Коръәни-Кәримнең кайбер аятьләренең ничек бозылганын… «Алар өчен үч алачакбыз», — диде. Ике сәгать буе шулай сөйләшеп утырдык.

Соңрак остаз Сәйед Абдуллаһ Нәдим Мисрый безгә килеп кушылды. Мине остазга танытырга теләгәч, «таныйм, ул безгә файдалы булачак», диде. «Русча беләсеңме?» — дип сорады, мин «әйе», дидем. «Агъля, агъля», — диде. Гадәттә, сөенгән чагында ул бу сүзне куллана иде.

Шулай итеп, остаз ул вакыт мине аптырашта калдырган иде: мине таный һәм минем турыда бар нәрсәне белә иде. Соңрак: «Русча газеталар укыйсыңмы?» — дип сорады. «Юк, чөнки акчам юк», — дидем. «Мин акча бирермен, син бары тик укып, аларда ни язылганны миңа сөйлә», — диде. Шуннан соң өч газетага язылдым. Даими рәвештә очрашып, газеталарның кыскача эчтәлеген сөйли торган идем.

Инде хәзер остазның кайбер якларын сөйлим сезгә.

Иманы

Аллаһ рәхмәт әйләсен, остаз ныклы иманга һәм һич какшамас бер инанычка ия иде. Иманы Әбүбәкер Сыйддык (р.г.) иманы дәрәҗәсендә иде. Гел дөреслекне генә сөйләр иде. Аңа каршы чыгучыларның сүзеннән гел курыкмас иде. Король яки падишаһлардан бөтенләй читенсенмәс иде. Моңа мисал итеп шундый бер вакыйганы сөйлим сезгә.

Кайбер укымышлылар һәркөн килеп аның хәлен белер иделәр. Беркөнне мин аның янында утырганда, Галиҗан әфәнде шәкертләреннән икесе килде. «Әфәндем, иман хакында нәрсә уйлыйсыз? Кимергә яки артырга мөмкинме ул?» — дип сорадылар. Аның җавабы мондый булды: «Авыл һәм җәйләүләрдә иман үзгәрмәс. Артмас та, кимемәс тә. Фәкать шәһәрләрдә кешенең иманы сәгать саен үзгәрә. Арта яки кими. Аеруча тирә-ягында кеше кыяфәтендәге шайтаннар булганда. Мәсәлән, солтан Габделхәмиднең иманы шундый», — диде. Бу сүзләрне сөйләгәндә, ул һәр тарафында солтан шпионнары булуы мөмкинлеген бик яхшы белә иде...

Әңгәмәләрендә гел пәйгамбәр әфәндебезнең (с.г.в.) сәхабәләрне сүзе белән түгел, үз эш-гамәлләре белән тәрбия итүен сөйләр иде. Остаз Җәмалетдин Әфгани даими шул бөек шәхесне үрнәк итеп куяр иде. Бик еш кына миңа: «Иманың куәтле, ышанычың какшамас булырга тиеш», — дияр иде...

Мине ислам пропагандасына чакырып, еш кына шушы аять-и кәримәне укыр иде: «Һәм арагызда изгелеккә чакыручы, дөреслекне әмер итүче, яманлыктан читкә этәрүче бер төркем кеше булырга тиеш, менә алар теләкләренә ирешәчәкләр» (Әли Гыймран сүрәсе, 3/104).

Күп вакыт кяферләрнең мөселман җирләрен басып алуларын искә төшерер, мөселман лидерларын бу мәсьәләдә гел сүгәр иде. Беркөнне мин аның туган җирен сорадым. «Минем ватаным юк, — диде, — чөнки бүген мөселманнарга ватан калмады». Беркөнне кәлимә-и тәүхид (Лә илаһе иллаллаһ Мөхәммәде рәсүлуллаһ) хакында сөйләде. Кешеләрнең бу гыйбарәнең мәгънәсен белмәүләреннән зарланды: «Чөнки бу кәлимәнең мәгънәсен белгән кеше башка берәүгә мохтаҗ була алмас һәм беркемнән дә ярдәм сорамас», — диде...

Күп вакыт болай дияр иде: «Мөхәммәд (с.г.в.) безгә тәүхид кәлимәсен өйрәткән кебек, минлек һәм шәхсият хөрриятен дә өйрәтте».

Гыйбадәте

Әфгани (р.г.) бары тик фарыз намазлар укыр иде, Рамазан кичләрен гыйбадәттә уздырыр иде.

Суфичылык аңлаешы

Әфгани (р.г.) — суфи (тасаувыф) шәйхе иде. Ләкин үз заманының шәйхләренә охшамас иде. Болай дияр иде: «Фәна филлаһ түгел, фәна фиһалкиллаһ булырга кирәк, ягъни Аллаһы Тәгаләнең яратканнарына хезмәт итәргә һәм аларның ялгышлардан коткарылуында фани булырга кирәк».

Сәясәт аңлаешы

Әфганинең сәяси карашларының нигезендә әфганлыларны, иранлыларны, көрдләрне, төрекләрне, һиндлеләрне... бөтен мөселман милләтләрен берләштерү фикере ята иде. Моны бары тик бер сәяси ихтыяҗ буларак түгел, бигрәк тә дини бер ваҗиб [тиешле] эш санар иде. Чөнки исемнәрнең төрле булуы, мөнәсәбәтләрнең аерымлануы ислам берлегенең бозылуына сәбәп була иде. Аның иң бөек максаты — Көнчыгыш һәм Көнбатыш мөселманнарын бергә туплап, бөек бер ислам дәүләте төзү иде.

Беркөнне Япония императоры Мэйдзи [8] солтан Габделхәмидкә хат яза. Үз иленә ислам миссионерларын җибәрүен сорый. Шул рәвешле ике милләт арасында хезмәттәшлек булдырырга тели. «Беләсең инде, мин дә, син дә көнбатышлыларның рөхсәтеннән башка берни эшли алмыйбыз. Шаять, милләтләребез берләшсә, көчле-куәтле булырбыз», — ди. Солтан Габделхәмид Истанбулдан кайбер дин галимнәрен җибәрергә җыена, ләкин остаз, аңа каршы чыгып, болай ди: «Һич шигем юк ки, бу галимнәр исламнан нәфрәт иттерәчәк кешеләр. Боларны Япониягә кяферләрне динебезгә чакырыр өчен җибәрмик. Иң яхшысы, син Япония җитәкчесенә бүләкләр җибәр һәм аның теләген тормышка ашырачагыңны әйт. Үзең исә бу хезмәткә яраклы галимнәр тәрбиялә һәм соңыннан аңа җибәр», — ди.

Кирамәтләре

Хәзер сезгә бу мөҗәһиднең кирамәтләрен сөйлисем килә. Күрешкән чакларыбызда ул минем Япония һәм Ерак Көнчыгышта ислам дәгъвасын тарату өчен горбәткә [читкә] чыгуымны тели иде. Мин исә моны мөмкин түгел дип саныйм, сәяхәт өчен акчамның булмавын, хатынымның авыру булуын сәбәп итә идем. Берсендә ул: «Хатының вафат итәр, син исә сәфәргә чыгып китәрсең», — диде. Нәкъ ул әйткәнчә булды: берничә көн дә узмады, хатыным үлеп китте. Шулай итеп, аның беренче кирамәтенә шаһит булдым.

Бервакыт Истанбулга рус сәясәтчеләреннән танылган бер кеше килде. Нияте — Мәккәгә хаҗга бару, имеш. Остаз: «Монда нидер бар, артыннан караштыр, күргәннәреңне миңа әйтерсең», — диде. Мин дә минутын-минутка артыннан карап йөрдем. Исеме Габделгазиз иде [9]. Ләкин анда шөбһәле бернәрсә күрмәдем. Остаз: «Ул кеше Петербургка кайтып киткәнче гел артыннан кара», — диде.

Русларның зур кешеләренә таратыр өчен бер китап биреп, миңа болай диде: «Бу сәяхәтең я бик уңышлы булыр, я син үләрсең...» Әфгани киңәшен тотып, бер рус түрәсе янына киттем. Аны мөселман булырга чакырдым. Остазымның христианнарның тәслис [троица] һ.б. ялгыш инанычларын дәлилләр белән юкка чыгарган китабыннан алып мәгълүмат бирдем. Ләкин ул кеше шактый зирәк иде. «Бу сүзләр синеке түгел, син аларны ниндидер бер китаптан укыгансың», — диде. Мин дә «әйе» дидем һәм китапны аңа бирдем. Китап русча иде. Адәм сөенде, ярдәмчесен чакырды, миңа теләгән кадәр акча бирергә кушты. Бу китап-

8. Император Мэйдзи (1852-1912) 1868 елның 23 октябреннән 1912 елның 30 июленә кадәр тәхеттә утыра.

9. Бу шәхесне татар генералы Габделгазиз Дәүләтшин (1861-192?) дип уйларга нигез бар. Рәсәй хөкүмәте кушуы буенча ул Мәккәгә хаҗга бара һәм андагы дини-сәяси атмосфераны һәм хаҗилар өчен санитария-эпидемиология шартларын тикшереп, отчёт яза. Аның бу әһәмиятле язмасы нигезендә Рәсәй мөселманнарының хаҗга бару кагыйдәләре эшләнә («Временные правила о паломничестве мусульман») һәм мөселман хаҗын оештыру шартлары христиан хаҗиларның Иерусалимга бару шартларына якынлаштырыла. Ләкин монда бер туры килмәүчелек бар: Г.Дәүләтшинның хаҗ миссиясе 1898 елда була, ә бу вакытта инде Әфгани исән булмый. Димәк, Г.Дәүләтшин Истанбулга 1898 елдан иртәрәк килгән булырга мөмкин.

ны Софияда бастыруымны теләде. Чыкканда ярдәмчесе миңа «Күпме акча кирәк?» — дип сорады. Мин: «Нихәтле җитәр?» — дидем. Ул: «Сезнең арагызда ни турында сүз баруын мин белмим, ләкин сез никадәр сорасагыз, шулкадәрле бирермен», — диде. «Алайса миңа уйларга өч көн вакыт бирегез», — дидем. Өченче көнне ярдәмче янына килеп, өч мең сорадым. Ул: «Утыз мең бирим», — диде. «Юк, миңа өч мең җитә», — дидем. «Сез Аурупада акчаның никадәр кыйммәт булуын беләсезме соң?» — диде. Мин барыбер өч мең булсын, дидем, ул бирде һәм акчага ихтыяҗым булганда, теләсә кайсы банктан алыр өчен миңа бер чек бирде. Китапны бастырдым һәм йөз нөсхәсен аңа җибәрдем.

Бер өлешен башка җиргә күндердем. Рәсәй хөкүмәте, моны белеп алгач, артымнан карап йөрергә шпионнар куйды. Истанбулга килеп җиткәч тә, рус консулы мине кулга алдырды һәм судка бирер өчен Рәсәйгә җибәрде, чөнки мин Рәсәй гражданины идем. Бу вакыйга һиҗри 1313, милади 1895 елда булды [10]. Төрмәгә кергәндә үз-үземә: «Бу остазның икенче кирамәте, я әйбәт тормыш, я дә үлем көтә», — дидем.

Мин төрмәдә вакытта Рәсәйнең премьер-министры үлде, аның урынына килгән Мирскийны [11] мин электән таный идем. Төрмәдән аңа телеграмма суктым. Икенче көнне төрмә башлыгы миңа килеп: «Бу телеграмманы син җибәрдеңме?» — диде, мин, әйе, дидем һәм премьер-министр белән таныш булуыбызны әйттем. Өченче көнне яңадан килде һәм, икебез бергә төрмәдән чыгып, премьер-министр янына киттек. Мине күрү белән таныды һәм, төрмә киемнәреннән күреп: «Бу нихәл?» — дип сорады. Башымнан узганнарны сөйләп бирдем. Яңа кием алу өчен 500 сум акча бирде, яңа киемнәр киеп, өенә киттем, бергә утырып аш ашадык. Ничек тә булса паспорт юнәтеп, Рәсәйдән чыгып китүне уйлап утырдым. Хатыныннан, кайда куна калырга мөмкин, дип сорадым. «Гранд отель»гә киттем. Карыйм, миңа махсус бер бүлмә аерып куелган. Җиде көн отельдә яшәдем. Җиденче көнне отелем өчен акча түләргә теләдем. «Синең бүлмәңә бер ай өчен акча алдан түләнде», — диделәр. Аллага шөкер иттем һәм остазым янына кире кайттым.

Рәсәйдә күргәннәремне сөйләгәндә, остаз Әфгани миңа: «Ислам үзенең гаскәрен ничек яклаганлыгын күрдеңме инде?», — диде.

Өченче тапкыр ислам дәгъваты өчен Рәсәйгә киттем. Тагын алты айга төрмәгә утырттылар. Тик мин Япониягә качтым. Бу вакыйга һиҗри 1323, милади 1905 елда булды. Шул рәвешле остазымның кирамәте үзе үлгәннән соң да күренде.

Япониядә 8 ай калдым. Миңа зур хөрмәт күрсәттеләр. Анда мине ислам дәгъвасы өчен солтан Габделхәмид тарафыннан җибәрелгән дип уйлыйлар иде. Моның сәбәбе исә япон газеталарының берсендә минем турыда озын бер мәкалә басылу белән бәйле. Анда минем солтан Габделхәмид һәм остаз Җәмалетдин Әфгани тарафыннан җибәрелүем турында язылган иде. Моның нәтиҗәсендә Тышкы эшләр министры минем Япониядә калуымны үтенде һәм хезмәт хакы тәкъдим итте. Ләкин остазымның мөселман дәүләте төзү идеясен тормышка ашыру

10. Рәсәйдә кулга алыну вакыйгаларын сөйләгәндә, Г. Ибраһим даталарны бутаган булырга мөмкин: монда 1904 елның августында Истанбулда тотыкланып, Одессага, аннан Петербургка җибәрелүе хакында сүз бара булса кирәк.

11. Генерал Пётр Дмитриевич Святополк-Мирский (1857-1914). 1904 елның 26 августыннан 1905 елның 18 гыйнварына кадәр Рәсәй Эчке эшләр министры.

юлында ниләр эшләвен өйрәнү теләге мине Истанбулга кайтырга мәҗбүр итте… Бу дәгъваны Япониядә таратыр өчен, миңа андагы иптәшләремне дә алырга кирәк иде.

Истанбулга кире кайтканда, бар нәрсәнең үзгәреп беткәнлеген күрдем. Солтан Габделхәмиднең солтанатлыгына соңгы нокта куелган иде.

Остаз Җәмалетдин Әфгани (р.г.) белән дуслыгым өч ел да алты ай дәвам итте. Ул миңа бик ышана, минем турыда гел яхшы фикердә генә иде.

Авыруы һәм вафаты

Әфгани (р.г.) рак белән авырды. Дәваланса да, әҗәле якын иде. Беркөнне хәлен белергә киттем. Кулы белән ишарәт итеп, янына чакырды, чөнки сөйләшә алмый иде. Кулына каләм-кәгазь алып, болай дип язды:

«Әй Аллаһым, син беләсең ки, Пәйгамбәребез салаллаһу галәйһи вәссәламнең соңгы сүзе «өммәтем, өммәтем, өммәтем» иде, мин исә «милләтем, милләтем», диямен».

Ике сәгатьтән соң кире килгәндә остаз вафат иткән иде инде, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәт әйләсен. Тарих һиҗри 1315, милады 1897 елны күрсәтә иде.

Кардәшләр!

Истанбулдан чыкканда, сезнең белән күрешәчәгемне һәм сезгә остаз Җәмалетдин турында сөйлисемне алдан белми идем. Шуңа күрә хаҗ фарызымны җиренә җиткереп өйгә кайткач, Истанбулдагы балаларыма остазның тормыш юлына бәйле кайбер язмаларны миңа җибәрергә кушармын. Мәсихиләргә [христианнар] җавап итеп язган ул китаптан да берничә нөсхә соратырмын. Сезнең белән аңлаешлы бер телдә сөйләшкәнмендер дип ышанам, чөнки егерме еллап гарәпчә сөйләшкәнем юк иде.

Вәссәламе галәйкем вә рәхмәтуллаһ».

Шулай итеп, ислам миссионеры Гәбдерәшит Ибраһимның XX гасыр башында дөнья буйлап мөселман диненә чакырып йөрүенең нигезендә Җәмалетдин Әфганинең панисламизм идеяләре ятуын раслый торган бу нотык Әфгани эшчәнлегенең дә кайбер бәхәсле якларына ачыклык кертә. Мәсәлән, Г.Ибраһим аның суфичылыкка уңай мөнәсәбәтен генә дәлилләп калмый, тарикать шәйхе булуын да әйтә. Үлеменең сәбәбен дә көчле авырудан икәнен белдерә, югыйсә кайбер галимнәр аны, солтан Габделхәмид кушуы буенча, агулаганнар дигән карашта тора.

Әлбәттә, Г.Ибраһимның нотыгында сорау тудырган урыннар да юк түгел. Әйтик, христианнарга ислам динен пропагандалаган русча китапның исеме аталмый. Рәсәй хөкүмәте әлеге китап өчен эзәрлеклиме Г.Ибраһимны, әллә аның үзенең 1885 елда бастырган «Чулпан йолдызы» исемле әсәре турында сүз барамы? Аның чыгышын конспектлаштырган гади гарәп кешеләре өчен бәлки мондый сорауларның ул заманда бер әһәмияте дә булмагандыр, бүген исә без, татарлар, бу күренекле шәхесебез турында барлык детальләрне дә белергә телибез. ■

БАТЫРША

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА,
язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты,
тарих фәннәре кандидаты

Әйткәнебезчә, XVIII гасырның уртасы — Россиядә ислам диненә һәм рус булмаган халыкларга карата басымның иң нык көчәйгән вакыты. Бер яктан, Уралда сәнәгатьнең кисәк үсеп китүе, йөзәрләгән эреле-ваклы заводлар эшли башлавы аларга мәҗбүри беркетелгән җирле халыкны кол хәленә китерсә, икенче яктан, буш далада Ырынбур каласының калкып чыгуы да биредә патша хакимиятен көчәйтә, борынгы төрки-татар җирләре рус гаскәре һәм түрәләре белән тула. Ырынбур каласын төзүдә дә, Уралдан Казангача урнашкан хәрби кирмәннәре, ям йортларын тотуда да татар-башкортларның көчен файдаланалар, милләтне кара эшкә ат урынына җигәләр. Халык бушка эшли, аны теләсә кайсы вакытта патша хезмәтенә көчләп алып чыгып китәләр, урман кистерәләр, ям чаптыралар, үзен дә, малын да кызганмыйлар...

Әмма җанга иң нык тигәне көчләп чукындырулар була. Батыршаның яшьлегенә туры килгән 1735-1740 еллар — Россия тарихында татарлар өчен иң фаҗигале еллар ул. Бу чорда Идел-Урал арасында мөселман-татарларның каны елга булып ага, авыллар һәм мәчетләр ялкын-ут булып яна... Себер төрмәләре тагын татарлар белән тула, хатын-кызлар һәм балалар коллыкка сатыла, көчләп чукындырылып, чиркәү-монастырьларга ябыла. Азгын һәм аңгыра рус патшабикәсе Анна Ивановна татарларны бөтенләй кешегә санамый, аларны хайваннан да түбән дәрәҗәгә куя, бу хакта аның тарафыннан чыгарылган указлар сөйли... Ул чукынырга теләмәгән татарларны кыру өчен, Идел-Урал буйларына гаскәр арты гаскәр юллый, татарларны юк итүдә рус генералларына бөтен хокукларны бирә.

1736 елның 16 февралендә рус патшабикәсе Анна Ивановна татарларга каршы яңа указ чыгара, ул анда татарларның җирләрен тартып алырга әмер бирә, ул җирләргә рус крестьяннарын һәм каторжан христианнарны көчләп күчерергә боера. Боларга каршы баш күтәргән татарларны бернинди кызганусыз юк итәргә, йорт-җирләрен туздырырга, исән калганнарын руларга коллыкка бирергә яки мәңгелек каторгага сөрергә боера. Шушы явызлыкларны кылу өчен, Кама аръягына өстәмә рәвештә 22 меңлек рус гаскәре җибәрелә. Рус генераллары Кириллов, Румянцев, Татищев һәм башкалар Идел-Урал арасында татар халкын юк итү эшенә керешәләр... Идел-Урал арасына үлем килә...

Василий Татищев отряды, 1736 елның мартында, указ чыгып, бер ай үтүгә, Себер юлында, ягъни Батыршаның туган якларында, 90 татар авылын яндыра, 384 татарны җәзалап үтерә, 162 кешене әсирлеккә ала, 1247 ат һәм 850 сыерны халыктан талап ала, кешеләрне ач калдыра. Болар әле рус архивларында документаль рәвештә теркәлеп калганнары гына, ә исәпкә дә алып тормыйча үтерелгән татар-башкортлар күпмедер... (Бу мәгълүматлар

* Дәвамы. Башы журналның 10-11 саннарында.

һәм XVIII гасырда татар-башкорт күтәрелешләре белән бәйле алга таба кулланылачак башка мәгълүматлар түбәндәге хезмәтләрдән алынды: Акманов И.Г. Башкирские восстания. — Уфа, 1993; Вахит Имамов. Запрятаная история татар. — Набережные Челны, 1994; Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. — Казань, 1897; Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии. — М.-Л., 1940).

Бу рус генералы ике айда Нугай юлында 313 татар-башкорт авылына ут төртеп яндыра, 1658 татар-башкортны җәзалап үтерә, 300 кешене әсир итеп ала…

Рус генералы Румянцев Казан юлында 100 татар авылын яндыра, меңнән артык татарны газаплап үтерә…

Могҗиза белән исән калган татарлар моңа каршы сугыш белән җавап бирә, алар 10 меңлек гаскәр җыеп, руслар өстенә ташланалар. Татар ирләре коралга тотына, халык яуга күтәрелә. Алар, Румянцев һәм Кириллов отрядларына һөҗүм итеп, йөзләгән рус солдатын үтерәләр, ныгытмаларын яндыралар, рус авылларын юк итәләр. Татарларның һөҗүменә каршы тора алмаган рус генераллары, исән калган солдатларын алып, Минзәлә крепостена кереп качарга мәҗбүр булалар һәм ярдәм сорап, патшабикәгә мөрәҗәгать итәләр. Татарлар Минзәлә крепостен чорнап алалар һәм әсирлектәге мөселманнарны азат итүне таләп итәләр.

Рус патшабикәсе, үз генералларын татарлардан коткару өчен, ашыгыч чаралар күрә. Ул 1736 елның 6 августында яңа указ чыгара һәм Кама аръягына өстәмә гаскәр җибәрә. Татарларны җиңә алмаган вәхши Румянцев урынына тагын да явыз генерал Хрущёв билгеләнә. Ул шунда ук яугир татарларны астыра һәм кистерә башлый. Рус архив чыганакларыннан күренгәнчә, генерал Хрущёв 13 юлбашчы-татарны артлары белән очлы казыкка утырта, йөзләгән татар ирен кабыргаларыннан асып куя, дүрткә өздерә (четвертовать итә), 144 кешене сөргенгә сөрә, 505 хатын-кызны һәм балаларны русларга коллыкка сата. Халыктан 2 мең ат талап алына.

Татар җирләрендә рус генералларының вәхшилеге тантана итә…

Генерал Соймонов та явызлыкта башка рус хәрбиләреннән кимен куймый, 1737 елның җәендә ул 98 татар яугирен рәхимсез рәвештә, карап торып җәзалап үтерә, татарларның йөзләгән авылларын гына түгел, иген кырларын да яндырып китә, шулай итеп, аның җәбереннән исән калган халыкны да ач үлемгә дучар итә. 1738 елны ул Нугай юлында тагын 32 татар-типтәр авылын яндыра, 881 кешене җәзалап үтерә. Болар әле рәсми докуметларда теркәлеп калганнары гына, ә бернинди исәпсез үтерелгән татарлар күпмедер?

Рус патшабикәсе Анна Ивановна генералларының татарларга карата бу явызлыкларын хуплап, аларны үсендереп тора. Ул 1737 елны татар яуларын тизрәк бастыру өчен, зур акчалар вәгъдә иткән указ чыгара. Идел-Урал арасына гаскәр артыннан гаскәр җибәрелә, татарларны үтерү, авылларын яндыру гадәти бер нәрсәгә әйләнә. Бернинди судсыз һәм хөкемсез, бернинди гаепсез һәм сәбәпсез, бары тик татар булганнары өчен генә, бары тик мөселман булганнары өчен генә халыкны юкка чыгару башлана. Мондый максатчан үтерүне, геноцид димичә, тагын ни дип әйтәсең? Исән калган халыкка исә түли алмаслык салымнар салына, шул сәбәпле, мал-туарлары тартып алына. Нәтиҗәдә, татаралар ачлыктан кырыла башлый… Бу чорда татар халкы милләт буларак үлем чигенә килеп җитә.

Боларны яхшы белгән һәм Идел-Уралда татарларны юк итүне үзе оештырган рус генералы Василий Татищев, 1739 елның 22 февралендә патшабикә Анна Ивановна янына килеп, татар-

ларны ахыргача җиңүе турында рапорт бирә:

«Две опаснейшая — Казанская и Ногайская дороги так разорены, что едва половина осталась, а Осинская и Сибирская дороги — хотя не столько людей пропало. Однако у всех лошади и скот пропали. Деревни сожжены, и, не имея пропитание, многие с голоду померли», — ди генерал Татищев. Азгын рус патшабикәсе белән аның яшьлек фавориты Татищев: «Татар халкы инде беркайчан да баш күтәрә алмас», — дигән нәтиҗәгә киләләр.

Әйе, бу чорда татар халкы беркайчан да баш күтәрә алмаслык хәлгә китерелә. 1736-1737 елларда гына да Идел-Урал арасында 696 татар авылы яндырыла, 17 меңнән артык мөселман җәзалап үтерелә, 4 мең татар мәңгелек сөргенгә сөрелә, 10 мең төрки-татар хатын-кызлары һәм балалары русларга коллыкка сатыла. Исән калган татарлардан 17 мең баш мал-туар тартып алына, үзләренә 9194 сум штраф салына. Бу елларда русларга каршы милли азатлык сугышларында Казан губернасында 40 меңнән артык татар җәзалап үтерелә. Ул вакыт өчен бу — бик зур сан, бүгенге 40 миллион бәрабәренә тиң. Һәм шушы геноцид өчен әле беркем җавап бирмәде, рус хөкүмәте дә, рус чиркәве дә бу явызлыклары өчен татар халкыннан гафу үтенмәде.

XVIII гасырда Идел-Уралда рус гаскәриләре мөселман-татарларны җәзалауның иң вәхши алымнарын уйлап табалар. Әйтик, Василий Татищев әмере буенча, 1738 елның 28 февралендә Себер юлы мишәрләре Сабан Сабырколыв һәм Бәкшурга Назаровны дүрткә өздерәләр («четвертовать» һәм «колесовать» итәләр). Заманында урта гасырлар инквизиторлары гына кулланган бу җәза ысулы дөньяда иң рәхимсезләрдән санала һәм аны ул чорда руслардан кала бер җирдә дә кулланмыйлар. Җәзага тартылган кешенең башта тереләй аяк, бот, җилкә, бил сөякләрен сытып изәләр, чәрдәклиләр, аннан, аягы башына тиеп торырлык итеп, махсус тәгәрмәчкә салып әйләндерәләр. Кеше шунда зур газаплар белән үлә... Яуга күтәрелгән татар җитәкчеләренең дә күбесен әнә шундый газаплы үлем көтә...

Көчләп чукындырылганнан соң, яңадан ислам диненә кайткан татарларны исә тагын да катырак җәза көтә — аларны тереләй утта яндырып үтерәләр. Әйе, кеше ышанмаслык хәл — XVIII гасыр уртасында руслар чукынырга теләмәгән татарларны утта яндырып үтерәләр! Бу хакта да тарихта мәгълүматлар теркәлеп калган... Казан губернасының Уфа өязендәге Себер юлы мишәре Туйкилде Җүләковны, көчләп чукындырганнан соң яңадан ислам диненә кайткан өчен, 1738 елның 20 июнендә, патша указы белән Екатеринбург шәһәрендә утта яндырып үтерәләр. Бу коточкыч җәзаны көчләп чукындырылган бөтен татарлар карап торырга мәҗбүр ителә, Туйкилдене инквизиция учагында яндырыр алдыннан, аңа патшаның указын укыйлар. Менә ул вәхши фәрман, укыгыз һәм тетрәнегез! Бу хәлләр бит әле моннан 274 ел элек кенә булган...

«По указу Ея императорского величества самодержицы Всероссийской и по определению его превосходительства Тайного советника Василия Никитича Татищева, велено тебя, татарина Тойгильду, за то, что ты, крестясь в веру греческого исповедения, приняли паки магометанский закон, и не только что в богомерское преступление впал, но яко пес на свои блевотины возвратился, и клятвенное обещание, данное при крещении презрел, чем Богу и закону его праведному учинил великое противление и ругательство, — на страх другим таковым, кои из магометанского приведены в христианскую веру, при собрании всех крещённых татар велено казнить смертию — сжечь». (Анисимов Е.В. Дыба и кнут. Поли-

тический сыск и русское общество в XVIII веке. — М., 1999, С.541-542.)

60 яшьлек татар хатыны Кисәнбикә Байрасованы исә шул ук Екатеринбург шәһәрендә шундый ук «гаепләү» белән 1739 елның 30 апрелендә тереләй утта яндырып үтерәләр, ул тумышы белән Батырша хәзрәтнең хатыны туган төбәктән — Чиләбе якларыннан була... Яндыру алдыннан Кисәнбикәгә дә патшабикә указын укыйлар, анда: «По Указу Её Императорского Величества... оной татарке за три побега и что она, будучи в бегах, крещённая обасурманилась, учинить смертную казнь — сжечь», — диелә. Шуңа нигезләп, генерал-палач Соймонов үз фәрманын чыгара: «Пойманную татань-башкирку, которая была крещена и дано ей имя Катерины, за три побега и что она, оставя Закон Христианский, обасурманилась, за оное извольте приказать на страх другим казнить смертию — сжечь, дабы впредь, на то смотря, другие казнились». (ГАСО. Ф.24, оп.1, д.818, С.243-245).

Әмма җәзалар никадәр куркыныч булса да, татар халкы үзенең коллыгы белән беркайчан да килешергә теләми. Асып һәм яндырып үтерелгән татар яугирләре урынына яңалары баса, Килмәк абыз һәм Акай батырларны Абдулла Акаев, Сәетбай Алкин, Йосыф Арыков, Күчәп батыр, Сәет, Бәпәнәй батырлар, Мөслим Сарманаев, Зәит Аитов, Мандар Карабаев, Төклечура Алдагулов, Алдар Тарханнар алыштыра. Татар халкы дин өчен, ирек өчен, югалган дәүләтен яңадан торгызу өчен корбаннар бирә-бирә, рус басып алучылары белән сугышын дәвам итә. 1740 ел бу тиңсез көрәшнең иң хәлиткеч елы була, татарлар өчен зур фаҗигаләр елы була.

Генерал-майор Соймоновның әмере буенча, 1740 елның август-сентябрь айларында Себер һәм Нугай юлларында тагын 537 татар-башкорт авылы яндырыла, Уфа өязендә 725 төрки-татар авылы юк ителә, халыктан 5298 ат, 5736 сыер талап алына. Генерал Соймонов 3665 мөселман ирен яу кырында үтертә, 404 татарны үз кулы белән җәзалап үтерә, 802 кешене мәңгелек сөргенгә сөрә, 3026 мөслимәне, балалары белән биргә, русларга коллыкка сата. Аның кул астындагы рус гаскәриләре дә татарларны кыруда хуҗаларыннан калышмыйлар. Рус поручиклары һәм прапорщиклары Жданов, Ростовцев, Шишков, Скирманов, Веселов, Аристов, Загоскин, Дурасов, подполковниклар Павлуцкий, Путятин, Буткевич, майорлар Языков, Зимиский, капитаннар Микулин, Кублицкий, Возницын, Семенихин, Тарбеев, Сытин һәм Рогозиннар, бер-берләрен уздырып, ничә татар һәм башкортны үтерүләре турында югарыга мактанып рапортлар бирәләр, моның өчен патшабикәдән вәгъдә ителгән әҗерне көтәләр. Мөселман канын кызганмыйча койган өчен, патшабикә Анна Ивановна рус башкисәрләрен алтынга күмә, әҗерне бик мулдан бирә.

1740 елның 25 август көнне Ырынбур далаларында (хәзерге Орск шәһәре урынындагы беренче Ырынбурда) моңа кадәр кешелек дөньясы күрмәгән вәхшилекләр эшләнә — рус генераллары күзәтүе астында мәйданда берьюлы меңләгән татарны җәзалап үтерәләр... Көпә-көндез, якты кояш астында барабаннар кагып, туплардан атып, чаңнар чыңгылдатып, «Алилуй»лар улап, азатлык өчен көрәшкән татарларны кыргыйларча җәзалап үтерәләр...

Тарихның канлы пәрдәсен күтәреп, шул кара елларга күз салыйк...

Карагыз һәм уйланыгыз! Тыңлагыз һәм тетрәнегез... Бу хәлләр таш гасырда түгел, 1740 елны Рәсәй империясендә, Ырынбур далаларында бара...

Әнә ул үлем үзәнлеге... Генерал Урусов кул астындагы җәлладлар бирегә 6 мең татарны җәзалау өчен куып китергәннәр. Аларның бер өлешен хәзер эссе дала кояшы астында җәзалап

үтерәчәкләр, бер өлешен Сакмар крепостена алып китеп үтерәчәкләр... Ирләренең һәм улларының, аталарының һәм туганнарының газапланып үлгәнен татар хатын-кызлары һәм балалар карап торырга тиеш була, соңыннан исә аларның үзләрен дә русларга коллыкка сатарлар... Әнә тагын барабаннар кагалар, быргылар кычкырталар, бу вәхшилекне сизенеп, атлар ярсып кешни, этләр күккә карап улый, сабый балалар өзгәләнеп елый... Әнә кулаяклары богауланган татар ирләрен, бер-берләренә бәйләп, Ырынбур үзәнлегенә китерәләр, биредә аларны газаплы, рәхимсез үлем җәзасы көтә...

Кемне ничек үтерергә кирәклеген рус генераллары үзләре хәл иткән, чөнки патшабикәдән аларга мондый хокук бирелгән. Бу канлы вәхшәтне башкарып чыгарга исерек рус солдатларын куып китергәннәр, чөнки үз акылында булган кеше мондый ерткычлыкны эшли алмас иде... Үлем җәзасының иң авыры — кешене арты белән очлы таш казыкка утырту, 5 татар юлбашчысын әнә шундый газаплы үлем көтә... Сәрхуш генералларның акырып көлүе, быргы-барабаннар тавышы астында, аналары һәм хатыннары карап торганда, яугир татарларны шәрә килеш артлары белән таш казыкка утырталар... Бу хәтле вәхшәттән һәм хурлыктан, кояш булып кояш болытлар артына кереп качмакчы була, әмма битен капларга дала күгендә болыт кисәге таба алмый...

11 татар ирен кабыргаларыннан асып үтерү җәзасы көтә...

Башта адәм баласының тереләй сөякләрен тартып чыгаралар, аннан ботарлап, кабыргаларыннан асып куялар... Дала туфрагы кып-кызыл кан белән тула... Кеше, тамчылап канын югалтып, ата-анасы, газиз балалары каршында зур газаплар белән үлә...

Тагын барабаннар кагалар, быргылар кычкырталар, тагын «Алилуй»лар улыйлар...

Шушы кыргый, исерек тавышлар астында, 21 татар иренең кырылган башы, тәгәрәп, рус генералларының аяк астына барып төшә... Татарларның ачык калган күзләрендә бетмәс нәфрәт һәм үлем газабы чагыла... Моны карап торган балалары һәм аналары, акылларын җуеп, киселгән башларга барып ябышалар... Дала кыргый иңрәү авазы белән тула...

Әнә дарда 85 татар иренең гәүдәсе чайкала, алар якты дөнья, якыннары, бәйсезлек турындагы уй-хыяллары белән шулай мәңгелеккә бәхилләшә... Бу җансыз гәүдәләр әле монда атналар буе шом салып асылынып торачак... Исән калган татарлар беркайчан да русларга каршы баш күтәрмәсен өчен, башкаларны куркыту өчен тотачаклар бу мәетләрне дар агачларында...

Әнә бер читтә яугир татарларның телләрен, борыннарын, колакларын кисеп алалар, маңгайларына, тимерне утта кыздырып», «ВОР» дигән канлы тамга сугалар, аларның тереләй тиреләрен туныйлар... Империя өчен бу татарлар бур, татарларның илен, иреген урлаган рус дәүләте биредә әнә шулай «гаделлек» урнаштыра... 6 мең татар бер урында әнә шулай халык алдында җәзалана...

Аннан соң исән калган татарларны Сакмар крепостена куып китерерләр, канлы тамаша инде биредә дәвам итә... Монда 170 татарны төрлечә җәзалап үтерәләр, 301 кешенең телләрен, борын-колакларын кисеп алалар, меңләгән хатын-кызны һәм балаларны русларга кол итеп саталар...

Шулай итеп, Идел-Урал арасы тагы канга батырыла...

Татар илендә ачлык, төрле чир зәхмәтләре башлана...

Халыкның авыр хәленнән файдаланып калырга теләгән рус поплары, кулларына тәре тотып, тагын Идел-Урал арасына тараладар, тагын татар өстенә ябырылалар... ■

Дәвамы киләсе саннарда.

ТУФАН СТРОФАСЫ СЕРЛӘРЕ

ФӘРИДӘ ХӘСӘНОВА,
филология фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге мөдире

Бөтендөнья әдәбият тарихында шагыйрьләрнең үзләре уйлап чыгарган шигырь формаларына исем бирүләре мәгълүм күренеш. Мәсәлән, борынгы грек шагыйре Анакреон, тормыш матурлыгын җырлый торган шигырьгә үз исемен биреп, тарихка кереп калган. Антик шигырьнең спондей, дактиль, хорей стопаларын тезеп, яңа форма уйлап чыгарган грек шагыйре Ферекрат исеме белән аталган шигырь дә (ферекратов стих) яшәп килә (Квятковский 1998: 376).

Әдәбиятта һәр әсәрнең үз эчтәлеге һәм формасы була. Эчтәлек әсәрнең сыйфат үзенчәлеген билгеләсә, форма — шул эчтәлекнең яшәү ысулы, тышкы рәвеше. Эчтәлек формадан башка була алмый. Әдәби әсәр эчтәлеккә ия булырга һәм шул эчтәлекне яшәтә торган форманы табарга тиеш. «Эчтәлек белән тулы тәңгәллеккә ирешкән форма табылганда гына, эчтәлек һәм форманың тулы бердәмлегенә ирешкәндә генә, әдәби әсәр чын мәгънәсендә сәнгать әсәренә әверелә», — дип яза А.Әхмәдуллин (Әдәбият 1990: 221). Әдәби әсәрдә эчтәлекнең беренчел, форманың икенчел булуы турында бәхәсләр тынып тормый. Иҗат процессында эчтәлекне һәм шуңа туры килгән форманы эзләү бер үк вакытта бара. Чын әдип өчен форма үзмаксат була алмый, шагыйрь укучы алдында форма матурлыгы белән генә уңыш казануны күздә тотмаска тиеш.

Х.Туфан (1900-1981) да шигърияткә үзенчәлекле бишьюллык строфалы шигырь формасы алып килә. Аның 1940-1950 елларда бу өлкәдәге эзләнүләре яңа табышка китерә. Шагыйрь шигырьнең беренче һәм аннан соңгы юллары калган строфаларда бер-бер артлы беренче юл булып кабатланып килә торган (шулай

ук бердәй булган беренче һәм бишенче юл) строфалы шигырь формасында яза башлый.

Төрки шигърияткә әлеге строфа формасы Хафиз строфасы буларак кереп калган. Хафиз Ширази (чын исеме Шәмсетдин Мөхәммәт) — 1320/25-1389/90 еллар тирәсендә яшәгән фарсы шагыйре. Ул күпсанлы газәл, касыйдә, кыйтга, робагый, мәснәвиләр язган. Аның кайбер шигырьләрен татарчага Ф.Бурнаш һәм Х.Туфан тәрҗемә иткән (Татарский 1998: 630).

Шәрык поэзиясенең башка күренекле вәкилләре Хәйям, Фирдәүси, Нәвоиләрдән килгән, рус әдәбиятында С.Есенин тарафыннан уңышлы кулланылган бу форма Х.Туфанга уй-фикерләренең мәгънәсен тирәнәйтергә, эмоциональ тәэсир итү көчен арттырырга булыша. Нәтиҗәдә, гаҗәеп ягымлы, мөлаем лирик сурәт барлыкка килә. Рифмалашу тәртибе — аббаа. Әгәр моның дүрт юлын гына алып карасаң, монда әйләнмәле рифма күренә. Ләкин биредә 1-4 нче юллар гына түгел, 5 нче тезмә дә бердәй яңгырый. Шулай итеп, шактый катлаулы рифма барлыкка килә (Хатипов 2002: 69).

Бишьюллык строфа формасы Бөтендөнья әдәбиятында яңалык түгел. Тарих танка дип аталган, төп фикере шигырьнең баштагы өч юлына, нәтиҗә ясалган фикере исә соңгы ике юлына салына торган бишьюллык рифмасыз япон шигырен дә белә (Елисеев 2002: 245).

Якын һәм Урта Көнчыгыш шигъриятендә, кайбер Кавказ халыкларында, аерым алганда, әрмән халкында, «мөхәммәс» исемле бишьюллык шигырь строфасына юлыгыла. Мөхәммәс бер генә строфалы шигырь түгел. Аның беренче строфасында бер гомуми рифма яки «рәдиф» дип кабул ителгән поэтик синтаксис күренеше күзәтелә. Икенче строфаларның инде рифма төре бөтенләй башка була. Мөхәммәс строфасында һәр дүрт юл рифмалаша, соңгы бишенче юллар тагын үзара рифмалаша, алар хәтта бер үк сүз белән рифмалашырга да мөмкин. Мәсәлән, төрекмән шагыйре Молланепесның «Зөһрә һәм Таһир» дастаны шулай төзелгән (Квятковский 1998: 195). Хәзерге шигъриятә шагыйрә Ф.Тархановaның мөхәммәс строфа формалы шигырьләре бар (Тарханова 2000: 113).

Тагын бишьюллык строфа формасы, испан лирик шигъриятендә «квинтилла» дип исемләнеп, абааб рәвешендә рифмалаша. Әдәбият тарихыннан күренгәнчә, бишьюллык строфаның үз тарихы бар. Татарда Р.Фәйзуллинның һәркайсы исемле булган мөстәкыйль бишьюллыклары 1960 еллардан бирле мәгълүм булып, узган гасырның 70 нче елларында шигъри фикерне кыска формада белдерүнең иң югары һәм камил ноктасына кадәр барып җитә. Мисал өчен бер шигырь:

Ике көзгесе бар Кешелекнең:
Каберләр һәм күзләр.
Үткәне һәм бүгенгесе.
Ә калганы?
Ә калганы — бар да сәясәт!.. (Фәйзуллин 1996: 165)

Әдәбият

1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г.Әхмәдуллин. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1990. — 238 б.

2. Гайнетдинов М. Давылларда, җилләрдә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 280 б.

3. Даутов Р.Н., Рахмани Р.Ф. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2009. — 735 б.

4. Елисеев И.А., Поляков А.Г. Словарь литературоведческих терминов. — Ростов н/Д: Феникс, 2002. — 320 с.

5. Квятковский А.П. Школьный поэтический словарь. — М.: Дрофа, 1998. — 464 с.

6. Коллектив. Туфан: Истәлекләр, шигырьләр. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2000. — 152 б.

7. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. — Казан: Мәгариф, 2002. — 199 б.

Р.Харис, З.Мансуров, Г.Моратның да бишьюллык шигырьләре бар. Соңгы еллар шигъриятендә М.Мирза үзенә генә хас ритмик үзенчәлекләре булган бишьюллык строфа белән өр-яңа шигъри форма барлыкка китерде. (Хасанова 2009: 210-215).

Строфаның бер үк сүз яки сүз тезмәсе белән башлануы һәм бетүе эпистрофа (кире борылу, әйләнү) яки анэпифора (баштагы юлны азакта кабатлау) дип атала. Татар поэзиясендә бу стилистик алымның остасы булып Хәсән Туфан санала. Аның Себердәге тоткынлык чорында (1940-1956) язылган (Әдипләребез 2009: 457) «Хәят» (1942), «Иртәләр җитте исә» (1944), «Гөлләр инде яфрак яралар» (1945), «Яшьлек» (1947), «Халыклар Капкасы янында» (1947), «Кәрван» (1947), «Кара-Ком ягында» (1947), «Каплан Кырда» (1947), «Агыла да болыт агыла» (1951) (Туфан 2007: 228-268) исемле шигырьләре шул стилистик алым белән язылган.

Әмма исемнәре күрсәтелгән әлеге тугыз шигырьнең һәрберсе дә бер-беренә төгәл тәңгәл килә торган бердәй формалы түгел. Шулардан «Хәят» һәм «Агыла да болыт агыла» — алтышар, ә «Яшьлек» дүрт строфадан төзелгән, калган алты шигырь бишәр строфадан тора. Исемнәре күрсәтелгән шигырьләрнең төзелү формасының үзенчәлеге шунда: аларда анэпифоралы эпистрофа күзәтелә. Туфан һәрбер шигырендә аббаа формалы рифма тәртибен саклап яза.

Тугыз шигырьнең сигезе төгәл тугызлы үлчәм белән язылган, бары берсе — Әминә Җәлилгә багышлаулы «Иртәләр җитте исә» шигыре генә җиделе үлчәмдә калган силлабик шигырь. Бу шигырьнең өч строфасында цезуралар төгәл өч һәм дүрт ритмик буынны кисеп үтә. Ә менә дүртенче һәм бишенче строфаларда, цезураларның төгәл урынын һәм шигырь ритмикасын саклау максатында, фонетик яңгырашны җиделе шигырь калыбына «буйсындырырга» кирәк була. Безгә бу очракта 5 томлык «Әсәрләр»дә (236 бит) сүз уртасындагы иҗекнең [е] һәм [ы] авазларына тәмамлана торган өлеше төшеп калуга нигезләнгән синкопа күренеше кебек үзенчәлекнең күрсәтелмәвен әйтергә генә кала.

Галим М.Гайнетдинов билгеләп үткәнчә (Гайнетдинов 1989: 280), Хафиз строфасында шигъри әсәр беренче строфадагы шигырь юллары санынча — биш строфалы итеп төзелә. Хафиз строфасын татар әдәбиятында беренче булып Х.Туфан куллана башлый. Соңрак әлеге форманы Туфан строфасы дип атап йөртә башлыйлар. Әйткәнебезчә, «Яшьлек» шигырендә Х.Туфан Хафиз строфасына хас үзенчәлекне «үтәп бетерми»: шигырь дүрт строфадан гына гыйбарәт.

Килде дә ул, үтеп тә китте,
Шау-гөр килеп, сабантуй сыман.
Әйтте бугай: «Сагынсын Туфан
Иң ахыргы көненә тикле!»
Килеп шулай үтеп тә китте.

Әлеге шигырьнең 2 нче һәм 3 нче строфаларын укыганда (хәтта бер үк юлда ике тапкыр), 4 һәм 5 (2+3) иҗекле ритмик

8. Татарский энциклопедический словарь. — Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1998. — 703 с.

9. Туфан Х.Ф. Әсәрләр: 5 томда / төз. Гайнетдинов М.; 1 т.: шигырьләр, поэмалар; кереш сүз авт. М.Гайнетдинов.— Казан: Татар.кит. нәшр., 2007. — 479 б.

10. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма. — Казан: Раннур, 2002. — 352 б.

11. Хасанова Ф.Ф. Медитатиная лирика в поэзии татарского поэта М.Мирзы / MEDITATION LYRICAL AND BY TATAR POET MUHAMMAT MIRZA // Вестник Поморского университета им. М.В.Ломоносова. Серия «Гуманитарные и социальные науки». 2009. — № 9.

12. Хасанова Ф.Ф. Новый жанр в татарской литературе: «татарская танка» // Научный Татарстан. — 2009. — №4. — С. 150-155.

буыннарның төгәл тәртибен саклау максатыннан, тагын ритмикага бәйләнешле фонетик синкопа алымын кулланырга кирәк була. Шулай да бу шигырьгә 5 нче строфаның соралып торуын билгеләп үтү кирәк булыр. Дөрес, фикер төгәлләнә, ләкин шигырьнең мелодикасы дәвам итүне сораган кебек тоела. Хафиз строфасы шарты буенча «Килеп шулай үтеп тә китте», дип башланган бишенче строфа булырга тиеш иде. Ләкин шагыйрь фикерен алданрак — дүртенче строфа белән үк тәмамлый.

13. Хәсәнова Ф.Ф. Шигърияттә — яңалык // Казан утлары. — 2010. — №4. — Б.134-142.

«Хәят» шигыре — тугызлы үлчәм белән алты строфалык итеп төзелгән силлабик шигырь. Шигырьнең 5 нче строфасында лирик геройның халәте һәм монологы урын алган дип билгеләсәк, алтынчысы лирик герой хисе белән объект хисенең берләшүе буларак кабул ителә. Соңгы строфа өмет хисләрен белдерү өчен кирәк булып чыга. Шигырьнең дүртенче строфасында 2 тапкыр атом сүзе кулланыла. Бу строфаның дүрт юлында 4 һәм 5 (2+3) иҗекле ритмик буыннардан гыйбарәт булган цезуралар тәртибенең «бозылу»ы күзәтелә. Шигырьнең дөрес яңгырашын бозмас өчен, синкопа куллану сорала.

«Әсәр»ләрдә шигырьнең язылышы	**Шигырьне уку тәртибе**
Аерылабыз, ахры, озакка, —	*Айрылабыз, / ахры, / озакка, —//*
Атом чорының тыныч көннәрен	*Атом чорның / тыныч / көннәрен //*
Тилмерешеп көткән күзләрем	*Тилмерешеп / көткән / күзләрем /*
Атомнарга бүленер зиратта.	*Атомнарга / бүлнер / зиратта.//*
Аерылабыз күпкә, озакка.	*Айрылабыз / күпкә, / озакка.//*

«Аерылабыз» сүзендәге [й], [ы] авазлары әлеге шигырьнең тагын ике урынында ритмик яңгырашны «бозарга» мөмкин икәнлеге күренә.

Х.Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигыре күп галимнәр тарафыннан анализланды. Шул сәбәпле, безгә шигырьнең алтынчы строфасындагы «таулар аша» сүзләрен искә алмаганда, беренче строфаны кабатлавын әйтергә генә кала. Әлеге шигырь башкаларыннан 4 елга соңрак язылуы белән дә аерыла. Беренче строфада шагыйрьнең әйтеп бетермәү кебек поэтик синтаксис чарасы («Агыла да болыт агыла...») соңгы строфада капма-каршы позициягә күчә, ягъни күпнокталарның урыны үзгәрә: «...Агыла да болыт агыла...». Күренеп торганча, әйтеп бетермәү кебек стилистик алым әлеге символик тезмәне баштан алып ахыргача чорнап ала. Аңлашыла да: бу әле 51 нче ел гына...

Х.Туфанның 1945 елда язылган «Гөлләр инде яфрак яралар» шигыре дә — мәктәп дәреслекләреннән башлап, фәнни хезмәтләрдә һәрвакыт искә алынып килә торган шигырь. Галим Х.Курбатов Туфанның «Кая ашыгасың?» шигыренең дә үзенчәлекле строфа белән язылуын әйтә (Курбатов 2002: 148), ләкин ни сәбәптәндер, әлеге шигырь яңа чыккан биштомлыкта урын алмаган.

Шагыйрьнең 1947 ел язылу датасы белән Хафиз строфалы

дүрт шигыре яшәп килә («Халыклар Капкасы янында», «Каплан-Кырда», «Кәрван», «Кара-Ком ягында»). Алар, шагыйрьнең 1928 елның язынннан башлап, Кавказ һәм Урта Азия якларына икееллык сәяхәте нәтиҗәсе буларак язылган. Туфан географик атамаларны шигырьләрнең исеменә үк чыгара. Әлеге шигырьләрдә төрки халыклар тарихы, көнкүреше, табигате чагылу белән бергә, совет чорындагы «елгаларны борып, чүлне сугару» кебек «бөек төзелешләр» дә урын алган.

Билгеле, һәр уйлап табучы өчен аның дәвамчылары булу шарт. Хафиз строфасы белән язучылар Туфаннан соң булганмы дигән сорау туа. Шагыйрь Зөлфәт (1947-2007) иҗатында Хафиз строфалы шигырьнең еш очравы — нәкъ менә Х.Туфанның дәвамчылары булуы турында сөйли торган факт. 1971 елда Зөлфәтнең «Язмышлар ярында» исемле беренче мөстәкыйль җыентыгы Х.Туфанның кереш сүзе белән чыга. Мәкаләдә Туфан татар шигъриятенә үзенчәлекле шагыйрь килүен раслый. Шул «үзенчәлекле шагыйрьнең» күп кенә шигырьләре бишьюллык анэпифоралы эпистрофа белән язылган. Менә алар: «Чишмә сукмагы» (1993, 2 февраль); «Калыкты ай» (1993, 6 февраль); «Кызлар көлә» (1993, 2 февраль); «Мәҗүсиләп син шәм кабыздың» (датасы куелмаган); «Ярам-ярым» (1998); «Бәхет кошы өркеп очмасын» (1998, 8 июль); «Әйтми калганы» (1998, 21 декабрь).

Күренгәнчә, «үзенчәлекле» шигырь Зөлфәттә дә күп түгел. Аның «Калыкты ай» шигыре Туфанның токтынлык мотивларын дәвам итә. Күктә ай калкуын лирик герой тылсымга тиңли. «Айбичара» ялгыз җаннарга охшаган, нурларыннан тулып моң ага, ул уйлый, тыңлый. Лирик герой да үзен Айга тиңли. Серләрне дә бары тик Айга гына ышанып сөйләргә була. Айның «сары сагышы» лирик геройга да күчә. Шулай да соңгы строфадан шигырьдә оптимизмга урын калган дип уйларга нигез бар.

Калыккандыр бу ай кыйссадан.
Янсын яктың әйткән сүземдә,
Сары сагыш булып күземдә
Балкысын нур, чорлар кысса да…
Калыккандыр бу ай кыйссадан!

Зөлфәт иҗатында Табигать образының җанлануын, кешегә хас сыйфатларны ала барып, ахырда фаҗигале үлемгә дучар ителүен инкарь итеп булмый. Шагыйрьнең баллада жанрында язылган әсәрләре күп булу да моның бер дәлиледер. Әйтик, «Казан шәһәренең 39 нчы кварталы янындагы Сазлыкның төнге бәхилләшүе» шигыре (1976). Ә менә «Бәхет кошы өркеп очмасын» шигыре Хафиз строфасы таләпләренә тулысынча туры килә. Шигырьнең нигезен лирик геройның «Төнге аккаеным»а риторик эндәше тәшкил итә.

Чык төшсә дә, гөлләр егыла.
Иртәгесен уяныр ла ул,

Матур әдәбият

1. Гаташ Р.К. Бу — сиңа кылган догам: шигырьләр, газәлләр, робагыйлар. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1997. — 240 б.

2. Дэрдмэнд. Шигырьләр = Стихотворения / авт. предисл. и пер. с тат. В.Думаева-Валиева. — Казань: Татар. кн.изд-во, 2009. — 160 с.

3. Зөлфәт. Ике урман арасы: Эссе, шигырьләр, җырлар, поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. — 287 б.

4. Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты. — Казан: Рухият, 1999. — 416 б.

5. Зөлфәт. Ходай сулышы: шигырьләр. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2007. — 383 б.

6. Ибраһимов М.М. Адәм баласы: Шигырьләр. — Казан: Мәгариф, 2009. — 448 б.

7. Рәшит Ә.Ә. Язмыш җилләре: Шигырьләр, поэмалар; кереш сүз авт. З..М.Мансуров. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. — 271 б.

Тибрәп-тибрәп уйланыр ла ул!
Уйлы таңнар аткан чагында
Чык төшсә дә, гөлләр егыла.

Шагыйрьнең «Мәҗүсиләп син шәм кабыздың» шигыре тирән мәхәббәт лирикасына карый. Шагыйрь серле, тылсымлы, тигез, язмыштан ук насыйп булган мәхәббәт хисенә мәдхия укый. «Ярам-ярым» шигыре дә лирик геройның шомлы айлы-йолдызлы төнне искә төшерү хисләренә нигезләнгән. Шунысы үзенчәлекле: лирик геройның үкенечле сөю хатирәләре һәр биш строфада кабатланып килгән соңгы юл «феномены»на салына. Хафиз строфасында һәр шигырь юлының өчәр-дүртәр тапкыр кабатлануы күренә. Бер үк сүзләрнең, тезмәләрнең һәр очракта яңача яңгыравы шигырьнең моңлы мелодикасын китереп чыгара. Зөлфәтнең «Әйтми калганы...» исемле шигыре дә — бик матур мәхәббәт лирикасы шигыре.

Моң дигәнең / серләр / середер... //
Әллә әйтми / калган / сүз микән?//
Күңелеңә / төнме, / көн үткән?//
Тик бер генә / кара — / боз эрер!//
Моң дигәнең — / серләр / середер...//

Әлеге строфадагы мөлаемлыкны сизми мөмкин түгел. Шунысы кызыклы: Хафиз строфасының башка бер формасы белән язылган С.Есенин шигыре дә нәкъ шул интонацияне бирү көченә ия.

Свет вечерний шафранного края,
Тихо розы бегут по полям.
Спой мне песню, моя дорогая,
Ту, которую пел Хайям.
Тихо розы бегут по полям.

Зөлфәтнең «Чишмә сукмагы» шигыре (1993) Хафиз строфасына куелган барлык таләпләргә туры килә. Дөрестән дә, 4 һәм 5 (2+3) ритмик буыннан төзелгән 9лы үлчәмле Хафиз строфалы шигырь бу. Хәтта шигырьнең эчке интонациясендә үк Туфан рухы сизелә. Мисал өчен беренче һәм соңгы строфаларын укып карыйк:

Илләр искә төшкән чагында /
Күз алдыма килә гел генә — //
Сулар тибә чишмә төбендә, //
Кызлар көлә чишмә янында /
Илләр искә төшкән чагында. //

Илләр искә төшкән чагымда /
Утлы уйлар айкый күңелне: //
Кемнәр җырсыз итте бу илне? //

8. Сәлах Р.Г. Күңел бөртекләре: шигырьләр, поэма; кереш сүз авт. Ә.Рәшит. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2007. — 111 б.

9. Тарханова Ф.Г. Язмышлар язылганда: шигырьләр, хикәяләр. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2000. — 239 б.

10. Фәйзуллин Р.А. Җил — Вакыт ул... — Казан: Мәгариф, 1996. — 287 б.

11. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда / Төз. һәм кереш сүз авторы Ф.Хәсәнова; 3 т.: Шигырьләр (1990-2005). — Казан: Татар.кит. нәшр., 2006. — 511 б.

12. Шәех Л.М. Дүртенче кат... Бишенче кат...: шигырьләр, поэма; кереш сүз авт. Р.Миңнуллин. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. — 176 б.

...Гүяки мин хөкем алдында — /
Илләр искә төшкән чагында...

Бик матур яңгырашлы беренче строфаның төгәл вертикаль цезуралы ачык иҗекләр системасына нигезләнүен сизми калу мөмкин түгел. Тик калган строфаларда әлеге тәртип тулысынча сакланмаган. Шулай да югары дәрәҗәдәге шигырь техникасы белән язылган бу әсәрне һич тә сәясәткә кагылышлы итеп күрәсе килми, билгеле. Әмма шигырьнең дүртенче строфасы тагын сискәндерә:

Кызлар көлә чишмә янында.
...Ул чишмәләр кипте ләбаса —
Яңа заман — яңа тамаша!
Хыялымда бары, җанымда
Кызлар көлә чишмә янында. (Зөлфәт 1995: 271)

Зөлфәт Хафиз, Туфан строфасын кулланып шигырь генә язып калмый, бәлки анэпифоралы эпистрофалы шигырьне баета, төрләндерә дә. Шундый бер шигыре «Күзлут» (1996) дип атала. Зөлфәтнең әлеге шигырендәге үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: ул биредә, ритмик буын тәртибен һәм 9лы шигырь үлчәмен саклап, алтыюллык анэпифоралы алты эпистрофалы шигырь уйлап чыгара. «Бездән калыр-калмас эзләр бар» (1996) шигыре дә нәкъ шундый формага нигезләнә. Тик бер үзгәреш белән — соңгы алтынчы строфага тагын бер юл өстәп. Әлеге артык җиденче юл ахырдан (бәлки баштандыр) шигырьнең исеменә үк әйләнә. Шул юл белән шагыйрь анэпифоралы строфаның «бар таләпләре»н дә үтәүгә ирешә. Җиденче юл булмаган очракта, шигырьнең исеме икенче төрле булыр иде.

Йолдыз нуры тамсын җаныңа!
Керфегеңә җилләр кагыла,
Һәр бөртеге саен — якты таң...
Сөю өстен икән Вакыттан
Куеныма сеңгән чагында...
Йолдыз нуры тамсын җаныңа!
Бездән калыр-калмас эзләр бар.

«Сөйләшик бер, гомер, синең белән!» (1974) шигырендә Зөлфәт эпистрофаны башкача төрләндерә. Шигырь шулай ук биш строфадан төзелгән, әмма бу Хафиз строфасын башкача куллану. Шагыйрь шигырьнең һәр икенче юлын соңгы юлда кабатлап бара. Ирексездән ни сәбәпле Зөлфәт, Хафиз строфасы «таләпләрен бозып», строфаның беренче юлына игътибарсыз соң дигән сорау туа. Менә өченче строфадан бер мисал:

Син дә, гомер, олгаясың бугай,
Җитдиләнә бара карашың;

Бала чагым илләреннән мине
Нинди илгә алып барасың?
Җитдиләнә бара карашың.

Китерелгән мисалдан күренгәнчә, шагыйрь строфаның беренче юлында риторик эндәш яки лирик геройның күзәтүен «урнаштыра», кабатлана торган юлның беренчесендә фараз итүен бирсә, икенче тапкыр кабатлаганда нәтиҗә ясарга омтыла. Шигырьнең төп фокусы — Гомер образы. Лирик герой аны сөйләшергә чакыра, ул башта йолдызлы күкләр буйлап йөрергә тели. Әмма уе барып чыкмый, ил өстендә төнге җил йөри башлый. Торабара гомер үзе дә олыгая бара, күзенә көз ялкыны капкан каеннар күренеп ала, йөргәндә дә сары яфракларга басып атлый. Шигырьнең 1974 елда ук язылуына игътибар итсәк, бу аның яңа строфа тудыруда беренче тәҗрибәләре булуы да мөмкин дигән нәтиҗә ясау ихтималы килеп чыга. Белгәнебезчә, Зөлфәтнең Хафиз строфалы шигырьләре, нигездә, 1993, 1998 елларда язылган.

Хафиз строфасы булмаса да, Дәрдмәнднең «Нидер, и сөйгәнем, бу яшь күзеңдә» шигыре дә строфаның икенче юлын кабатлап бару формасында язылган (Дэрдмэнд 2009: 18). Барысы ундүрт юлдан төзелгән бу шигырьдә Дәрдмәнд «Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?» юлын дүрт тапкыр кабатлауга ирешә. Шигырьнең беренче башланып киткән юлында риторик эндәш яки лирик геройның күзәтү нәтиҗәсе ачык беленеп тора. Кыскасы, эпистрофа таләпләре үтәлә.

Бишьюллык строфа формасы яшь шагыйрьләрдән Л.Шәех (Шәех 2008: 42) һәм Р.Сәлах (Сәлах 2007: 61) иҗатларында күзәтелә. Ләкин бу шигырьләр Туфан строфасы таләпләренә туры килми: метрик система һәм рифмалар тәртибе үзгә булган верлибр шигырьләр бу. Л.Шәехнең «Бер җылы сүз» шигыре период алымы белән язылган булса, Р.Сәлахның «Син кил әле...» исемле эпифора дип аталган стилистик фигуралы бишьюллык шигырен ун да тугызлы үлчәмле традицион дүртьюллык строфага бик җиңел генә әйләндереп була. Шулай булса да, безнең карашыбызча, нәкъ менә Р.Сәлахта Туфан строфасына якынаю сизелә. Әллә бу «Буа феноменымы?» дигән сорау да туа, хәтта.

1990 елларда эпистрофалы шигырь язу Буа шагыйре Р.Хариста күзәтелгән иде. Аның иҗатында бары ике шигырь — «Мин кабат кадерле җылыда» (Харисов 2006: 323) һәм «Якында булсаң да — еракта» (Харисов 2006: 329) шигырьләре анэпифоралы эпистрофа юлы белән язылган. Дөрес, шигырьләрнең икесе дә төгәл Хафиз строфасы түгел. Шагыйрь андый максат куеп язмаган да. Тикшерү өчен аларны эпистрофа буларак мисал итеп алабыз.

Мин кабат / кадерле / җылыда... //
Көз сеңгән / яфраклар / keләме... //
Язны да, / җәйне дә / теләмим — //
Ә гөлләр — / чәчәктә... / Нигәдер /
Мин кабат / кадерле / җылыда. //

Р.Харисның «Мин кабат кадерле җылыда» шигыре дүрт кенә строфадан төзелгән. Рифма тәртибе болай: абаба / абаба / абвба / абвба. Күренгәнчә, рифма тәртибе Хафиз строфасына туры килми. Шигырьнең һәр строфасында беренче һәм бишенче юллар бертөрле кабатлана, шулай да строфаларның тезелү тәртибе башкача: шигырьнең беренче юлы һәр дүрт строфада да баштагы һәм азактагы юллар булып кабатланып бара. Бу, дөрестән дә, чын анэпифоралы эпистрофага нигезләнгән шигырь. Р.Харис шигырендә 9лы үлчәм сакланса да, ритмик буыннар тәртибе Х.Туфан һәм Зөлфәт шигырьләреннән үзгә: цезуралар вертикале һәр өчәр иҗекле ритмик буынны кисеп үтә, ә алдагы ике шагыйрьдә беренче цезура дүрт иҗектән соң килә иде. Р.Хариста да цезураларның урыны төгәл билгеләнгән һәм ул башта ничек булган, шулай ахыргача үзгәрми. Шигырь техникасы югары дәрәҗәдә. Ул лирик геройның яңа мәхәббәт хисләрен ачуга юнәлдерелгән.

Шагыйрьнең икенче шигырендә дә Хафиз строфасы таләпләре тулысынча үтәлми. «Якында булсаң да — еракта» шигыре анэпифоралы эпистрофа сыйфатларын алса да, өч кенә строфа белән калган. Бу шигырьнең дә ритмик системасы алдагысына охшаган кебек, әмма рифмасы бүтән, дөресрәге, ул төрле. Беренче строфадагы рифма тәртибе калган строфаларда сакланмый. Әлеге шигырьдә рифма менә ничек: аабаа / абаба / аббба. Ә менә Туфан белән Зөлфәттә рифмаларның тәртибе Хафиз строфасы рифмасына тулысынча туры килә иде.

Р.Харисның эпистрофалы «Мин кабат кадерле җылыда» шигыре белән Туфан һәм Зөлфәтнең Хафиз строфасында зур аерма бар икәнлеген әйтми калу ярамый. Билгеле, шагыйрь әйтәсе фикерен яки белдерәсе хисен бишьюллык строфада белдереп калырга дип «планлаштыра». Безгә бишьюллык строфага «сыймыйча», киләсе строфага да чыккан (интонацион фраза бүленеше белән метрик бүленешнең туры килмәвенә нигезләнгән) фраза бүленү кебек поэтик синтаксис алымы белән очрашырга туры килмәде. Ә менә традицион дүртьюллык строфада синтагма бүленү очраклары. күп булмаса да, очрый торган шигъри күренеш, гәрчә ул шигъри гармониягә зыян салса да.

Шулай да Х.Туфан иҗатында да ике строфа арасында фраза бүленү алымын безгә табу насыйп булмады (хәтта шагыйрь иҗатын өйрәнгән тикшерүчеләр дә бу фактны күрсәтми). Ә хәзер Хафиз строфалы шигырьне өч шагыйрьдән дә берәр мисал итеп китерик.

Хәсән Туфанның «Каплан-Кырда» шигыреннән өзек:

«Чүлдә сиңа, Кеше, ни кирәк?»
«Су кирәк, су! Чүлдә су булсын,
Дәрья тагын Каспийга койсын!
Сахраларны гөлстан итсәк,
Чүлдә миңа бүтән ни кирәк?!»

Зөлфәтнең «Бәхет кошы өркеп очмасын» шигыреннән өзек:

Чык төшсә дә, гөлләр егыла.
Иртәгесен уяныр ла ул,
Тибрәп-тибрәп уйланыр ла ул!
Уйлы таңнар аткан чагында
Чык төшсә дә, гөлләр егыла.

Ренат Харисның «Мин кабат кадерле җылыда» шигыреннән өзек:

Мин кабат кадерле давылда...
Дөньяңда җил булып очамын.
Бер узган гомерләр кайтмый дип,
Әйтсәләр, мин ничек ышаныйм?!
Мин кабат кадерле давылда.

Һәр өч шагыйрьдә дә беренче юл бәйсез, мөстәкыйль формада язылган. Х.Туфан шигырьләрендә шигырь юлларында яки юл ахырында интонацион фраза бүленеше белән метрик бүленеш туры килә. Шулай да безнең максат шигырьгә «бишенче тәгәрмәч» нигә кирәк икәнен ачыклау иде. Х.Туфан шигырендә ул эмоциональлекне көчәйтү белән бергә мәгънә бөтенлеген тәэмин итү өчен дә кирәк. Зөлфәт шигырендә, Туфаннан аермалы буларак, бишенче юл кыска цезурадан соң килә. Шулай ук фикерне төгәлли, хисне көчәйтеп җибәрә. Харис шигырендә бишенче юл, баштагы ике шагыйрьдән аермалы буларак, синтаксик яктан тулысынча тәмамланган фикердән соң килә. Ләкин әлеге фикерне шагыйрь, сорау билгесе белән тәмамлап, «җавап сорый» торган итеп формалаштыра. Һәм соравына җавап ала да. Ул җавап бер үк вакытта эмоциональ дә, лирик геройны тынычландыра да, фикергә дә ачыклык кертә. Шулай да Р.Харис шигыреннән бишенче юлны алып ташларга мөмкин икәнлеген дә күрсәтеп үтү дөрес булыр. Ә алдагы ике шигырьдә моны эшләп булмый: синтаксик яктан җөмлә бөтенлеге югала. Димәк, Хафиз строфасындагы «бишенче юл феномены» «арбаның бишенче тәгәрмәче» була алмый, дигән нәтиҗә килеп чыга. Шагыйрьләргә бу очракта шигырь, Мөхәммәт пәйгамбәргә вәхиләр иңгән кебек, бер эчтәлек — бер форма булып «иңә», дигән фикергә ышанырга гына кала.

Соңгы елларда татар шигъриятендә М.Мирза мөстәкыйль бишьюллык строфалар язып танылды (Ибраһимов 2009). Әмма аның бишьюллыклары Туфан строфасы түгел. Мирза бер строфалык кыска шигырьләр яза. Саны биш йөздән дә артып киткән әлеге мөстәкыйль шигырьләр «Адәм баласы» исемле уртак бер циклны тәшкил итә, күпсанлы шигырьләрне Адәм баласы исемле бер гомумиләштерелгән образ бәйләп тора. Мирза строфасының Туфан строфасыннан төп аермасы шунда, аның шигырен ике һәм өч юллардан торган өлешләргә бүлеп була. Ә менә Туфан строфасын бүлеп булмый. Ул — бербөтен. Шулай да бик тырышканда Зөлфәт белән Туфан шигырендә өч юлдан соң «тукталып хәл

алырга» була. Ә Р.Хариста киресенчә — ике юлдан соң. Димәк, Зөлфәттә Туфан белән охшашлык күбрәк булып чыга.

Туфан строфасы хәзерге шигърияттә тагын бер Буа ягы шагыйрендә күзәтелә: ул да булса — шагыйрь Әхмәт Рәшиттә. Безгә аның Хафиз строфасына куелган бар таләпләрне үтәп язылган бер генә шигырен табу насыйп булды, гәрчә шагыйрьнең бишьюллык строфа белән язылган әсәрләре берничә булса да. Без эзләгән шигырь — ул «Каршылау идиллиясе» исемле (Рәшит 2006: 194).

Йә, мәрхабә, / яңа көн таңы, //
Күңелләрнең / сүндер сагышын — /
Татлы булсын / безнең кавышу, //
Мәхәббәтен / сөйлә син аның — /
Йә, мәрхабә, / яңа көн таңы! //

Күренгәнчә, Ә.Рәшит Туфан строфасы рифмасын һәм ритмик системасын саклап яза. Туфан, Зөлфәт, Ә.Рәшит шигырендә дүрт иҗектән соң, ягъни һәрбер тәфәгыйльдән соң, кече цезура килү күзәтелә. Әлеге күренеш шигырьнең гаруз системасыннан силлабикага күчүен дәлилли торган сыйфатларның берсе булып тора. Шигырь тулысы белән күңел лирикасы төренә карый. Хис агышына килсәк, ул салмак. Гомумән, Хафиз строфасы белән язылган шигырьдә ярсу хис була алмый, хисләр агышы салмак, тигез, тыныч. Бу шигырьдә дә иртәнге таң туып килә, тынлык. Лирик геройның очучылар эшенә катнашы бар икәнлеге күренә, бәлки ул юлчыдыр йә эшчедер. Самолётлар да, вертолётлар да очмый. Шагыйрь бу сүзләрне «очкычлар һәм боргалаклар» дип бирә. Нәтиҗәдә, лирик геройның берәр аэродромда утырып, сөйгәне янына ашкынуы сурәтләнгән дигән фикер кала.

Анэпифоралы эпистрофа формасы Ә.Рәшитнең тагын «Әллә?.. Әллә?..» дип исемләнгән И.Шакировка багышламасында күренә. Әмма шигырь Туфан строфасы түгел. Ул алтышар юллык өч строфалы эпистрофа буларак кына карала ала.

Нигә җырлыйсың син / үзәк өзгеч җырны? //
Бәгырь уртасына / күз яшьләре тама: //
Кемгә гаҗәп бу җыр, / кемгә газап бу җыр, //
Кемгә яңгыр ява, / кемгә йолдыз яна. //
Өзгәләнә күңел / һаман, һай, сызлана: //
«Әллә яңгыр ява... / әллә йолдыз яна...» //

Өзектән күренгәнчә, алты буынлы рәмәл цезурасының бишенче юлда урыны ныклы түгел, ул тагын ике иҗек киткәч соралып тора. Шигырьнең калган ике строфасында гаруз ритмы тәртибе саклана. Ә.Рәшит иҗатында бишьюллык строфа формасы «Фәлсәфи парадокслар» исемле күләмле шигырендә күзәтелә. Ләкин бу инде Туфан строфасы түгел. Шагыйрьнең «Казан» поэмасы да тугызлы үлчәм, бишьюллык строфа белән язылган.

Әмма поэманың рифма тәртибе бертөрле түгел. Аерым строфалар бер катлаулы кушма җөмләне хәтерләтә. Шул «җөмләдә» ике төп фикер — ике баш җөмлә шәйләнә. Өченче җөмләне шагыйрь өч юлга тигез итеп, тугызар иҗектән бүлеп «урнаштырган кебек» тоела. Бер җөмлә булганлыктан, ике янәшә юлда озын цезуралар кую мөмкинлеге дә калмый. Шулай да строфаларда Хафиз строфасына хас интонация һәм мелодика сизелә.

Утырам / Казансу ярында, //
Дулкыннар / тәгәри Иделгә — //
Аларның / шул гамьсез җырына /
Бик теләп / кушылыр идем дә, /
Нигәдер / ямансу күңелдә. //

Бишьюллык биш строфалы (нәкъ менә биш строфалы!) шигырь Рәдиф Гаташ иҗатында да бар. Мисал өчен ике шигырьне генә алыйк: «Бишенче каләм. Синең хат» һәм «Ләйләләр язса...» шигырьләре (Гаташ 1997: 45). Икенче шигырь эпифоралы эпистрофа стилистик фигурасы кулланып язылган, һәр икесе 11ле үлчәмдә. Әмма бу шигырьләр Хафиз строфасы түгел. Р.Гаташ кулланган метр башка шигырьләрдән цезуралар тәртибе белән дә нык кына аерыла. Беренче цезураның урынын төгәл генә билгеләү кыен: ул йә дүрт, йә биш иҗектән соң туры килә, йә сүзне бүлә. Ә менә рифмалар тәртибе Туфан строфасындагы кебек. Шигырьдән Шәрык мотивларын, гаруз интонациясен тоймый калу мөмкин түгел.

Нәтиҗә ясап, «әдәби әсәрдә эчтәлек беренчел, әйдәүче як булса да, ул үзенә лаеклы форма табылганда гына яшәеш ала, әсәрнең эчке бөтенлеге тик шул вакытта гына хасил була. Иҗат процессы асылда бер үк вакытта эчтәлекне һәм шуңа туры килгән, тиң форманы эзләүдән гыйбарәт. Чын әдип беркайчан да форманы үзмаксат итеп куймый, ягъни укучы алдында форма матурлыгы белән генә уңыш казануны күздә тотмый» (Әдәбият 1990: 221) икәнлеген истән чыгармыйк.

Хафиз строфасы — катлаулы күренеш. Аңа бишьюллык строфа формасы дип кенә карарга һич ярамый. Бишьюллык строфа белән язучылар бар ул. Н.Акмалда, Сөләйманда, Х.Бәдигыйдә, Р.Зәйдуллада бишьюллыклар бар, ә менә Туфан строфасы юк. Аның шигърияттә сирәк очравы рифма һәм ритм системасының катлаулы булуыннан киләдер. Хәтта без күрсәткән сирәк мисалларда да «нормадан» тайпылышлар бар.

Шулай да Хафиз строфасы традицияләрен өйрәнгән, тәрҗемә иткән Х.Туфан татар әдәбиятында үз дәвамчыларын әзерләп калдыра алган. Аның үзе зур шигърияткә фатиха биргән шәкерте шагыйрь Зөлфәтнең камил дәрәҗәдә эшләнгән Туфан строфалы шигырь формалары булу шул турыда сөйли. Ә Зөлфәттән соң кем килер? Хәзергә әлеге сорауга җавап ачык күренми... ■

ЙОЛДЫЗЛАР ТӨСТӘН ЯЗГАНДА...

РИФӘ РАХМАН,
язучы, Ф.Хөсни исемендәге премия лауреаты,
филология фәннәре кандидаты

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК*

Себер край инспекцияләренә буйсындырылган Томск төзәтү учреждениеләре арасында көчләп хезмәт иттертү лагерьлары төп урынны алып тора икән. Егерменче еллар башында хәрбиләрнекеннән сөрелгәннәрнекенә әверелдерелгән төзәтү оешмасы шәһәр предприятиеләрен аякка бастыру белән шөгыльләнгән. 1923 елда лагерьны юкка чыгарганнар, ә төзәтү-арестант бүлеге белән губерния төрмәсеннән мәҗбүриләп эшләтү йортлары ясаганнар. Тора-бара түрәләргә анысы да ошамаган: зиндан һәм төзәтү йортларын тагын аерым-аерым иткәннәр. Хуҗиәхмәт, ахыр чиктә барыбер дә әнисеннән аерылып, балигъ булмаган җинаятьчеләрнең Себер край йортына тапшырылды. Үзе көн иткән йортның үткәне белән Хуҗиәхмәтне тарих дәресендә бик яхшылап таныштырдылар. Дөрес, аларның күпчелек гомере хезмәт колониясенең производство бинасында уза, әмма үсмерләрнең сәяси аңлылыгын үстерү, большевиклар идеологиясендә тәрбияләү кебек нәрсәләргә дә монда вакытны кызганмыйлар иде.

Җанбикә үзен халык дошманнарының хатыннары лагерена урнаштырырлар һәм, кайдан килгәнлеген исәпкә алып, авыл хуҗалыгы эшләренә билгеләрләр, Хуҗиәхмәтемнән, Аллаһ боерса, исән-имин туган якларына кайтканчы, бик ерак китмәм әле, дип өметләнгән иде, юкка булган икән — ул, юлга туң төшү белән, этапта Омск каласыннан төньяктарак урнашкан Кулай елгасы янындагы бер поселениегә — кулаклар күчереп утыртылган бистәгә җибәрелде.

Кулай дигәннәре бер дә кулай булып чыкмады. Сазлыклар эченнән талгын гына агып утырган бу елгачык тирәсендә төп халык яшәми диярлек, чөнки үлән-куак дигәне дә бик рәтсез, агач дигәне дә бик гарип һәм кечкенә, юлы да — кышлык кына.

Ач үлемнән беренче көннәрне Җанбикәне бу тирәләргә узган гасырда ук Казан ягыннан күченеп килгән татар гаиләсе коткарды: үзләре корып кергән йортка да алдылар, соңгы ризыклары белән дә бүлештеләр. Өеңдә ятсаң, дөньяныкын кайдан белер идең, дип уйлады хатын. Менә бит, аның яңа ахириләре дә кулаклар исемлегенә туганнарының ятим улларын өйләренә кертеп яшәткән өчен генә эләккән: шунда ук батраклы гаилә дип язып куйганнар.

Димәк ки, Себердә дә шул ук җилләр исә икән. Үз байларын, үз кулакларын да илгә хезмәт итәрлек түгел, кешечә көн итәрлек тә шартлары юк Кулайга, шуның ише башка сазлык-

* Ахыры. Башы журналның 7, 8-9 саннарында.

лы тирәләргә куалар булып чыкты. Ишле гаиләле себерлеләр әле беренче елларны адәм яшәмәгән сазлыкларда тулаем диярлек кырылып беткәннәр. Безнекеләр туган якларыннан монда качканда, алар исә башка якларга китеп котылуны хуп күрә, имеш.

Инде безне ни көтә дип уйлый иде аның саен Җанбикә. Утызынчы елны бунт күтәрүдә гаепләнеп, Васюган кебек сазлыкларга куылган кәрваннардагылардан беркем дә исән калмаганда, ирсез-терәксез Җанбикә исән калырмы? Әтисез-әнисез, улсызкызсыз, җилкәсенә баш куеп еларлык дусты да булмаган татар хатынын ач бүре карынысыдай төпкелләр оясында ни көтә…

Исән калырыңа, чыннан да, бер өмет уятырлык нәрсә юк. Соңрак раскулачивать ителгәннәрнең дә, үзләре чокыган җир алачыкларда салкын тиеп, ачлыктан шешенеп, үләнкайрыдан эчләре күбеп, бик күбесе үлгән. Торсынхан агайның гаиләсе дә үлгән атларының тиресен, киеп килгән итекләренең күнен кадәр пешереп ашаган. Җанбикә аның сөйләгәннәрен күз яше белән тыңлый. Безнең белән бергә сөрелгән ничә мең кешедән күпмесе генә калгандыр, ди карт, уфылдап. Бу сазлыклардан качып та котылырлык түгел: үземнең андамонда чыгарга омтылып күтәрелгән кул-аякларны күргәнем булды. Ярдәм итәм дисәң, үзеңнең дә баткаклыкка төшеп киткәнеңне көт тә тор. Инде үле гәүдәңне кем дә булса чыгара калса, итеңне тунап ашамас дип кем ышана?!

***

Ризыгың киселмәгән булса, кырыс Себер туфрагында да исән каласың икән. Акланып, туган ягына кайтып килгәндә, Җанбикә инде шулайрак уйлады. Илле җиденең июне иде. Җәйге юллары соңгы вакытларда рәтлерәк булса да, почта элемтәсе җайга салынмаган Кулайда гаиләсе белән бәйләнешен ул тәмам югалтты.

Сугыштан исән калган булса, Хуҗиәхмәт хәзер утыз бер яшьтә инде дип уйлады әни кеше. Аның белән хатлар да алышкан иде, бераздан өзелде. Исәндер, исәндер, дип кабатлады Җанбикә, аякларын кызулата барып. Исәндер-исәндер: фронтка китүе дә соң гына, күңел дә аның өчен артык хәвефләнми.

Җанбикә каенанасы Гөләфтар белән кызы Гөлхәбирәне ел дигәндә югалтты. Әнкәсенә ошап, чибәр булып үссен дип, исемен дә аныкына охшатып куйган иде ул. Исем кушканында да, аякка басып киткәнендә дә, озын гомерле булсын, дип теләргә булган икән… Кыз кешене авылның бер чибәре итеп күрәсе килә шул…

Олы юлда, кул күтәреп, йөк машинасына утырган иде, кайда барганлыгын да сорамаган, шофёр рульне Кызыл Аланга таба боргач, егет йөзенә күз ташлады да тынсыз калды. Янәшәсендә генә аны ерак Себер киңлекләренә алып китәчәк эшелонга этап белән озата барган егет утыра иде! Җанбикә шофёрга тагын бер карады, тагын, тагын… Аннан гына аңышты: Нурәхмәт түгел дә түгел инде! Шофёр яшенә күрә, булса да аның улы гына буласы. Егерме биш ел узсын да син киткәндәге егетләр егет булып калсынмыни?!

Кем көтә, ни көтә иде Җанбикәне авылда — ул бу турыда уйларга теләмәде. Солтанморат белән Хәмидулла картның табылмавыннан, әнкәсе, үз әнисе, кызы вафатларыннан хәбәрдар булгач, калганы нәрсәгә дип уйлады, ни көтсә, шул булыр…

Әйтүен әйтәсең дә, соңыннан терсәкне тешлисең. Исән-имин булса, дип теләү җитми, исән-имин булса… Ул әле тагын шул сүзне исенә төшерәчәген белми иде.

Нурәхмәткә охшаган шофёр,

Җанбикәне Кызыл Аланның Сабир исемле байларыннан калган таш кибет янында төшереп калдыргач, машинасы авылның икенче башына — аның балачагы узган югары очка таба элдертте. Җанбикәгә үз турларына кадәрле аның белән генә барса да буласы иде — теләмәде. Әле төшеп калып, өсбашын рәтләгәч, чәчләрен тәртипкә китергәч, аяк-кулларын язып алгач та, туп-туры өйләренә таба атларга базмады. Йөрәгендә нindидер шом шикелле нәрсәне тойды. Авыл кешеләре булса, берәр танышрагы очрамасмы, күчтәнәч-мазар да алырмын, дигән сылтау белән кибеткә керде.

Киштәләре буш кибетнең сату прилавкасы артында аңа таныш түгел яшь бер хатынны күргәч, бар алганым җитәр, дигән уй белән шунда ук кире ишеккә борылды.

— Апа, сезгә ни дә булса кирәк иде мәллә? — дип сорады сатучы.

— Юк, акыллым, миңа бу авылның һавасы да җитә, — диде Җанбикә, аны сәерсендереп. — Бик ераклардан шуны сулар өчен кайттым. Син менә кемнең кызы буласың? Төсмерләгән дә кебек үзеңне, чат кына әйтеп бирә алмыйм.

— Тәкәрлек Шәйдәүләтенең төпчеге мин. Рәхилә. Ә Сез кемнәргә кайтасыз?

Һавасы булса да, сулый алмыйсың икән. Җанбикә муенын буып торган изү сәдәфләрен чишеп җибәрде. Дәшмәде. Ни дип әйтергә түгел, ни уйларга да белми иде. Бераздан бу авыр тынлыкны бозып:

— Кемгә булса да, аермасы юк, — дип әйтеп куйды. Сәеррәк кенә башланган сүзне шушы урында өзәргә дә була иде, алай эшләмәде:

— Бәбкәм, кызларны эти кешегә тарта, диләр дә… син менә әниеңә охшагансың, — дип өстәде. — Ул да яшь чагында төскә-биткә бик матур иде. Син дә андай тере булсаң…

— Усал, кызу… — тагын шуның ише әллә ниләр әйтергә дә булыр иде, Җанбикәнең үзенә ачык йөз күрсәткән кызның хәтерен калдырасы килмәде. Шәйдәүләт белән көн итсәң, усалланмый нишләрсең дип уйлады.

— Алайса, апа, безгә генә барыгыз. Ерактан кайтканмы, килгәнме кешегә охшагансыз. Әти-әнине дә беләсез икән. Без алардан аерым яшибез. Турыбызга кадәр моннан ун өй чамасы гына үтәсе. Үзем кибетне ябып китә алмыйм. Җәйләрен ялсыз эшлибез. Иремнең кыр ыстанынннан төшке ашка кайткан вакыты булырга тиеш.

— Юк, бер уйламаган-нитмәгән кешегә чемодан күтәреп бару килешеп бетмәс, мин башта туган нигезне, туган-тумачаны барлыйм әле, — дип каршы төште аңа Җанбикә.

— Булмаганны! Сез нәрсә?! Минем ирем — бик тә ачык күңелле кеше. Танышына да, таныш түгел кунакка да бер дә авырсынмый. Бала чагында сүз биргән: бу авырлыкларны узып исән калсам, соңгы ризыгыма кадәр бүлешермен, дигән. Сугыштан әйләнеп кайткач, яшәүнең кадерен белә. Аның сүзе гел шул: әле дә ярый авылның ачлыгыннан Себергә сөрелеп, төрмәгә утырып котылдым, ди.

Кайда яхшырак булганлыгын инде менә хәзер, елларның иң авыры артта калды дигәч тә, тәгаен генә әйтүе кыен шул… Себер ачлыкларын, Себер михнәтләрен Җанбикә белмиме соң?! Авылда калганнарга аннан да авыррак булды микәнни? Шулайдыр, шулайдыр… Үзенең дә монда калган гаиләсе тулысы белән еллар хәсрәтеннән искергән зират коймасы эчендә ята…

Каядыр, кемгәдер, бер-бер чыбык очынамы, үзенең ягылмаган йортынамы, әнисе каралтысынамы — барыбер кайтырга кирәк иде.

— Моннан ун йортлап кына узасы, дисез. Сез әллә соң Сәйфи Уразмәтенең малаена чыктыгызмы? Алар да,

мескеннәр, Себергә сөрелгән иде… Әллә Мортый Галимҗанынықынамы? Юктыр, аның улы Себергә киткәндә шактый олы — өйләнер яшьтә булгандыр инде. Алай дисәң, алары арырак, бездән ераграк яши иде…

— Юк-юк, мин аларның берсен дә белмим. Ирем дип мактанганым — Солтанморат малае. Ходайбирди Солтанморатыныкы. Өлкәнрәкләр Аюныкылар, дип тә аташтыргалый. Тумышыгыз бу авылдан булса, ишеткәнегез бардыр. Хуҗиәхмәт хатыны булам!

Җанбикәнең әтисе йортыннан куып чыгарганда да сыкрамаган йөрәгенә нәрсәдер булды. Әллә таш белән бәрделәр, әллә энә белән кададылар. Инде чемоданын күтәреп, кыз янына ук килгән иде. Әйберләренең ычкынып аягына килеп төшкәнен дә сизмәде.

— Кызым, су… — диде ул, һаман да изүен ныграк ача-ача. Сулыйм, дисәң дә, һавасы җитми икән…

Рәхилә Җанбикәнең болай әлсерәвен төш турысының әсселегеннән күрде. Әллә ничә көн болытның әсәре дә күренми. Болындагы үләннәр вакытыннан алда саргаерга тора. Бакчасында да иртә су сибәсең, кич… Алай да ни кыярын ашамыйлар әле, ни башкасын. Графинага әлерәк кенә алып кергән кое суын тутырган иде. Артык җылынырга да өлгермәгән, токкан кулга бераз салкынчалыгы сизелеп үк тора. Рәхилә кырлы стаканнарга салкынча су салды да берсен кунак хатынга сузды, икенчесен шунда ук соңгы тамчысына кадәр үзе эчеп куйды.

— Әллә, аннан гына сүз булмас, төшлектә барыбер кеше кибеткә йөрми — озатып кына куйыйм мәллә, апа?

— Озатып куярга да туры килмәгәе шул, кызым. Син минем киленем булып чыкмагаең… Ходайбирде Солтанморатының хатыны Җанбикә булам мин. Ирең Хуҗиәхмәтнең әнкәсе…

— Соң… Ни… Әйдәле… Тизрәк кайтыйк… Соң… Ни… Хуҗиәхмәт шаккатыр инде… Шаккатып кына калса… — диде кибетче хатын, тотлыга-тотлыга.

Рәхилә, тиз генә озатып куйыйм дисә дә, бик озак кибет ишеген бикли алмый газапланды, бикләгәч, әле генә текелдәп торган булса да, сөйләшергә сүз тапмады. Җанбикә дә бу көтелмәгән очрашудан югалып калган иде.

— Кичә Хуҗиәхмәт белән капка төбенә чыгып утырган идек. Йолдызлар бүген төсен җуйган, иртәгә нидер булмагае, дип көлгән иде. Юраганы юш килде, — диде Рәхилә урам буйлап атлаганда. — Алай да яхшыга килде, әнкәй!

Җанбикәне Рәхиләнең «әнкәй» дигән сүзе тагын бер кат дертләтеп җибәрде. Бу аңа үз гомеренең яңа юллардан китүе шикелле тоелды. Рәхәт тә, шомлы да, борчый да торган билгесезлек иде ананың йөрәгендә. Кара син аны, йолдызлар төсен җуйган, дигән була икән. Әтисе Солтанморат та вакыт-вакыт әллә йолдызлар төстән язган, әллә мин акылдан язганмын, дип уфтанып куя торган иде.

Шулай… Ни юрасаң да, яхшыга юрарга кирәк. Исәнлеккә-иминлеккә юрарга кирәк. Ул турыда уйлап җиткереп булмый. Ир-ат ул хакта уйламый да уйламый инде. Бар нәрсәгә дә игътибарлы, вакланучан җан түгел бит ул. Әле менә Хуҗиәхмәте… Әнкәсен, үзен Себер төрмәләрендә, сазлыкларында череткән берәүнең кызын хатынлыкка алган, ире-каенатасы көч түгеп төзегән йортына кертеп утырткан.

Яраткандыр инде Хуҗиәхмәт, яраткандыр… Яратсаң, күзеңә бернәрсә дә чалынмый бит ул. Солтанморатның ничәнче күрүе булгандыр, ата-анасының да кемлеген белешмәстән, сиңа гына өйләнәм, дип әйтте дә салды. Шәйдәүләтнең күзе дә ерткычлар-

ча яратудан томаланган иде. Боларның яратуы инде башкача булсачы...

Әйе, Солтанморатны да, Җанбикәне дә яратканнар бар иде. Сез соң безне яратасызмы, дип тә сорап тормадылар, зыян арты зыянны эшләүләрендә булдылар. Андый яратуны Җанбикә аңлый алмый. Хәер, ул врату нәрсә була дип уйлый башлаганда, Солтанморатларның сары бүрәнәләрдән салынган йортында, шуның да яшь парга дип эшләнгән бүлмәсендә, Солтанморат кочагында утыра иде инде. Сабый гына булган бит югыйсә, сабый гына...

Җанбикә үзенең киленлек еллары узган өйнең һәр бүрәнәсенә кадәр хәтерли иде. Улы Хуҗиәхмәт калын тышлагыч такталар белән әйләндереп чыккан икән. Тәрәзә өлгеләрен дә яңага, бизәклегә алмаштырган. Һәр тәрәз өстендә кып-кызыл булып йолдыз янып утыра. Элек өлгеләр чуклы, яфрак бизәкле була иде. Малае әнә шакмаклардан, йолдызлардан ясаган. Очлы башлыгына кызыл йолдыз төшерелгән Шәйдәүләтне хәтерләтә икән лә җирлеге ачык яшел бу өлгеләр... Ул инде аны салгандыр, картларча, төсе киткән малахай бүрек киеп йөри торгандыр...

Әллә Хуҗиәхмәтнең дә кулы әтисенеке кебек балта эшенә оста инде?! Капка төбенә җыйнак кына утыргычлар ясап куйган. Өй каршысындагы коймаларны да бөтенләй үзгәртеп корган икән. Кара син аны әй, аларында да адым саен бер йолдыз... Яңа гына буялганнар, төсләрен җуймаганнар әле, дип көлемсерәгәндәй итте Җанбикә.

Капка төбенә җиткәч, Җанбикә бик озак тукталып торды. Күзәтте. Өлгеләре тартылган тәрәзәләрдән кемнедер эзләгәндәй итте. Килененең әйдәкиләвенә дә, ашыктыруына да карамады, нәрсәдер әйтергә теләгәне һаман уйда икәнлеге күренеп тора иде.

Себерләрдә тилмергән вакытларда яшәгән нигезенә кайтып керү шулкадәр авыр булыр дип башына да китермәгән иде Җанбикә. Торган нигезенә соңгы сулышын алырга кайткан бер адәм шикелле, тирән-тирән итеп сулады, уфтанды, аһлады, тагын-тагын изүләрен тарткалаган булды, тик һаман капкага таба атлый алмады. Аннан әкрен генә:

— Кызым, мин үз нигеземә таба атлый торыймчы. Хуҗиәхмәткә әйт. Әнкәң кайтты, диген. Башта тынычлап ашасын. Аннан төшеп хәлемне белер. Ул — яшь кеше. Мин авылның теге башына чыкканчы, куып та җитәр әле, — диде. — Берочтан белеш: ачкыч кемдә микән, анда булса, алырга онытмасын.

Рәхилә каршы төшмәде. Бу көтелмәгән очрашудан ул үзе дә югалыбрак калган иде. Хатын әнкәсенең, иренең кем аркасында төрмәләрдә утырганын, лагерьда бил бөккәнен белмиме соң, белә, тик Хуҗиәхмәтен яраткач, исән була һәм табыла калса, әнкә кеше кайчан да бер киленен кабул итәр, нәселенә үпкәсен дә онытыр дип өметләнә иде.

Җанбикә үз өендә тукталмыйча, туган йортында яшәргә уйлап ялгышмады булса кирәк. Әле менә урам буйлап узганда, үзгәрешләрне дә күреп, очраган бала-чагасы белән исәнләшеп, танымаган өлкәннәренә дә сәламен биреп бара.

Авылны алай да танып булырлык. Җанбикәнең яшь чагыннан калган йортлар әле җитәрлек. Егерме биш ел узган димәссең. Ачлыгы, сугышы, ирләрнең кырылуы авыл тормышын яхшыртырга бирмәгән, ахрысы, дип уйлады ул. Алай да үзгәрешләр бар. Югары оч башындарак зур бер бина калкып утыра. Мәктәпкә охшаган. Янындагысы, түбәсенә флаг кадаганы, я авыл советыдыр, я колхоз идарәседер инде. Кибеттән кала бар нәрсәне бер тирәгәрәк җыйганга охшыйлар.

Галиәхмәтләр турына җитәрәк,

Җанбикәнең йөрәге тагын дертләп китте. Аюныкылар дигәннән, каенатасы Хәмидулла әйтә торган иде, алар белән без бер тамырдан, ә менә бу авылга төпләнгән башка нәселләр белән бер тамырдан түгел дип. Аю кушаматлы бер көчле башкорт кавеме булган да, ишәеп, бик күп авылларга таралган, Кызыл Аланга да килеп җиткәннәре булган, имеш.

Кем белә, әткәсе, бәлки, хаклыдыр да. Әнә бит, Галиәхмәт тә Аюныкылардан кыз алды, әмма алар кебек батыр, сүзен сүз итүчән булып китә алмады. Бирнә байлыгы килсә дә, үзеңнеке булып китсә дә, кушамат хатын белән ияреп йөрми шул. Ә менә ире Солтанморат Аю дисәң дә Аю булган! Аның көче кулыннан түгел, күзеннән ташып тора иде.

Җанбикә сәвиткә, кәмитет эшенә бирелгән Галиәхмәтнең дә инде дөньяда юклыгын капланган тәрәзә яңакларын күргәч кенә чамалады. Улы Хуҗиәхмәттән сорарга кирәк булыр әле дип уйлады. Комитетка кердем дип, халыкка зыянлыга әйләнмәсә дә, баена-кулагына артык зыянсыз булса да, ул да юк икән. Нишләп диген? Якты дөньялардан үз үлеме белән генә киткән булсачы. Яшьләр иде бит әле алар да, яшьләр…

Ире Солтанморат яшиме-юкмы, моннан хәбәрсез иде Җанбикә. Исән булса, Себер сазлыкларыннан да эзләп табар кебек иде ул! Ул юктыр инде, юктыр… Артык яхшы кеше иде шул. Андыйлар бакыйга да бик кирәк, диләр бит.

Солтанморат юк, Солтанморат юк! Аның төсен, әнкәсенең төсен саклар-лык гүзәл Гөлхәбирәсе дә юк… Ә менә имансыз Шәйдәүләт тә, нәселе дә яши! Алай дисәң, ул инде аның нәселе белән бергә тамырланып яши була түгелме?! Карале син аны, оныкларым бармы, дип сорарга да өлгермәде. Сорар әле, сорар, кыз булса, әнкәм-балам кебек чибәрме, дип сорар. Тьфу! Тагын да шул чибәрлек! Башы исән-имин булсын, дип теләр.

Гомер бакый юньле бер сүз белән искә алмаган Шәйдәүләт оныкларының бабасы була түгелме соң?! Инде аңа да алар хакына исәнлек-иминлек теләргәме?! Нишләп алар хакына гына булсын?! Улы Хуҗиәхмәт хакына да! Әнә бит, сөйләр сүзең юк: кан дошманының кызы белән яшәп ята. Исән калсам, гел яхшылык эшләрмен, дигән икән, бәгырь. Диярсең, дими ни! Ачлык-ялангачлык тотканда, күзгә ак-кара күренми ул. Дөньяның бөтен йолдызлары төстән язган кебек тоела.

Инде дә хәзер үч саклаудан кемгә зыян да кемгә файда? Яшисе яшәлгән, ашыйсы ашалган… Язмыш такталарында шулай язгандыр, ахрысы. Әнкәләре, кызы Гөлхәбирә Себергә дә сөрелмәгәннәр иде югыйсә, барыбер бу дөньяда юклар. Бәлки, казна икмәген ашап кына исән калгандыр әле ул Җанбикә!

Такталары каралып, баганалары тераүгә терәлеп куелса да, зур капка бикләнмәгән булып чыкты. Алай да каралтыда кеше-мазар бик йөрми булса кирәк. Җанбикә ачып керде дә билдән үлән арасында торып калды. Алдан — юлда чакта ук, дога-мазар укысам дип, тәһарәтен алып куйган иде. Көч-хәл белән биек үләннәрне бастыра-бастыра, баскычкача узды да, башына яулыгын бәйләп алгач, йорт нигезенә утырып дога кылды. Аннан үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтә куйды:

— Инде исән-имин генә шушында яшәргә язсын. Нәзер үк итеп әйтмим, булдыра алсам, әткә-әнкәләремне, иремне, баламны гына түгел, дошманнарымны да догамнан калдырмам. Исәннәренә, Себер җибәреп, исән калдырганнары өчен, гомернең озынын теләрмен. Һичьюгы, мин чынлап торып кичерә алганчы яшәрлек гомер.

2012 ел

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай,
«Уянгач беренче эшем»,
1913 ел, 14 март

МИГЪРАЖ (1911), шигырь, Тукайның фәлсәфи яңгырашлы, тирән эчтәлекле дини әсәре. Исеменә үк чыгарылган «Мигъраҗ» сүзе «күккә ашу» һәм «баскыч» дигән мәгънәләрне аңлата. Шигырьдә бүгенге көндә дә мөселман дөньясында рәҗәп аеның 27 нче көнендә олуг бәйрәм рәвешендә билгеләнеп үтелә торган могҗиз бер рухи күренеш — Мөхәммәд пәйгамбәрнең Пырак (Бурак) исемле кеше кыяфәтле, канатлы оҗмах атына атланып, Мәккә шәһәренең әл-Хәрам мәчетеннән Коддес шәһәрендәге (Иерусалимдагы) әл-Әкъса мәчетенә сәфәр (исра) кылуы һәм аның бусагасы, капкасы төбеннән, ә икенче берәүләр фикере буенча, Ибраһим пәйгамбәрнең кайчандыр улы Исмәгыйльне корбан кылырга җыенган текә кыя түбәсеннән яктылык баскычлары аша җиде кат күкләргә ашуы (мигъраҗ кылуы), анда Аллаһы Тәгалә белән очрашып, Аңа сәҗдә кылып, җемелдәп торган нур кисәкләрен хәтерләткән сүзләр ярдәмендә әңгәмәдәш булып, олуг рухи кыйммәтләр белән әле суынып та өлгермәгән ятагына Мәккәгә әйләнеп кайтуы турында бәян ителә. Пәйгамбәребезнең «Мөхәммәд» дигән исеме дә «күккә ашучы» дигән мәгънәне аңлата.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең күккә ашуы турындагы мигъраҗнамәләр урта гасыр гарәп-фарсы-төрки әдәбиятларында бик күп очрый. Күпчелек галим-голәмә аларның мәйданга чыгуына Коръәннең Бәни Исраил кавеме турындагы 17 нче сүрәсе этәргеч ясаган дип фаразлый. Икенче төрле аны «Исра» — әл-Хәрам мәчетеннән әл-Әкъса мәчетенә төнге сәфәр сүрәсе дип йөртәләр. Бу озын сүрәнең (12 нче бүлек, 111 нче аять) беренче аятендә генә Аллаһ исеменнән «Мөхәммәд пәйгамбәрне кодрәтебез белән йөреттек, гаҗәеп галәмәтләребезне күрсәттек», диелә. Сүрәдә борынгы заманнарда югары үсеш баскычына күтәрелгән, дәүләтле халык яһүдиләрнең масаеп китүләре, Илаһиятнең гадел хөкемнәрен онытулары, шуның өчен зур афәтләргә дучар ителүләре: изге Иерусалимның башта вавилонлылар, соңрак римлеләр тарафыннан җимерелүе турында сөйләнә. Аллаһның бу җәзасы әле яңа гына тарих мәйданына чыккан ислам дине һәм мөселманнар өчен дә зур сабак икәнлеге ассызыклана. Бәни Исраил — Ягъкуб пәйгамбәр балаларының бу фаҗигале язмышы турында байтак әдәби әсәрләр һәм хезмәтләр язылган, мигъраҗ сюжеты белән үрелеп, италияле Данте Алигъеринең (1265-1321) «Илаһи комедия»сендә дә чагылыш тапкан һәм аңа күп кенә иллюстрацияләр ясалган. Мигъраҗнамәләр эчтәлеген гәүдәләндергән миниатюралар Шәрекъ һәм Гареб рәсем сәнгатендә дә байтак урын алган. Мәсәлән, уйгыр телендәге мигъраҗнамәгә алтмышлап миниатюра багышланганлыгы билгеле. Мөхәммәд пәйгамбәрнең гарешләргә күтәрелеп, Аллаһ, фәрештәләр, пәйгамбәрләр белән очрашып, намаз укып һәм күп кенә рухи байлыкларны үзләштереп җиргә кайтуы гарәп, фарсы, төрек һәм татар телләрендәге байтак мигъраҗнамәләрдә яктыртылган. Бу хакта Әхмәт Ясәви хикмәтләре,

«Алты бармак», «Мөхәммәдия», «Әнвәрел-гашыйкыйн» әсәрләре дә тәфсилле итеп сөйли-көйли. Мигъраҗ темасы татар мөнәҗәтләрендә аеруча уңдырышлы туфрак таба. Мөхәммәд пәйгамбәрнең күкләргә сәфәре XIV гасыр төрек әдәбиятында үзәк бер мотив һәм концепт рәвешен ала. Шәрекъ Ренессанс әдәбиятында да мигъраҗ мотивына зур урын бирелә. Мәсәлән, Низами Гянҗәвинең (1141-1209) «Бишлеге»ндәге («Пятерица») һәр поэмада мигъраҗ турында махсус бүлекләр урнаштырылган. Пәйгамбәрнең җиде кат күкләргә Аллаһы Тәгалә янына сәфәре турында мөселман мәдәниятенең атаклы галимнәре Бохари хәдисләрендә дә, Ибн Хишамның «Сират ән-нәби»ендә дә җитәрлек мәгълүмат бар.

Мигъраҗ турындагы Коръән сүрәләре (17 нче һәм 53 нче), дини-фәлсәфи чыганаклар, мифологик материаллар, фольклор һәм әдәби әсәрләр белән Тукай да яхшы таныш булган. Әмма ул үзенең «Мигъраҗ»ын, Г.Ибраһимовның әйтүенә караганда, азәрбайҗан Ренессанс әдәбиятының күренекле вәкиле Мөхәммәд Фөзулинең (1494-1556) шул исемдәге шигыренә нәзыйрә рәвешендә иҗат иткән. Шигырьнең тирән дини-мистик фәлсәфи эчтәлеге, сәнгатьчә бик югары эшләнеше, ислам теологиясе, эстетикасы, этикасы өчен хас символик образ-сүрәтләр, хронотоп, ягъни урын-җир гәүдәләнеше (ля мякән, көн фәякүн; замана-зәмин; сүрәт-мәгънә, заһир-батыйн кебек төшенчәләр) Фөзули белән Тукай арасында әңгәмәдәшлекнең (интертекстуальлекнең) тыгыз булуы турында сөйли. Фәлсәфи-эстетик фикерләүдәге бу уртаклык иң элек яктылык сүрәтләренең мул бирелешендә күзәтелә. Җәбраил фәрештә аша Хак Тәгаләдән хәбәр килгәндә, Мәккә шәһәре (топос) күкләрдән иңгән нур белән тоташа. Чөнки Коръәндә яктылык образы Аллаһ символы (А.Е.Бертельс) итеп сүрәтләнә. Изге Китапның 24 нче сүрәсе 35 нче аятендә әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә — «күкләр вә җирләрнең нуры» («Аллаһ-әс-сәмавәти вә-л-арди»). Аның тәхете дә нурлардан үрелгән. Барлык тәфсирләрдә «Аллаһ теләгән кешесен үз яктылыгына алып килә», диелә. Мөхәммәд пәйгамбәр дә — икеләтә нур иясе: дөньяга килгәнче үк аның җаны якты йолдыз кебек күкләрдәге шәмдәлдән яктылык бөркеп торган, ә беркадәр соңрак аңа илаһият нуры да иңгән. Фөзули шигыренә Тукай язган нәзыйрәдә дә бары тик нурлардан гына үрелгән Җәбраил һәм меңләгән мәляикләр образы бар. Шуңа күрә «Мигъраҗ» шигыренең нур сүрәтләренә корылган «*Ярты төн булган чагында китте Мәккә яктырып, / Нур тоташты җиргә күктән, иңде нурдан бер Пырак*», дигән бәйт белән ачылып китүе бер дә гаҗәп түгел. Оҗмах атының Пырак — Бурак дигән исеме дә дөрләп кабынган ут — яктылыкны белдерә. Кыскасы, шигырьдә урта гасыр мөселман әдәбиятлары өчен хас нур эстетикасының йогынтысы бик тә көчле.

Шигырьдә ислам дине мифологиясе, мигъраҗнамәләр өчен хас булган хронотоп бирелеше, Коръәндәге образ-сүрәтләр, төшенчәләр — барысы да сакланган. Мәккә — Коддес мәчетләре, күк катламнары аша үтеп, Мөхәммәд пәйгамбәр белән бергә Аллаһы Тәгалә хозурына Изге китап та күтәрелә: «*Дөньяда һәр нәрсә дә үз асылына бер әйләнә. / Ашты кодрәтлә сәмавәткә бу кич Коръән янә*». Бу шигъри юл белән фәлсәфә фәне өчен бик әһәмиятле булган бер канун: галәмдәге, җәмгыятьтәге, рухи яшәештәге күренешләрнең «кабат әйләнеп кайта алу» кануны (вечное возвращение) турындагы фикер ассызыклана. «Мигъраҗ» шигыренең 6-7 нче бәйтләрендә сүрәтләнгән кайнап торган Берлек — «вәхдәт диңгезе»,

юкка чыккан җир (зәмин) һәм вакыт-замана образлары (зур шартлау теориясе) мисалында урта гасыр гарәп-мөселман неоплатонизмы өчен хас бик тә үзенчәлекле хронотоп, онтологик һәм гносеологик карашлар чагылыш тапкан: «*Бәхре вәхдәт» асты өскә килде шунда, кайнады, / Бетте, мәхү улды зәмин, һәм дә замана калмады*». Тән кабыгын салып, Аллаһның гаршекөрсиләренә яктылык нуры булып очып менүче Мөхәммәд пәйгамбәр образы неоплатонизм эстетикасындагыча мәгънәви символны аңлатучы семиотик билгегә әверелә. Шуңа күрә куркыныч утлы тәмугны хәтерләткән вакыт агышы да әллә нишләгән шартлау-җимерелүләр белән тулы хаос упкынында Рәсүл дә җирдәге төс-кыяфәтен, бәдәнен, сурәтен югалта, рухилык белән тулган нурлы мәгънәви җанга әверелә, Илаһият белән очраша, аны сәламли, меңләгән фәрештәләр һәм пәйгамбәрләр белән бергәләп Аңа сәҗдә кыла. Бу хакта шигырьдә: «*Калмады сүрәт, бары тәбдил ителде мәгънәгә, / Әүрелеп мәгънәгә, дөнья сәҗдә кылды Мәүләгә*». Шигырьнең азагында «заһир — батыйн» (мәгълүм булган — яшертен) антиномиясе рәвешендә Аллаһның барлыгын, Берлеген танымаган «мөнкирләр» белән бәхәстартышлар да искә алына; Олуг Кодрәт иясенә сыгыну, буйсыну, гыйбадәт кылу кирәклеге, намаз укуның фарыз икәнлеге турында фикерләр әйтелә.

Күкләргә иңгәч тә, Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһның йөзен күргәнме, әллә юкмы — бу хакта ислам дөньясында бүгенге көнгә кадәр бәхәсләр бара. Мөселманнарның күпчелеге бу хәл булмаган, диләр. «Мигъраҗ» шигыре авторы Мөхәммәд Фөзули дә, аңа нәзыйрә язган Габдулла Тукай да Пәйгамбәрнең Бөек Кодрәт иясе белән очрашуын әллә өндә, әллә төштә булып үткән хыялый бер күзаллау, яшертен (батыйл) эчтәлекле бер риваять сыман тәкъдим итәләр: «*Нә саташмак, нә гөман бу, нә хыял, нә төш иде, — / Бер илаһи вакыйга, могъҗиз вә серле эш иде*».

Гомумән алганда, Мөхәммәд пәйгамбәрнең «Ләйләтел-мигъраҗ» кичәсендә, төштә генә булса да, гаршекөрсиләргә күтәрелеп, Аллаһы Тәгалә белән җемелдәгән нур ярдәмендә әңгәмәдәш булу бәхетенә ирешүе олуг бер мәгънәви могҗиза — киләчәктә Рәсүлебезнең илаһи һәм рухи бөеклек баскычларына күтәреләчәге турында алдан хәбәр бирү, вәхи җиткерү иде. Америка язучысы һәм галиме Майкл Хартның «Йөз бөек кеше» китабында (1998) кешелек җәмгыятендәге иң олуг шәхесләрнең берсе һәм беренчесе итеп Мөхәммәд пәйгамбәр исеме аталуы гаделлек һәм зарури бәя булды.

Шигырь аа бб вв рәвешендә рифмалашкан, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы 12 бәйттән тора; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кульязмасы сакланмаган. Беренче мәртәбә «Йолдыз» газетасында (1910 ел, 13 апрель; «Г.Тукаев» имзасы белән), аннары «Шура» журналында (1910 ел, 9 нчы сан), «Күңел җимешләре»ндә (1911) басылган.

Чыганак

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. — 2 том. — 2011. — Б.116-117; Мөхәммәд пәйгамбәр турында хикәяләр. — Казан, 1997. — Б.12.

Әдәбият

Шукуров Шариф. Об изображениях Мухаммада и проблеме сокрытия лица в средневековой культуре ислама / Суфизм в контексте мусульманской культуры. — М., 1989. — С.252-267; Пиотровский М.Б. Аль-Асра ва-л Мирадж / Ислам. Энциклопедический словарь. — М., 1991. — С.115; Бертельс А.Е. Художественный образ в искусстве Ирана IX-XV вв. — М., 1998. — С.238-289; Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре. — Казан, 1998. — Б.223-224; Салихҗан Харис. Рәсүлебезнең мигъраҗ кичәсе // Ватаным Татарстан. — 1995. — 19 декабрь; аныкы ук: А.Пушкин һәм Г.Тукай иҗатында Коръән аһәңнәре. — Казан, 2001. — Б.22.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе
Җитсен иде һәрбер күңелгә…

Хәсән Туфан

ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР*

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,
филология фәннәре кандидатлары

Бәс, ни килсә башка,
бел: телдин килер,
Адәмичә нә ки кыйлса, тел кыйлыр.

***

Кеше ялган сүз берлә тапмас нәҗат[1],
Тугры сүз берлә табар даим хәят[2].

***

Телдән нәрсә чыкса, ул башка килер.

Мөхәммәдъяр

Сүз ул — гәүһәр,
аның кадерен белсәң,
Таләп белән бу сүздә фикер йөртсәң.

***

Бу дөньяда сүзем калыр, үзем — юк.

Мәҗлиси

Тидермә һичберәүгә син ачы тел,
Әгәр дә ул тидерсә, син бары көл.

***

Мәгънә диңгезенә чумып,
төбенә төшсәң,
Фикер итеп, сүзнең асыл
мәгънәсенә җитсәң,
Белерсең: китапның мәгънәсе
бик яхшы,
Шигырен әйбәт сыйфатлы дип
тапмасаң да.

Габдерәхим Утыз Имәни

Берәү чит бер телне өйрәнәсе булса, башта үз телен яхшы белсен.

[1]Нәҗат — котылу.
[2]Хәят — тереклек.

***

Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр.

Каюм Насыйри

Хөрмәтсез кешеләрнең сүзләре яман санала, олуг кешеләрнең ялган сүзләре сәясәт санала.

***

Әйткән сүз, үткән гомер — агып киткән су мисалында.

***

Озын сүзләрдә кыска гына бер максат була.

***

Пыяла савытларның сәламәт булыпбулмавы тавышларыннан беленгән кебек, адәм балаларының һөнәрләре дә сүзләреннән беленер.

***

Күп фикерлә, аз сөйлә.

***

Сүзләрнең кыйммәтлесе — заман үтү белән онытылмый торганы.

Ризаэддин Фәхреддин

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү — яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак — наданлыктан әсәрдер.

***

Динең өчен телең булсын тозаклы,
Йөз аклыгың өчен — аузың йозаклы!

Дәрдемәнд

Сүз көчле ул, мәгънәле ул,
сирәк булса,
Тыңлаучысы да сүз аңлаучысы
зирәк булса.
Сәгыйть Рәмиев

И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
син туган тел аркылы.

***

Якын дустым! Сиңа миннән
киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.
Габдулла Тукай

Тәмле тел — халык җаны...

***

Үз ана телем — минем өчен матур,
иң тәмле тел,
Үз телем — үз әйберем булган өчен
ярата күңел.

***

Вакты белән чәчкәгә су сипмәсәң —
бетәр кибеп,
Тел дә шулай үстерүгә мохтаҗ ул,
сулар сибеп.

***

Телләре югалмадисә,
мәңге югалмас татар;
Милләт ашдыкча — ашар,
милләт яшьдекчә — яшәр...
Мәҗит Гафури

Асыл ташлар ята суның төбендә,
Асыл сүзләр ята күңел төбендә.
Әкрам Галимов

«Фәлсәфә сатма» дигән сүз фәлсәфә түгелмени?
Шәехзадә Бабич

Сүз юк —
Урыс телен белү кирәк нәрсә,
Ләкин
Кирәклеген аның бутыйлар,
Татарларга татар була торып,
Урысчадан доклад укыйлар.
Һади Такташ

И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.
Хәсән Туфан

Тел — халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын, мең еллар буена үзенә сеңдерә килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә.
Гомәр Бәширов

Гайбәтне, гадәттә, үзләре бозык кешеләр үзләреннән яхшырак кешеләр турында уйлап чыгарырга яраталар. Шуның белән алар, бер яктан, үзләреннән яхшырак кешеләрдән үч алалар, икенче яктан, үзләре гайбәттән читтә калалар.
Әхмәт Фәйзи

Тел кешене дус итә,
Бер-беренә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!
Шәйхи Маннур

Телнең иясе — халык, хуҗасы — дәүләт.
Габдрахман Әпсәләмов

Уе юкның — теле юк,
Теле юкның — иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк.
Нури Арсланов ■

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ГУМАНИТАР-ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ

МИЛЛИ ИДЕЯ

Уяныр да бәлки нәсел хисе,
Сискәнеп бер, уйга калырсың.

Һәсән Туфан

ТАТАР ТЕЛЕ – ГОМУМХАЛЫК ТЕЛЕ

ФӘРИТ ЯХИН,
филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры

Хөрмәтле укучыларыбыз! «Чын мирас» журналында өр-яңа сәхифәгә фатиха бирелде. Алдагы саннарыбызның берсендә (№7) Искәндәр Гыйләҗевнең «Татар теле язмышы турында кайбер уйланулар» мәкаләсе дөнья күргәннән соң, редакциябезгә бу мәсьәләгә караган төрле язмалар килә башлады. «Милли идея» сәхифәсенә бүген тәкъдим ителгән мәкалә дә шундыйлардан.

Редакция

I

Казан шәһәрендә татар әдәби теле хәтта иң авыр, тел сәясәтендә катлаулы елларда да аксөякләрдә камил дәрәҗәдә кулланылышта һәм яшәештә булды. Моның хыялый фараз түгел, бәлки хактан да шулай икәнлеген ачык аңлау-аңлату өчен йөзләрчә вакыйгаларны искә алып сөйләп китәргә мөмкин. Әмма берсенә генә тукталып узам.

Бервакыт шулай, университетта укыган студент елларым иде, күптән танышып, хисләребезнең уртак булуында шикләребез калмаган хәлдә, сайлаган ярымның әти-әнисе белән танышу өчен өйләренә бардым. Аларның иске заманнардан татар милләтенең бәрәкәт туфрагы тәрбиясендә яшәгән кешеләреннән икәнлеген әлегә белми идем. Хәер, ул танышу-очрашудан соң да нәсел-нәсәпләреннән хәбәрдарлыгым берничә ел дәвамында артмады. Алар: «Без – шулар, тарих ниргәләрендә милләтебезнең мәгърур йортын төзегән шанлы бабаларыбызның балаларыбыз», – дип бер генә булса да мактанып сүз кузгатмадылар. Болары тормыш барышында белешкәнемдә, китаплардан очраган исемнәр белән бәйле сорауларыма җаваплар тапканымда гына мәгълүм булды.

Өйләренә кереп, исәнләшеп, инде танышу һәм аралашу ишекләре миңа киң ачылгач, гаилә атасы Тарикъ Шәех улы әйтә куйды:

– Без өйдә урам телендә сөйләшми идек!

Тәрбиясезлегемне сиздерүдән йөземә оят кызыллыгы йөгерми калмады. Ул узган гасырның сиксәненче еллары башында Казанда «урам теле», «урам тәрбиясе» дигән гыйбарәләргә киң вә тирән мәгънәләр салынып, аларга бәйле кисәтүләрне, матбугатта булмасын, халык телендә булмасын, университет профессурасы телендә булмасын, еш искәртә иделәр. Бу сүзләр кешенең холыкта һәм әдәптә үзен иркен хис итүен тарлауга этәрәдер сыман да иде. Мин ул «урам теле» дигәннәрендә, әлбәттә, «русчаны тоюым чамалыдыр» дигән фикергә килдем. Заманасы шундый иде аның: һәммә җирдә, урында, хәтта дөньяда бары тик рус теле генә тел, русча сөйләшү генә сөйләшү, русча белем генә белем һәм тагын да әллә ни-күпме русча-русчалыклар өстен куела иде. Бәлки ялгышамдыр? Аннары, кайдадыр ерактагы сала бәрәңгесен ашап үскән, икмәккә туймас колхозлы татар авылы баласы, инде егет кеше, Казан аксөякләрен күргән-белгәнмени? «Урам теле»ндә сөйләшүемне дәвам итеп, сүзләр бәйләнешендәге «падеж» вә «окончание»ләргә аерата зур игътибар салып, сорауларга мөмкин кадәр аң белән җавап бирәм. Тырышлыгым, әлбәттә, кызларын да, үземне дә оятлы итмәү теләге белән сугарылган. Әмма тагын да шул ук сүз кабатлана, гади, гадәти, шелтәсез:

– Без өйдә «урам теле»ндә сөйләшми идек!

Бу аристократик кисәтү инде аңыма барып җитми калмады, йөрәк бөтенләй дә башка яктан, тамырыннан киселеп куйгандай булды. Күрше як бүлмәдә тыныч кына, әмма ягымлы һәм рәхәт итеп Татар радиосы сөйли. Һәм мин:

– Гафу итегез! – дип үтендем. – Аңламый торам…

Бу йортта шушы сүзләр минем тарафтан беренче тапкыр әйтелгән татарча сүзләр булдылар һәм алар Ходайның хикмәти тәэсире илә хуҗалар тарафыннан кабул ителделәр. Күңелем суынганчыга кадәр баштарак үземне телсез калгандай тойдым, аннары сәер уңайсызлыклар онытылды. Ул йортта моннан соң һәрдаим татарча гына сөйләшергә тиешлегемне төгәл белеп тордым. Дөнья йөзе дә башкача күзаллана башлады. «Урам теле», «урам тәрбиясе» дигән гыйбарәләр дә «рус теле», «рус тәрбиясе» дигән мәгънәләргә ия икәнлеген белеп һәм аңлап яшәү күземне генә түгел, күңелне дә ачып, анда якты утларын мең төрле тасвирлы төсләрдә кабызып җибәрде. Минем танышлык-танышулар киңәя торды һәм һәр татар аксөякләре гаиләләрендә шул ук бер хәл иде. Әмма, гыйбрәт өчен булгандыр, «урам тәрбиясе» коткысында калган һәм шуның белән «урам теле»нә балалары аяк баскан семьялар да юк түгел иде. Тагын да искәртергә тиешмендер, ул ныклап атлаган балаларының көннәрдән-беркөнне аяклары таеп киткәнен күреп һәм ишетеп, вакыйгалардан хәйранлык хәсрәтендә сүзсез калган көннәрне дә узарга туры килде. Бу хакта башка әдип һәм журналистларыбызның язмаларын укыганымда, аңлап җиткерми, миңа бу кагылмый дип кенә, күңел белән игътибарга алынмаган. Инде аларның хаклы булуларына, кайнарланып бәян итеп, кисәтеп язып чыгуларына ил халкы, милләт рәхмәтледер. Әмма тагын да шунысы бар: ул татар аристократиясе-аксөякләре үз балаларын башка милләт вәкиленә кияүгә бирүгә яки өйләндерүгә һичбер каршылык итмичә, ә тәрбиядә татарлыкны, татарчалыкны оныкларына тапшыра алуына сокланыргамы, әллә шелтә

белән карарга тиешменме – боларын, алдымда торган яисә калкырга мөмкин мәсьәлә буларак, ничек чишәргә тиешлегемне белмим. Казан милли аксөякләренең гаилә бәхете дигәннәре ул – ныклы, саф мәхәббәткә корылган тигез тормыш. Бу мәсьәләдә алар үтә сак була беләләр. Монда Аллаһы Тәгаләнең тәкъдир кулы уйнавына зур ышаныч белән карыйлар. Сүздә ул мәсьәләгә шушы кереп алуыбыз фикер мантыйгыннан гына түгел, тормыш чынбарлыгының үзенчәлекләрен дә искәртүдән икәнлеге аңлашыладыр?!

II

Рәсәй шартларында ябылып яшәгәндә, рус телен белү белән генә канәгать итсәң дә җитә. Ул шулай булды. Хәтта милли телнең дә кирәге бетә. Моны дөрес аңларга тиешбез. Глобаль шартларга интеграция бөтенләй башка мөмкинлекләр ача. Моңа кадәр яшәгән һәм табигый дип исәпләнелгән шартлар үзгәреше халыкта телләргә булган мөнәсәбәтне кискен рәвештә яңартып җибәрде. Элек гаилә, өй-йорт кысаларында гына булган туган телнең глобаль коммуникатив мөмкинлекләре аерым әһәмияткә ия икәнлеге ачыкланып, мәдәни үсеш шартларында, һичшиксез, туган телнең кирәклеге аңыбызга барып ирешә. Милли тел иҗтимагый функция генә түгел, бәлки дәүләти, илнең яшәве шартларының берсе сыйфатын алып, мәртәбәдә үсеш кичерә башлады. Татарстан дәүләте, аның идарәсе, өскормасы моны ачык аңлап эш итәргә мәҗбүр булды. Бездә ул ихтыяр көченең әйдәве тәэсирендә алып барылган төс алды. Аны рус теленә каршы сәяси хәрәкәт формасында кабул итүебезнең төп сәбәбе милли җәмәгатьчелегебезнең холкыннан да килә. Глобаль процесста туган телнең югалып калу мөмкинлеге дә фараз ителеп, татар җәмгыятен кабат үзенә бикләнергә, йомылырга, хәтта вакуумга кертү юлына да барырга әзер торган милли каһарманнарыбыз сүз һәм гамәлне, әлбәттә, изге максатларга юнәлтүдән шулай иде. Әгәр дә Рәсәй кабат үз эченә ябылса, дөнья белән бергә кешелекнең мәдәни үсешенә омтылмаса, иске хакыйкатьләр кабатланачак, милли телебез дә өй ишекләребез артына кереп бикләнәчәк, аксөяк-аристократлар, зыялылар теле булып калачак. Моны тоталитар яшәеш шартлары рәвешендә кабул итәргә тиешле икәнлегебез көн тәртибенә килеп басачак иде.

Әмма глобаль вазгыять бездән дөнья күләмендә коммуникатив дәрәҗәсе көннән-көнгә арта барган инглиз телен белүнең әһәмиятен алга куйды. Бүгенге татар аксөяк-аристократлары бу яктан борчылусыз яшиләр. Татарчасы, русчасы һәм инглизчәсе электән яхшы куелган бу катлам үз яшәү кыйммәтләренең тарихи үсеш шартларында кабат өстен чыгарылуына сөенми кала алмый. Болар янына алар тагын да гарәпчәне яхшы ук дәрәҗәдә чамалыйлар, иске заманнардан калган гадәт буенча фарсыча мөгамәлә кыла алалар, төрекчәне яхшы таныйлар. Телгә һәм телләрне белүгә һәр кешенең, әлбәттә, югары культуралы кешенең, ягъни зыялының, ихласы булырга тиеш дигән караш һәм күзаллау каннарына сеңгәнлек сәбәпле, табиб-медикмы, инженермы, укытучымы, башка өлкә вәкилеме, кайда гына эшләмәсеннәр, Казан милли аксөякләребез бу тәрбияләрендә мөкатдәс хис белән береккәннәр. Китапханәләрендә француз, испан, немец, инглиз, гарәп, фарсы, төрек, татар, рус китаплары алгы рәтләрне алып, алар янәшәсендә кытай-япун әсәрләре дә күренә башлау бәхәссез мәдәни затлардан икәнлекләрен танырга мәҗбүр итә. Татар язучыларының әсәрләрен күпләп укыганлыклары, һәр әдипкә карата татар рәсми тәнкыйтенә һәм әдәбиятчыларының фикерләренә бәйсез рәвештә бәяләре булу, җитмәсә электән укылып, халыкта истәлекле ядкәрләр сыйфатында саклanган-

лыгы сәбәпледер, хәтта «Тәварихы-Болгария» («Болгар тарихлары») кебек, фән вәкилләре тарафыннан Шиһабетдин Мәрҗани заманнарыннан тәнкыйть ителә килгән китапларга да теш азайтуны, сүз белән суктыруны яратмыйлар. Шул «Тәварих» хакында кемдер саксыз фикер кузгатса:

– Онытмагыз, аны иманында камил, аңы-белеме бар кеше язган, – дигәннәрен ничәмә ишеттем. – Безнең чорыбызның белемдә тарлыгын гаеп итүебез – дөресрәктер!

Ш.Мәрҗани, М.Акмулла, Р.Фәхретдин, М.Госманов һәм башка галимнәрнең ул китапка биргән бәяләре йогынтысында формалашкан фикер калыпларым озак вакытлар шул хәбәрдар Казан аксөякләренең сүзләре тәэсирендә тамырдан какшаган икән, монда, әлбәттә, бары тик аңбелем дәрәҗәсенең канәгатьсез хәлдә булуыннан гына зар итәргә кала. Дәлилгә китерелгән «Ибне-Фадлан сәяхәтләре»ндәге фактларга да беркатлылык белән турыдан-туры ышанырга тиеш түгелмен икән әле. Моны татарларга бераз хас кирелек аркасында дип аңларга ярамый.

III

Бүгенге көндә рус теле «урам теле» булудан үзе дә арына барып, милли мәртәбәсенә кайта башлады. Әмма ул барыбер дә безгә кирәк, глобальләшү шартларында аның да әһәмияте бермәбер артты. Рус теленең чит илләрдә мәртәбәсе һич кенә дә ким түгел, төрле мәмләкәт вәкилләре русчаны таныргa, белергә, үзләштерергә омтыла. Бу, әлбәттә, шул ук мәдәни үсеш юлының киңәя баруы белән бәйле. Рус телен өйрәнүебез, белүебез бүгенге көндә үзебез өчен дә файдага. Моңа Рәсәйдә яшәвебез генә сәбәп түгел. Милли хәрәкәтебез дә рус теленең үзенә каршы түгел, бәлки халыкта аны «урам теле» булып калу бәласеннән котылдыру юлын эзләү процессы да бара. Бусы да ачык билгеле хакыйкатьләребездән.

Рус теленең туган тел, чит телләр кебек үк бүгенге XXI гасыр Рәсәй кешесенә кирәклеге, аның да мәдәни, хәтта дини үсешебезгә дә хезмәт итүе һәм иттерелүе, аксөякләребезгә генә түгел, халкыбызга да бары файдага. Рус телен без мәктәпләребездә, югары уку йортларыбызда, көндәлек тормышыбызда өйрәндек һәм өйрәнәчәкбез. Аңа инде мөнәсәбәтебез «урам теле»нә булган мөнәсәбәт түгел, бәлки милли, зыялы, мәдәни телгә карата хөрмәтебез төсен алды.

Татар халкының шушы соңгы унбиш-егерме ел эчендә генә дә телләргә бәйле үсеше сокландыра. Бу ниндидер бер ялагай, куштан, мактану сүзләре түгел, бәлки чынбарлыкны дөрес аңларга тиешбез дип таләп итүдән туган уйларыбызның фикер формасын ала баруы күренешеннән килә. Башкалар бүтән реалияләрдә яшәргә мөмкиннәр, әмма мин ул хакыйкатьләрне тоймыйм, күрмим һәм аңламыйм. Белемем татар әдәбияты һәм журналистика гыйлеме өлкәләре белән бәйләнештә үсте. Язучы һәм шагыйрь буларак дөньяның барышын туктаусыз күзәтергә, бәяләргә, ачыкларга туры килә. Борынгы язма мирасыбызны утыз еллап даими өйрәнеп, тикшереп, текстларын том-том китаплар рәвешендә дә, фәнни анализ юлында гыйльми трактатлар хәлендә дә халыкка, өлешчә булсын, кайтаруларым да – барысы бергә татар милли тормышын һәм яшәешен дөрес күрәм, тугры бәялим дигән өметемнең терәге. Ялгышырга да мөмкинмен. Адәм баласы хаталардан хали була алмый шул.

IV

Телебезне алга таба нәрсә көтә? Ул үсешендә туктап калмасмы? Яшьләр аңа ничек карар? – Менә шушындый йөзләрчә төрле сораулар аңны да, күңелне дә борчып торалар. Аңлашыла, яшьләрнең туган телебезгә һәм башка

телләргә мөнәсәбәте тәрбиядән алынган өлешкә дә, глобаль мәдәни үсешкә кушылып, аннан читләшми яшәвебезгә дә бәйле. Бер чит телне генә белгәндә, ул тел үз сөйләшебездә ана телебезне чүпли башлый, әмма ике-өч чит телне үзләштергәндә, бөтенләй башка төрле процесс башланып, аң һәм телне мөкатдәс итеп кабул итүгә күчәсең һәм аның шушы үсеш-киңәеше үз милли телебезнең сафлыгына хөрмәт хисен ныгыта. Әмма иң тәүдә үз милли ана телеңне белү шарт. Бу фикер — үз тәҗрибәмнән генә түгел, башка ничәмә акыл иясе кешеләрдән ишетелгән, хәтта әүвәле ишеткәннәремдә гаҗәпкә дә калдырган сүз.

Татар телебезнең драматик кына түгел, трагик халәт алдында калган чаклары да булмады түгел. Заман үзгәреше Россия чикләрен ничек ачарга мәҗбүр итсә, аң-белемдә чикләнгәнлегебезне дә бик тиз ихтыярый төшендерде. Вакытында авыл мәктәбендә укуым да, Казан милли аксөякләребез арасында кабул ителүем дә, башка сәбәпләр дә миңа ярдәм иткәндер дип беләм. Татарчасы яхшы булган кешенең русчасы һәм чит телне белүе аның каравы начаррак дигән кешеләрне аңламыйм. Русчам дәрәҗәсе үземдә канәгатьсезлек тойгысы уяткан чаклар аз булмады, туган телем белән бәйле дә шундый ук хисләр кичермәдем түгел, чит телләрне үзләштерү осталыгым да бик үк алай сөендерде дип әйтү җаема килми. Боларны авыл мәктәбенең тәрбиясе җимешләреннән буларак азмы бәяләдем? Шуның белән хаталы уйларга да дучар идем. Әмма авыл мәктәбенең үз хозурлыклары һәм ямьнәре хатирәләремдә яңарып, булдыксызлыгымны укытучыларыма аудару бәласеннән шул изге тойгылар саклап калдылар. Төрле телләрне белү бәхете кешегә әйтеп-сөйләп бетереп булмаслык рәхәтлекләр ирештерә!

Бүген мәктәп белеменең заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә булырга тиешлеген күпләр кайгырта. Дәүләт думасы махсус карарлар әзерләде. Дәүләт Советы да эштә. Аңа карап кына, каршылыклы карарлар белән берни дә хәл итеп булмас, укучылар һаман да искечә калырлар, укытып кына белем артмый, диючеләр дә җитәрлек, милли телне кысалар, милләткә үсү мөмкинлекләре бирмиләр, дигән кешеләребез дә борчылуда. Уку-укыту методикаларына үзгәрешләр, үзгәртеп корулар һәм заманга кулай формалар мәйданга чыкмый торып, бу тырышлыклар һәммәсе дә иске киемгә яңа ямаулык салудан гына гыйбарәт. Әле XIX гасыр ахырында гына балаларны уку-язуга өйрәтү мәсьәләсе татарда кискен торган, аны Исмәгыйль Гаспринскийның «җәдит методы» чишкән. Моның шулай икәнлеген татар тормышыннан һәм мәктәп-мәдрәсәсеннән хәбәрдарлар бик яхшы беләләр. Бүген телләрне өйрәнүдә дә шундый ук яңа методлар мәйданга чыгарга тиеш. Дөрес, алар бар. Әмма эффектлы методика юк. Бу хәл, әлбәттә, халыкны борчый. Галимнәребез тырыша. Юлларны барлый, сыный. Талантлары ачылуны без дә көтәбез. Өметләр акланыр кебек.

Хикмәт телдә генә түгел, бәлки һәр кеше дә үзен бәхетле тоя торган җәмгыять төзи алуыбызда. Милли телебезнең яшәве һәм хөрмәтле булуы милләтебезне бәхетле итә, аңа башка милләт вәкилләре дә сокланса, күңелебез тагын да нурланып китә. Татар халкында кардәш һәм күршекүләнгә хөрмәт белән яшәү рәвеше гадәт-йола, шәригать дәрәҗәсендә йөртелә. Нинди генә очракта да үзара хөрмәт хисен югалтырга ярамый – без моны барчабыз да яхшы беләбез һәм боларны Аллаһы Тәгалә каршындагы дөньялык гамәлләребезнең берсе буларак аңлыйбыз. ■

Рәшит Һибәтулла улы НӘҖМЕТДИНОВ 1912 елның 15 декабрендә Казахстанның Актүбә шәһәрендә туа, шашка буенча СССРның спорт остасы (1949), шахмат буенча халыкара дәрәҗәдәге спорт остасы (1954), СССРның атказанган тренеры (1962), биш тапкыр РСФСР чемпионы (1950, 1951, 1953, 1957, 1958), «Шахмат уены», «Сайланма партияләр» дигән китаплар авторы. 1974 елның 3 июнендә Казанда вафат була. 1979 елдан Казанда Россия шахмат мәктәпләре командалары арасында Рәшит Нәҗметдинов истәлегенә турнир уздырыла.

ШАХМАТ ГҮЗӘЛЛЕГЕ ГРОССМЕЙСТЕРЫ

15 ДЕКАБРЬДӘ АТАКЛЫ ШАХМАТЧЫ МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ РӘШИТ НӘҖМЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ БУЛА. ШАХМАТТАГЫ ИҢ ЗУР ДӘРӘҖӘ – ГРОССМЕЙСТЕР ТИТУЛЫН ЙӨРТМӘСӘ ДӘ, БИК КҮП ГРОССМЕЙСТЕРЛАРНЫ, ШУЛ ИСӘПТӘН ДӨНЬЯ ЧЕМПИОННАРЫ МИХАИЛ ТАЛЬ, БОРИС СПАССКИЙ КЕБЕК УЕНЧЫЛАРНЫ ҖИҢГӘН ШӘХЕС УЛ. НӘҖМЕТДИНОВ УЙНАГАН БАЙТАК ПАРТИЯЛӘР ШАХМАТ УЕНЫ ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛӘРЕНӘ, САЙЛАНМА ПАРТИЯЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН.

Ни кызганыч, миңа бу бөек шахматчы белән очрашырга насыйп булмады – мин урта мәктәпне тәмамлап, Казанга укырга килгәндә, ул бакыйлыкка күчкән иде инде. Шулай да Рәшит абый белән аралашкан байтак кешеләр сөйләве буенча, аның чыннан да уникаль шәхес булуына ышандым. Ул шахмат тактасы артында гына түгел, ә тормышта да бик үзенчәлекле, күп укыган, берничә чит тел әдәбиятын «су урынына эчкән», шул ук вакытта гадилеге, үз-үзен тотышы белән гаҗәеп тыйнак кеше булып күзаллана. Р.Нәҗметдинов журналистлар, язучылар белән нык аралашып яшәгән, бик еш кына Бауман урамындагы нәшриятка кергәли торган булган. Ә инде шунда берьюлы берничә тактада сеанс үткәрергә сорасалар, беркайчан да каршы килмәгән. Әлеге сеанслар кайчагында өчәр-дүртәр сәгатькә сузылган, алар тәмамлангач та атаклы шахматчы берәр бүлмәгә кереп, үзенең кайчандыр кем беләндер уйнаган партияләрен анализлый торган булган.

Рәшит Һибәт улының осталыгы, уникаль уены, кешелеклелек сыйфатлары, гадилеге хакында Михаил Таль, Борис Спасский, Яков Дамский, Алексей Суэтин, Марк Тайманов истәлекләрендә шактый күп язылган. Шулай да Нәҗметдиновка иң зур бәяне заманында ФИДЕ, ягъни Халыкара шахмат федерациясе президенты булып торган Мак Эйве биргәндер, мөгаен. Ул татар шахматчысы хакында: «Нәҗметдинов югары дәрәҗәдәге шахмат гүзәллеге гроссмейстеры», – дип әйтә.

Рәшит Һибәтовичның тагын бер уникаль күрсәткече хакында әйтеп китәргә кирәктер. Ул — шахмат буенча халыкара дәрәҗәдәге оста булу белән бергә шашка уены буенча да СССРның спорт остасы дәрәҗәсенә ирешкән уенчы. Беренче карашка бер-берсенә шактый якын тоелган бу ике уен буенча шундый дәрәҗәләргә ирешкән спортчылар элеккеге СССР территориясендә бүтән юк. Белгечләр аңа шашка уенында да зур киләчәк юрыйлар, әмма, кем әйтмешли, дөнья мәшәкатьләре, спортка соңлап килү, армиядә хезмәт итү, Бөек Ватан сугышы аңа бу төрдән үзен тулысынча ачылып бетәргә мөмкинлек бирмиләр.

Ә шахматта гроссмейстер дәрәҗәсенә ирешә алмавын ул түбәндәгечә аңлата: «Сәбәп гади һәм объектив. Шахмат уены шулкадәр катлауланды ки, анда югары нәтиҗәләр күрсәтү өчен теоретик һәм иҗади нигезне балачактан ук салырга кирәк. Олыгайгач инде багажны тулыландыру һәм аны яңа белемнәр белән баету өчен вакыт җитми. Талантлы асылташлар заманы үтте, сәләт белән генә аерым уңышлар яуларга мөмкин, ә югары класслы гроссмейстер була алмыйсың. Барлык дөнья чемпионнары да: Ботвинниктан башлап, Смыслов, Спасский, Петросян, Таль — алар барысы да фундаменталь әзерлекне балачакларында – 7-8 яшьтән башлап алганнар. Мин исә шахматка шактый соңлап, 17 яшьлек «картлач» булып килдем һәм фундаменталь база булмау үзен нык сиздерде. Әйе, мин аерым партияләрне югары дәрәҗәдә үткәреп, «Матурлык өчен» призлары да алдым, әмма гроссмейстер дәрәҗәсенә менеп җитү насыйп булмады».

Һәр шахматчының бәхетле саны була. Рәшит Һибәт улы өчен андый сан – бишле. Ул биш тапкыр РСФСР чемпионы була, биш мәртәбә икенче урын ала. Биш тапкыр СССР чемпионатының финалында уйный. Халыкара турнирларның бишесендә алгы урыннарга чыга. Дөньяның биш чемпионы белән уйнап, дүртесен ота, берсе белән уртак нәтиҗәгә ирешә.

Ярлы крестьян гаиләсендә туган, биш яшеннән әти-әнисез калган татар малае мондый биеклеккә ничек күтәрелә соң?

Башта аңа көтү көтеп тамагын туй-

дырырга туры килә. 1921 елгы ачлык вакытында Рәшит балалар йортына эләгеп кенә исән кала. Аннан соң малайга бәхет елмая. 1922 елда Рәшитнең абыйсы – Кызыл Армиядә хезмәт иткән Кави – Казандагы хәрби мәктәптә комиссар булып эшли башлый һәм энесен үз янына алдыра. Бертуганнарның өлкәне язучы Кави Нәҗми булып таныла, Рәшит исә бөек шахматчы дәрәҗәсенә ирешә.

Шахмат фигураларын Рәшит беренче мәртәбә унбер яшендә күрә. Журналдан укып, үзлегеннән уйнарга өйрәнә ул. Беркөнне Коммунистлар йортына пионерлар отряды җыенына баргач, Рәшит шахмат уйнаучыларга тап була. Алар малай журналда гына күргән фигураларны бер шакмактан икенчесенә күчерә-күчерә уйныйлар. Үзлегеннән уйнарга өйрәнгән үсмер дә уенга кушыла. Бәлки, ул чакта аңа көндәшнең йомшаграгы туры килгәндер, әмма Рәшит җиңүгә ирешә. Моны шахмат түгәрәге җитәкчесе Н.А.Самсонов күреп ала һәм, малайга «Өметле күренә, кабул итегез», дигән язу тоттырып, аны шәһәрнең шахмат клубына җибәрә. Бу клубка йөрү, «Шахмат уенына үзлегеңнән өйрәнү» китабын үзләштерү Рәшитне тагын да тирәнрәк уйларга өйрәтә. Өч ел эчендә ул шахмат буенча икенче категория ала.

1927 елда Казанда мәктәп укучылары арасында уздырылган шәһәр беренчелегенең беренче уенында унбиш яшьлек үсмер, унбиш мөмкинлектән унбиш очко туплап, беренче урынны ала. Соңрак Рәшит Казан шәһәре чемпионатында, Идел буе беренчелегендә җиңә, Одессада үткәрелгән ярышларда җиңүче булып таныла. Бөтенроссия күләмендә беренче категорияле уенчылар арасында оештырылган матчларда исә Нәҗметдинов югары дәрәҗәдәге уен күрсәтә алмый. Соңрак ул җиңелүен: «Мине «кыйнап» кайтардылар», – дип бәяли. Шулвакыт Рәшит теория ягыннан йомшаграк әзерләнгәнлеген аңлый. Оста уенчы булу өчен, үз өстендә эшләргә кирәклегенә төшенә. Казан дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетында укыган елларында ул Чигорин, Алёхин, Ласкер кебек оста шахматчыларның партияләрен өйрәнә. Катлаулы исәпләүләргә корылган, уен барышын алдан белеп алуга нигезләнгән, тырышлык, хәйләкәрлек, партиянең соңгы минутына кадәр уйнарга, җиңәргә омтылу кебек сыйфатларны үз эченә берләштергән «Нәҗметдинов почеркы» әнә шулар нигезендә формалаша.

Ил өстенә дошман яулары килгәч, егет, һәрбер ватанпәрвәр кеше кебек үк, өстенә соры шинель кия. Сугышны ул Германиядәге Совет хәрби администрациясендә кече политрук булып тәмамлый. Фашистларны җиңү хөрмәтенә оештырылган шахмат матчында да катнаша.

РСФСР чемпионатында өч тапкыр җиңү яулагач, Нәҗметдиновны чит ил уенчылары белән очраштырып карарга булалар. 1954 елның декабрь аенда Рәшит Бухарестта үткән халыкара турнирга бара. Анда Румыния чемпионы Баланельны, халыкара дәрәҗәдәге спорт осталарын ота. Дүрт турдан соң милләттәшебез 3,5 очко белән алга чыга.

Бишенче уен алдыннан Нәҗметдиновка Казаннан куанычлы хәбәр китерәләр: аның улы туган! Шатлыгыннан дөньяны колачлардай булган уенчы шул көнне Италия чемпионы Энрико Паолины егерме җиде йөрештә үк җиңә. Турнир вакытында залда шауларга ярамаса да, тамашачылар совет шахматчысын озаклап алкышлый. «Улыбыз туу белән котлыйм! Паоли белән уйнаган партиямне аңа багышлыйм», – дип, ул Казанга телеграмма суга. Турнирның иң матур партиясе дип табылган әлеге уен дөнья матбугатын урап чыга. Өч айдан соң Халыкара шахмат федерациясе конгрес-

сында Р.Нәҗметдиновка халыкара дәрәҗәдәге спорт остасы исеме бирелә.

Рәшит Һибәт улы – бик күп спортчыларга үрнәк булырлык шахматчы. 1958 елда Сочи шәһәрендә РСФСР чемпионаты үткәрелә. Турнирның финалында ике уенчы-гроссмейстер Л.Полугаевский белән халыкара дәрәҗәдәге спорт остасы Р.Нәҗметдинов очраша. Беренче йөрештән үк уен кискен төс ала. Егерме дүртенче йөрештә ак фигуралар белән уйнаган Полугаевский караларның ферзена һөҗүм итә, филенә дә яный. Шулвакыт шахмат тактасы өстендә көтелмәгән хәл була. Нәҗметдинов, ферзен һәм филен коткару турында уйлап та карамыйча, ладьясын көндәшенә бирә. Оста комбинация ясап җиңү яулый. Соңрак «Сайланма партияләр» дигән китабында, әлеге уенны искә төшереп, Рәшит Һибәт улы «Бу мин уйнаган партияләрнең иң матуры булды», дип яза.

Республикабызда гына түгел, илебездә дә шахмат сөючеләр Нәҗметдиновның бу уенны зур осталык белән үткәрүен, шахматны сәнгать югарылыгына күтәрүгә зур өлеш кертүен онытмыйлар. Ул яулаган бүләкпризларның да күбесе аңа нәкъ менә шундый гүзәл җиңүләр өчен бирелә.

Сочидамы, Баку, Киев, Рига, Кишинёв, Ростовтамы, Будапешттамы, Монголия, Гыйрактамы – кайда гына чыгыш ясамасын, Нәҗметдинов һәрвакыт матур итеп, комбинацияләр ясап уйнауны беренче урынга куя. Шуның белән ул уеннарын техникага гына корган көчле көндәшләрен җиңеп чыга.

Милләттәшебез Михаил Таль, Борис Спасский, Исаак Болеславский, Лев Полугаевский, Давид Бронштейн, Ефим Геллер, Андре Лилиенталь, Игорь Бондаревский, Владимир Антошин, Семён Фурман кебек гроссмейстерларга, италияле Энрико Паоли, румынияле Виктор Чокыльтя кебек көчле уенчыларга каршы уйный, һәм алар барысы да, Рәшит Нәҗметдинов каршына утырганда ук, татар егетенең үзләрен нинди дә булса көтелмәгән хәл алдында калдырачагын беләләр. 1960 елда Михаил Таль, дөнья беренчелегенә әзерләнгәндә, Рәшит Һибәт улыннан ярдәм сорый. Рига гроссмейстеры дөнья чемпионы исемен алгач, Нәҗметдиновка, башка уңышларын да исәпләп, «СССРның атказанган тренеры» дигән мактаулы исем бирәләр.

Үзе гроссмейстер исемен ала алмаса да, Казанның Рәшит Нәҗметдинов исемен йөрткән шахмат һәм шашка клубыннан (хәзер ул Олимпия резервы үзәк балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе кыскача ЦСДЮШШОР дип атала) шахмат, шашка һәм го уены буенча дистәләгән гроссмейстер, халыкара спорт осталары үсеп чыкты. Әлеге мәктәпнең шәкертләре арасында Алисә Галләмова, Юлия Машинская, Илдар Ибраһимов, Валерий Яндемиров, Артём Тимофеев, Сандугач Шәйдуллина, Татьяна Гарбузова, Рамил Хәсәнгатин, Артём Ильин кебек халыкара гроссмейстерлар бар. Аларның саны елданел арта бара.

1988 елда Бауман урамындагы атаклы шахматчы яшәгән 76 нчы йорт диварына мемориаль такта куелды. Әмма бу гына аз. Башкалабызның берәр урамына Р.Нәҗметдинов исемен бирү хакында сүзләр күптән барса да, моның әлегә кадәр эшләнгәне юк. Югыйсә Татарстаныбызның һәм Россиянең генә түгел, ә бөтендөнья шахмат уены үсешенә үз өлешен керткән милләттәшебез моңа күтән лаек. Бәлки бу хата атаклы шахматчының тууына 100 ел тулган көннәрдә төзәтелер?!

***Атлас Гафиятов** әзерләде.*

2012 ЕЛГА «ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР, РӘСМИ ДОКУМЕНТЛАР

Бөтенроссия «Белем көне» бәйрәме уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов мөрәҗәгате. — №7. — Б.3.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның 2012 елда Ураза бәйрәмен һәм Корбан бәйрәмен уздыру көннәрен билгеләү турында Указы. — №4.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов юлламасыннан өземтә. — №8-9. — Б.3; №10-11. — Б.3.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Сабан туе уңаеннан Татарстан халкына мөрәҗәгате. — №2-3. — Б.3.

Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгы турында Декларация. — №5-6. — Б.3.

Туфан Миңнуллин: «Кеше белән язылмаган законнар идарә итәргә тиеш, аның эчке дөньясы, аның рухы…» — №1. — Б.76-77.

Туфан Миңнуллинны озату мәрәсимендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимовның ясаган чыгышы. — №1. — Б.78.

Татарстан Республикасы Президентының 2012 елны Татарстан Республикасында Тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан итү турында Указы. — №1.

Татарстан Республикасы Президентының 2012 елны Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турындагы Указы. — №1.

Шәүкәт Биктимеровны озату мәрәсимендә Роберт Миңнуллинның ясаган чыгышы. — №2-3. — Б.184-185.

МИЛЛИ ИДЕЯ

Әбләзев К. Саратов татар милли гимназиясе. — №10-11. — Б.80-82.

Гыйләҗев И. Татар теле язмышы турында кайбер уйланулар. — №7. — Б.6-11.

Лотфуллин М. Россиядә милли мәгарифнең киләчәге. — №7. — Б.12-20.

Мөхәммәтдинов Р. Татар идеясе. — №10-11. — Б.104-110.

Мөхәммәтов И. Замана мәктәбе. — №7. — Б.25-31.

Татарстан Республикасы мәгариф системасы турында кайбер статистик мәгълүматлар. — №7. — Б.21-22.

Ханнанов Р. «Миллилек — безнең төп өстенлегебез». Фаил Камаев белән әңгәмә. — №10-11. — Б.76-79.

Яхин Ф. Татар теле — гомумхалык теле. — №12. — Б.84-88.

ТАРИХ

Әксанов Ә. Казан ханлыгының барлыкка килүе турында. — №8-9. — Б.6-11.

Вәлиди З. Казан ханлыгында төрки ислам мәдәнияте. — №8-9. — Б.56-60.

Вәлиев Р. Киләчәккә илтүче мирас. — №1. — Б.13.

Вәлиев Р. Тарих сабаклары. — №5-6. — Б.14-18.

Гайнетдин М. Йосыф Акчура шәрехләвендә XX гасыр башы татар милли мәктәбе. — №7. — Б.32-42.

Гайнетдинов Р. Татарстан — милләттәшләребезнең тарихи Ватаны. — №10-11. — Б.119-123.

Галиев М. Киләчәккә карап. — №5-6. — Б.6-12.

Гатин М. Алман тарихчылары Казан ханлыгының яулап алыну сәбәпләре һәм нәтиҗәләре турында.— №8-9. — Б.68-75.

Гаяз Исхакыйның Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда сөйләгән нотыгы. — №4. — Б.59-60.

Гобәйдуллин Л. Без — бербөтен бүленмәс халык. — №10-11. — Б.52-75.

Гобәйдуллин Л. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты эшчәнлегенең кыскача елъязмасы (1992-2012 еллар). — №10-11. — Б.124-137.

Гобәйдуллин Л. Габдерәшит Фәхреддиновның «Русия тарихы» дәреслеге. — №8-9. — Б.100-107.

Гобәйдуллин Л. Милли музей проекты. — №5-6. — Б.88-94.

Гобәйдуллин Л., Дубин А. Кремль дамбасы: үткәне һәм бүгенгесе. — №7. — Б.44-47.

Гобәйдуллин Л., Дубин А. Хәтәр китә — хәтер кала… — №8-9. — Б.108-114.

Госманов М. Россиядә төрки-татар басмасының беренче үрнәге хакында.— №1. — Б.22-33.

Дәүләтшин Г. Тамырлар кая тоташа? — №2-3. — Б.98-106.

Дубин А. Александров пассажы. — №5-6. — Б.96-98.

Закиров Р. Татар юлы дәвам итә: Бөтендөнья татар конгрессына — 20 ел! — №10-11. — Б.16-29.

Заһидуллин И., Гобәйдуллин Л. Мөстәкыйльлек юлында: өч сорауга — егерме җавап. — №5-6. — Б.20-28.

Заһидуллин И. Гомумтатар мәдәнияте өчен мөһим! Генадий Макаров белән әңгәмә. — №4. — Б.38-45.

Заһидуллин И. Казан алыну сәбәпләре һәм нәтиҗәләре: XXI гасыр башы ераклыгыннан бәяләү. — №8-9. — Б.86-99.

Заһидуллин И. Күчмәннәр җәмгыятьләренең үзенчәлекләре. Николай Крадин белән әңгәмә. — №8-9. — Б.12-23.

Заһидуллин И. Тарихи-мәдәни мирас елы: нәтиҗәләр һәм бурычлар. Айрат Сибагатуллин белән әңгәмә. — №12. — Б.18-22.

Заһидуллин И. Үткәнебез сәхифәләрен барлап… Рафаил Хәкимов белән әңгәмә. — №2-3. — Б.14-22.

Ибраһимов Г. Гани бай. — №10-11. — Б.92-95.

Исхаков Д. Алтын Урдада ислам дине кабул ителү мәсьәләсе. — №1. — Б.9-12.

Исхаков Д. Татарны санау. — №10-11. — Б.30-36.

Исхаков Р. Сабантуй бәйрәме. — №4. — Б.20-29.

Исхаков Р., Баһаветдинова Х. Казан керәшен педагогия курслары укучысы И.Д.Бабушкин иншасы. — №4. — Б.76-83.

Кинан Э. Мәскәү һәм Казан: дала дипломатиясе моделе турында кайбер гомуми фикерләр. — №8-9. — Б.76-85.

Кылынч А. Идел-Урал татарларының Госманлы җирләренә XIX гасырның 70 елларына кадәрге күчешләре. — №5-6. — Б.44-62.

Мазһаров Ә. Мирас — халык хәтере. — №1. — Б.3-4.

Мазһаров Ә. Татарстан Республикасы Конституциясе: тарих һәм хәзерге заман. — №12. — Б.8-17.

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия» программасы. Кушымта. — №5-6. — Б.77-87.

Мәхмүтова А. Галимҗан Баруди һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе. — №5-6. — Б.65-76.

Миңнуллин Җ. Татарларда хәйриячелек тарихы сәхифәләре. — №10-11. — Б.38-45.

Мирсәет Солтангалиев — милли каһарманыбыз («түгәрәк өстәл»). — №4. — Б.11-19.

Мортазина Л. Татарда беренче педагогика фәннәре докторы. — №4. — Б.30-36.

Мөстәкыймов И. Сәхибгәрәй ханның Казан ярлыгына карата берничә фикер. — №8-9. — Б.50-55.

Мөхәммәдьяров Ш. Казан ханлыгының тышкы сәүдәсе. — №8-9. — Б.61-67.

Мөхәммәтшин Ф. Татарстан Республикасы Конституциясе — социаль татулык хартиясе: 20 ел реформа һәм сәяси тотрыклылык юлында. — №10-11. — Б.6-15.

Раимова Р. Биналарда — тарих хәтере. — №12. — Б.23-25.

Рәхимов Р. 1812 елгы Ватан сугышында беренче Типтәр полкы. — №5-6. — Б.30-41.

Ситдыйков А. Казан — ханлык башкаласы. — №8-9. — Б.40-49.

Солтангалиев М. Социаль инкыйлаб һәм Көнчыгыш. — №4. — Б.3-10.

Таһиров И. Татарлыгыбыз сагында. — №2-3. — Б.10-13.

Таһиров И. Татарны, бер-ике башка югары булмаса, танымыйлар. — №1. — Б.6-8.

Уразаев Ф. Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең эшчәнлеге турында. — №10-11. — Б.96-101.

Фәйзрахманов И. 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1815 еллардагы рус армиясенең чит ил походларында татарлар. — №2-3. — Б.24-30.

Фәйзуллин Р. Милли басма. Без булганбыз, бар һәм булачакбыз!— №1. — Б.16-20.

Хәбибуллин М. Арыслан галим (Тарихи сәхифә). — №12. — Б.28-34.

Хәбибуллина А. Татар федераль милли-мәдәни автономиясе: кичә, бүген, иртәгә. — №10-11. — Б.46-51.

Хуҗин Ф., Ситдыйков А. Казан Кремлендә ханнар төрбәсе.— №8-9. — Б.24-39.

Һадиев И., Мәрданов Р. И таш, сөйлә.... — №1. — Б.80-87.

Чорлар кисешкәндә... — №1. — Б.2.

Шакиров Ә. Тукай авылы мәхәлләсе иҗтимагый киңәшмәсенең эш тәҗрибәсеннән. — №10-11. — Б.84-86.

Шәйдуллина Р. Нигъмәтең шөкранасы дөньяда кылмак изгелек... — №10-11. — Б.87-91.

Шәймиев М. Федератив мөнәсәбәтләр һәм илдәге вазгыять. — №12. — Б.4-7.

Шәйхи Г. Бердәм мәгълүмат кырында.— №10-11. — Б.102-103.

Яруллин Т. Бөтендөнья татар яшьләре форумы: яңа буын аваз сала! — №10-11. — Б.112-118.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Арсланов Г. Күпкырлы олы талант иясе. — №7. — Б.64-72.

Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Кол Шәриф Хаҗитархани. — №8-9. — Б.135-138.

Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай. — №2-3. — Б.54-61.

Батулла Р. Нәсел исеме. — №7. — Б.55-63.

Бәйрәмова Г. Тыйнак холыклы, басынкы табигатьле... Лирон Хәмидуллин белән әңгәмә. — №8-9. — Б.174-178.

Галимуллина Ә. Җанга рәхәт туган яктан яхшы хәбәр... — №4. — Б.62-68.

Галиуллин Т. Мин — Идел кешесе. — №5-6. — Б.109-122.

Ганиева Р. Тукай энциклопедиясенә. — №5-6. — Б.156-158; №7. — Б.74; №8-9. — Б.162-163; №10-11. — Б.188-189; №12. — Б.75-77.

Ганиева Р. Нәзыйрәчелектән-интертекстуальлеккә-әңгәмәдәшлеккә таба. — №2-3. — Б.44-53.

Ганиева Р. Шәрекъ Ренессансы. — №10-11. — Б.162-167; №12. — Б.36-43.

Гаташ Р. Каһарманнарга мирас — мәхәббәт. — №5-6. — Б.159-161.

Гобәйдуллин Л. Әхмәтҗан Бикмиевнең татар авыл хуҗалыгы әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге. — №1. — Б.58-61.

Җәүһәрова Ф. Рухи мирасыбызны саклауга кагылган кайбер фикерләр. — №1. — Б.68-73.

Заһидуллина Д. Казан ханлыгы чоры — милли әдәбият дәверенә капка (XV йөзнең икенче яртысы — XVI йөзнең беренче яртысы). — №8-9. — Б.148-150.

Исхаков Д. Соңгы сугыш (Бөек сәед Кол Шәриф турында тарихи эссе). —№8-9. — Б.142-147.

Казанда үтә торган Сабантуй бәйрәме — XIX гасыр рус газеталары битләрендә. — №2-3. — Б.140-143.

Кириллова З. Казан арты керәшеннәренең табын җырлары. — №4. — Б.70-75.

Миңнегулов Х. Гомәр Дашкин һәм аның шигъри иҗаты. — №1. — Б.36-45.

Мостафин Ш. Илгә тугрылыклы булып калам!.. — №5-6. — Б.162-164.

Мотыйгуллина Ә. Әмирхан Еникинең прототиплар дөньясы яки чынбарлыктагыча гадәти каһарманнар. — №1. — Б.62-65.

Мөхәммәтҗанова Л. Дастани мирасыбыз чичәннәр иҗатымы? — №5-6. — Б.168-174.

Рәмиев З., Ганиева Р. Кыска, әмма мөһим нотык. — №4. — Б.58-59.

Сабиров Р. Дөнья ярып атлап киләмен... — №5-6. — Б.146-154.

Сәйфуллина Ф. Ике бәет: уртак һәм аермалы яклар. — №5-6. — Б.136-144.

Сибгатуллина Ә. Габдерәшит Ибраһимның Җәмалетдин Әфгани турында бер чыгышы. — №12. — Б.44-51.

Тынгысыз галимә. Резеда Ганиевага 80 яшь. — №10-11. — Б.160-161.

Уразаев Ф. Федераль Сабантуй: тәҗрибә һәм үсеш перспективасы. — №2-3. — Б.122-132.

Фукс К. Сабан. — №2-3. — Б.144-148.

Ханнанов Р. «Сабан туе — безнең туй, сөлге яулык сайлап куй». — №2-3. — Б.108-120.

Хәйри Ә. Рамазан. — №5-6. — Б.102-105.

Хәсәнова Ф. Туфан строфасы серләре. — №12. — Б.57-68.

Хәсәнова Ф. Унҗиденче елның алдында уяндык без көлеп... — №2-3. — Б.68-75.

Хөснетдинова Г. Гаяз Исхакый: «...Кара көннәребезнең бетеп килгәненә, кояш тууының якынлашуына сөенә алабыз...». — №8-9. — Б.125.

Хөснетдинова Г. Маяк. — №10-11. — Б.152-156.

ӘДӘБИЯТ

Арсланов Н. Шагыйрьгә. — №7. — Б.43.

Афзал Г. Тарих таңы... — №1. — Б.21.

Әгъләмов М. Синең кулда каләм...— №8-9. — Б.151.

Әмирхан Ф. Сабан туенда. — №2-3. — Б.150-153.

Әхмәдиев Н. Мирас. — №5-6. — Б.155.

Әхмәтҗан Р. Азатлык. — №5-6. — Б.19.

Әхмәтҗанов Р. Сабан туенда. — №2-3. — Б.133.

Баттал Ф. Явыз Иванның ачы теле.— №8-9. — Б.164-166.

Батулла Р. Ярыш. — №2-3. — Б.

Бәйрәмова Ф. Батырша. — №10-11. — Б.168-173; №12. — Б.50-54.

Буби Г. Хакыйкать. — №5-6. — Б.128-134; №8-9. — Б.152-158.

Булатова К. «Питрау үтте — җәйләр бетте», — диләр... — №4. — Б.46.

Вәлиев Р. Борынгы Болгарда. — №1. — Б.57.

Вәлиев Р. Киләчәккә илтүче мирас. — №1. — Б.13.

Вәлиев Р. Чират. — №7. — Б.75.

Галиев Ш. Гаҗәпләнмә... — №10-11. — Б.159.

Гаташ Р. Сүнмәс йолдызлар. — №7. — Б.24.

Гәрәева С. Чабыш атлары. — №2-3. — Б.107.

Гыйззәтуллина Ф. Йөрәк җырлый. — №2-3. — Б.67-68.

Емельянов Я. Ходай сине илдән алган.— №4. — Б.61.
Зәйдулла Р. Шәһре Болгар. — №1. — Б.66.
Зөлфәт. Теге чак... — №7. — Б.73.
Игәнәй Я. Киләчәккә илтик. — №4. — Б.90.
Измайлова Н. Читтә... — №10-11. — Б.187.
Исхакый Г. Матәм көне. — №8-9. — Б.126-132.
Исхакый Г. Милли хәрәкәт вә Себер мөселманнары.— №10-11. — Б.156-158.
Кадыйри З. Җыеннар. — №2-3. — Б.135.
Кол Шәриф шигырьләре. — №8-9. — Б.138-141.
Маннапов Ш. Батыр тәкә. — №2-3. — Б.95.
Мансуров З. Катыктан акча эзләү. — №2-3. — Б.134.
Мансуров З. Сызлаулы хәтерне яңарту. — №1. — Б.14.
Мәннан Р. Идел ярында. — №5-6. — Б.145.
Мингалим Р. Иртәгә... — №5-6. — Б.123-127.
Мингалим Р. Үпкәләрмен кебек. — №5-6. — Б.181.
Мингалим Р. Шигырь генә... — №5-6. — Б.63.
Миңнеханова Н. Казан. — №10-11. — Б.111.
Миңнуллин Р. Шәһре Болгарда. — №1. — Б.34.
Мирза М. Сабантуй. — №2-3. — Б.186-187.
Мирза М. Скифлар — ерак бабайлар... — №1. — Б.88.
Морат Г. Алып батыр уллары. — №2-3. — Б.154.
Морат Г. Аран. — №5-6. — Б.29.
Морат Г. Болгарда. — №1. — Б.66.
Мөдәррисова Х. Минем халкым.— №10-11. — Б.37.
Мөслимова Ф. Казаным. — №5-6. — Б.175-177.
Мөхәммәтәмин. Гъикаб. — №8-9. — Б.179.
Османов Д. Кырымым — Казаным. — №10-11. — Б.83.
Рахман Р. Йолдызлар төстән язганда... — №7. — Б.80-90; №8-9. — Б.168-173; №12. — Б.69-74.
Рахмани Р. Бөтендөнья Сабан туйларының башкаласы — Казан! — №2-3.— Б.31.
Рәхим Г. Укымышлылар турында. — №4. — Б.56.
Рәхим Г. Шигъри дөньям. — №4. — Б.37.
Рәхим Г. Хан мәчетендә.— №8-9. — Б.159-161.
Рәхимова Б. Өмет белән язны көтеп алдык. — №5-6. — Б.99.
Рәшит Ә. Болгар... — №1. — Б.95.
Рәшит Ә. Каенлыкта бүген Сабан туе... — №2-3. — Б.149.
Сабиров И. Ул заманда. — №2-3. — Б.121.
Саттар Р. Шигырьләр. — №5-6. — Б.165.
Сәгыйди Ә. Шигырьләр. — №2-3. — Б.76-ө79.
Сәлах Р. Без дә бөек. — №5-6. — Б.43.
Туфан Х. Гомерем юлы. — №12. — Б.35.
Уткин Е. Кешегә ни җитми? — №4. — Б.84.
Фәйзуллин Р. Болгарда төн. — №1. — Б.34.
Фәхреддин Р. Уйгану вә яңалык тарихы. — №1. — Б.46-53; №2-3. — Б.81-94.
Филиппов А. Табигатькә нәрсә булды икән... — №4. — Б.89.
Харис Р. Ак сөлге. — №2-3. — Б.23.
Харис Р.Татарстан. — №5-6. — Б.13.
Хәким З. Татар иле. — №5-6. — Б.95.
Хәлим А. Без исән! — №8-9. — Б.167.
Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»сеннән үрнәкләр. — №2-3. — Б.62-67.
Шагыйрьҗан Л. Җыен сүзе. — №2-3. — Б.41.
Шәрипов Р. 30 нчы август, ягъни сүз урлау. — №5-6. — Б.135.
Шәрәпова Й. Чынаяклар. — №4. — Б.92-93.
Шәриф К. И күңел... — №8-9. — Б.133.
Юнысова А. Кәрим Тинчуринның кесә сәгате. — №7. — Б.91.
Яруллин Ф. Иң кадерле байлык. — №7. — Б.76-79.
Яруллин Ф. Якташларыма бәйрәм. — №2-3. — Б.80.
Яхин Ф. Хәйдәр (Мин белгән Гайнетдин). — №10-11. — Б.174-186.

СӘНГАТЬ

Әхмәтова Д. Кол Шәриф мәчете — яңарыш символы. — №1. — Б.91-94.
Мир-Хәйдәров Р. Сталин лауреаты (Әдәби портрет). — №10-11. — Б.141-151.
Поляков А. «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле. — №4. — Б.51-55.
Ханнанов Р. Ул кабызган утлар балкышы. Рәшид Заһидуллин белән әңгәмә. — №7. — Б.50-53.
Шаһиева Р. Казан кыйссасы. — №8-9. — Б.115-124.

ЯҢА КИТАПЛАР

Әхмәтҗанов М.И. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре. Илдус Заһидуллин рецензиясе. — №5. — Б.182-185.
Вклад Башкирии в победу России в Отечественной войне 1812 года. Сборник документов. Илдус Заһидуллин рецензиясе. — №5. — Б.185-187.
Гасырларны кичкән Наласа. Ленар Гобәйдуллин рецензиясе. — №7. — Б.92-94.
Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык. Динә Мостафина рецензиясе. — №10-11. — Б.190-191.
Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства. Илдус Заһидуллин рецензиясе. — №8-9. — Б.189-190.
Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби-нәфис, документаль, биографик җыентык. Ленар Гобәйдуллин рецензиясе. — №12.
Таһиров И.Р. Ил корабын җил сөрә: мәкаләләр, истәлекләр. Илдус Заһидуллин рецензиясе. — №4. — Б.94-95.
Фатих Әмирхан: тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре. Илдус Заһидуллин рецензиясе. — №8-9. — Б.188-189.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Галиуллин Т. Сүз ул — гәүһәр. — №2-3. — Б.168-172.
Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Идел эче — имин йорт. — №5-6. — Б.178-180.
Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Иле иркеннең көне иркен. — №2-3. — Б.173-178.
Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Үз халкыңны үз итсәң, ят халыкка кол булмассың. — №8-9. — Б.182-187.
Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Халык байлыгы җир белән су. — №4. — Б.86-88.
Нәбиуллина Г., Гыйләҗева Л. Иле барның теле бар. — №12. — Б.80-81.

ТӨРЛЕЛӘР

Гафиятов А. Шахмат гүзәллеге гроссмейстеры. — №12. — Б.89-92.
Хушлашу [Туфан Габдулла улы Миңнуллин]. — №1. — Б.74-75.
Хушлашу [Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров]. — №2-3. — Б.182-183.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

8 НОЯБРЬДӘ Татарстанның халык язучылары Мөдәррис Әгъләм, Фәнис Яруллин, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафинның каберләренә истәлек ташлары куелды. Бу изге гамәл өчен Татарстан Республикасы хөкүмәте акча бүлеп бирде, ә һәйкәлләрне скульптор Дмитрий Кузнецов иҗат итте. Ташларда әдипләрнең иҗат үзенчәлекләре, хис-кичерешләре чагылыш табу аеруча игътибарны җәлеп итте. Хәтер яңарту мәрәсимендә республика җитәкчеләре, язучылар, шагыйрьләр, әдипләрнең туганнары, гомумән, татар әдәбиятын сөючеләр катнашты.

8-9 НОЯБРЬДӘ Чебоксар шәһәренең Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институтында «Идел буе халыкларының менталитеты һәм этномәдәни үсеше: тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән төбәкара фәнни-гамәли конференция оештырылды. Конференция Россия дәүләтчелегенең 1150, Козьма Минин һәм Дмитрий Пожарский җитәкчелегендә халык ополчениесе Мәскәүне поляк интервентларыннан азат итүнең 400 еллыгына багышланган иде. Чебоксар каласы Татарстан, Мордовия, Мари-Эл республикаларыннан, Төмән, Свердловск өлкәләреннән килгән галим-голәмәләрне үзенә җыйды. Конференция эше барышында Идел буе халыкларының тарихы һәм менталитетлары формалашу, этномәдәни диалог, менталитет кысаларында этник берләшмәләрнең мәдәнияте, Россия социомәдәни мәйданында төрле милләтләрнең урыны кебек мәсьәләләр тикшерелде.

23 НОЯБРЬ көнне Татарстан Республикасы Президентының 2012 елда фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре бирү турында Указы имзаланды. Бүләккә ия булучылар арасында тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президиумының элеккеге киңәшчесе Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов та (вафатыннан соң) бар. Аңа бу бүләк күренекле шәхесләр турында «Җыен» фонды тарафыннан бастырып чыгарылган җыелма китаплар сериясен әзерләгәндә тарихи-биографик хезмәтләр циклы һәм фәнни-редакторлык эшчәнлеге өчен бирелә.

29 НОЯБРЬ көнне Казан каласының «Касыймия» мәдрәсәсе бинасында күренекле татар дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе, ислам белгече, Татарстан Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге җитәкчесе, «Мусульманский мир», «Иман нуры» журналларының баш мөхәррире, «Иман» мәркәзенең җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Вәлиулла хәзрәт Якупов исемендәге музей ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР Мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Абдулла Әдһәмов, Татарстанда Төркия консулы урынбасары Мәхмүт Мәҗит кебек мөхтәрәм шәхесләр катнашты. Музей экспозициясендә Вәлиулла хәзрәтнең шәхси архивы — диплом-таныклыклары, кульъязмалары, китаплары, фоторәсемнәре, киемнәре урын алган. Анда Совет чорындагы комсомол активистының ислам дине рухи лидерына күчеш этапларын күзәтергә мөмкин.

ЯҢА КИТАПЛАР



СӘХИБҖАМАЛ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯ: ӘДӘБИ-НӘФИС, ДОКУМЕНТАЛЬ, БИОГРАФИК ҖЫЕНТЫК / төз.-авт. Ж.Миңнуллин. — Казан: Җыен, 2012. — 480 б. («Шәхесләребез» сериясе).

Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1885-1974) — татар хатын-кызларыннан беренче булып профессиональ сәхнәгә аяк баскан мәшһүр актриса. Төрле образлар тудыручы өстенә әле ул 1912 елда «Нур» труппасын оештыручы, аның режиссёры, сәнгать җитәкчесе, артистларның остазы, спектакльләрнең чыгышларын әзерләү белән шөгыльләнүче җитәкче дә. Әлеге җыентыкта С.Гыйззәтуллина-Волжская истәлекләре, аның турында замандашлары, аны якыннан белгән шәхесләр — Шакир Шамильский, Локман Аитов, Риза Ишморат, Шәүкәт Биктимеровларның хатирәләре, сәнгать белгечләре һәм тарихчыларның мәкаләләре, шигырьләр, хатлар, документлар, рецензияләр, игъланнар, күзәтүләр урын алган. Без актрисаның үзе язган истәлекләреннән XX йөз башында татар хатын-кызына сәхнәгә күтәрелүнең ни дәрәҗәдә авыр һәм катлаулы булуын белә алабыз, әмма аны кадими карашлы халыкның хурлавы да, ачлык-ялангачлык, салкын торакларда яшәү дә, хакимиятнең спектакль куярга рөхсәт бирмәве дә, театрдан кергән табышның җан асрарга җитмәве дә туктатып калмаган. Ул Россия империясенең төрле почмакларында, шул исәптән Себер һәм Урта Азия киңлекләрендә яшәүче халыкларга беренче мәртәбә театрның нәрсә икәнлеген күрсәткән, милли тормышны җанландырып җибәргән. Аның турындагы хатирәләрдә С.Гыйззәтуллина-Волжскаяның талантлы актриса, оста педагог-җитәкче булуы белән шактый катлаулы шәхес икәнлеге дә ачыла. Шулай ук җыентыкта XX йөз башы татар вакытлы матбугатыннан да мәкаләләр китерелү бу шәхеснең шул чор иҗтимагый-мәдәни тормышындагы ролен тулырак ачарга мөмкинлек бирә. Китапның азагында актрисаның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында кыскача библиография тәкъдим ителү киләчәктә дә театр сәнгате тарихын тикшерүчеләр өчен маяк булып тора. Фотосурәтләр белән бизәлгән әлеге басма Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның шәхесенә һәм эшчәнлегенә бер һәйкәл булып, мәдәниятебез тарихы белән кызыксынучыларның күңелләрендә, китап киштәләрендә лаеклы урын табар дип уйлыйбыз.

Ленар Гобәйдуллин

Индекс 54132

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ

2012

ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАСЫ ЕЛЫ